PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
№ 9 / 2022

СӨЮМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ЗӨЛФИЯ ВӘЛИЕВА
кулларымда яралы кош

уку елын башлыйбыз
ХАТА
кемнең хатасы

банкада – десерт
шоколадлы
СУСЫЛ ЧИЯ

Ромина САДЫЙКОВА: *«Үсәр өчен тамырларыңны онытма!»*

Әниемнең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур
бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең
яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең
шаһиты.
Сакланамы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып
киткән әниегез нәрсәләр искә
төшерә, нинди истәлекләр
сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең
туй күлмәген киеп көзге
алдында бөтерелгән
мизгелне сурәтләгән
фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син,
кызым!» – дип әйтәдер
әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына
моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән
бер мизгел дә көтәбез!

Әтием белән әнием Казан педагогика институтында биш ел буе бер төркемдә укыйлар. V курста укыганда өйләнешәләр алар. Туй күлмәген бик озак эзләгән әнием. Беренчедән, икесе дә студент бит – кесә ягы сай, икенчедән – аның күңеленә ошаганы да тиз генә очрамаган... Үзләренең туе узгач, әни аны дус кызына биреп торган. Ә ул ерак районга кияүгә чыккан һәм... күлмәк аңарда калган. Әниләрнең өйләнешүләренә 30 ел булганда – быел гына безгә кире әйләнеп кайтты туй күлмәге. Бу еллар эчендә гаиләбездә әллә никадәр вакыйгалар булган, әмма бер нәрсә үзгәрмәгән: әтием һаман да әниемә яратып карый!

Зөһрә Гыйззәтуллина.
Балтач.

Фото: Гөлнара Сагиева.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Баш мөхәррир урынбасарлары 222-09-78
Мәликә Әсәтуллина
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламаның эчтәлеге (фото, текст) аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Ромина Садыйкова
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 19.08.2022 ел.
Чыгу көне: 1.09.2022 ел.
Заказ О-2479
Тираж 8761

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: ПО279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+


Белем көне
белән!

Баш мөхәррир сүзе



Фото: Анна Арахамия

Әтием укытучы булгач, минем өчен әле дә һәр сентябрь – яңа уку елы башы. Әтинең эше гаиләбез тормышында бик зур урын алып торды шул. Әнинең дә эше җаваплы иде, әмма анык өйгә ияреп кайтмый. Ә әткәйнеке – киресенчә... «Әтиегез дәфтәр тикшерә», «әтиегез план яза», «әтиегез дәрескә әзерләнә»... Математикадан сорау туганда, дәреслек тотып әти янында бер генә басып тормадым: «Хәзер, кызым, бер-ике дәфтәр генә карап чыгам да...»


Бүген, минемчә, мәктәптә укытучыга хөрмәт һәм балаларга мәхәббәт җитми. Монда без, әти-әниләрнең дә гаебе бар. Кайчагында хәтта берничә әхлакый кысаларга сыешмаган хәлләр дә килеп чыга. Бер әтинең, дәрескә кереп, бөтен сыйныф алдында укытучыга кычкырганын кайтып сөйләгән иде олы кызым. Бу безнең гаилә өчен шаккатмалы хәл булды. Укытучы бит ул! Аңа ничек тавыш күтәрергә була?!

Укытучы... Һәммәбезгә мәгълүм: белем бирүче генә түгел, тәрбияче дә ул. Укучыларым арасында абруем зур булсын дисә, мөгаллим балаларны яратырга, аларның барлык четерекле сорауларына җавап бирергә әзер булырга тиеш. Һәм... үзенең әхлакый йөзе турында да онытмаска!

Ә бүген, кызганыч, киресен дә күрәбез. Моңа соцчелтәрләр дә үз йогынтысын ясамый калмый, билгеле. Әйтик, замана белән бергә атлыйм дип (ә бәлки укучыма якын булыйм диптер дә?), бүген кайбер яшь укытучылар, соцчелтәр битләренә нинди генә фотосурәтләрен урнаштырмый. Ахырын уйламыйча... Әйе, укытучылар да кеше, әлбәттә. Әмма Мөхәммәт Мәһдиев язганча, «укытучы да бәрәңге ашый икән»ен балаларыбыз соңрак аңласа, яхшырак булыр иде...

...Әтиебез инде күптән арабызда юк, әмма аңа булган ихтирамны әлегәчә тоябыз: бүген ялгыз гына яшәгән әнкәйгә кайчандыр әти белем биргән укучыларның балалары булышырга килә...

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА



Безнен тышлыкта



«Хыялым – Мәскәүдә тагын да зур тәҗрибә туплап, шул белемнәрем белән Татарстанга кайту. Республикага файдалы буласым килә. Республика җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов та шулай ди бит – өйрәнеп кайтып, белемне монда кулланырга кирәк.»

10
Ак гөлләрдән җан җылысы алып...
Алсу Шакирова







6
Ялкаулык – сәбәп түгел
Чулпан Галиәхмәтова

14
Безнең күңелгә «Шахта» көе сеңгән!
Эльмира Закирова

22
«Блогер булу зыян итми»
Чулпан Галиәхмәтова

ЭЧТӘЛЕК

Заман һәм без

Без бит авыл балалары 18
Мәдинә Авзалова

Татар дөньясы

Риза-бәхил мин... 24
Римма Җаббарова

Теләк 27
Марат Кәбиров

Мәдәни тормыш

Син – шәмәхә көзем минем 34
Рифә Рахман

Салават күпере 36
Асия Юнысова

Китап уку – үзеңне табу ул 41
Гөлнара Сабирова

Яшәеш

Хата 48
Гөлнур Сафиуллина

Кулларымда яралы кош иде... 52
Лилия Гәрәева

Бала акча белән танышып үссен 55
Ләйсән Халикова

Хуҗабикә

Яшь әни: сорау–җавап 56


Укучы балалар туклануы 58

Тейплау 59

Өйнең яме – гөлләрдә 62

Тәэссоратлы әсәрләр 64
Зилә Нигъмәтуллина

28



«Беребез дә бүләк түгел...»
Гөлнур Гыйззәтуллина

42



«Дөнья буйлап инәй тавышын эзләп йөрим...»
Гөлнур Сафиуллина

60



Банкада – шоколадлы чия
Айзирә Биктимерова тәкъдим итә

»



ЯЛКАУЛЫК – СӘБӘП ТҮГЕЛ



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Баланың беренче тапкыр мәктәпкә баруы – олы вакыйга. Моңа җәй буе әзерләнәбез: әллә ничә төрле мәктәп формасы киеп карыйбыз, аяк киемнәрен сайлыйбыз, йөз төрле каләм, дәфтәрләр алабыз, иң матур һәм функциональ рюкзак эзлибез... Беренче сентябрьдә баланы энәдән-җептән киендереп, кулына иң зур гөлләмәне тоттырып зур горурлык һәм дулкынлану белән мәктәпкә алып барабыз. Икенче көнне мәктәп тормышы башлана. Менә монда әзерлек чын-чынлап күренә инде. Бала дәрестә утырмый, укытучы сөйләгәнне кабул итә алмый, өйгә язарга биргәнне эшлисе килми. Ә без нишлибез? «Син ялкау», – дип ачуланабыз. Ачуланабыз-ачуланабыз да бала өчен өй эше эшләргә утырабыз.
Бу – тамырдан дөрес түгел, дип чаң кага нейропсихологлар. Һәр бала талантлы, аларның белем алыр өчен бары тик базалары гына юк.

Укый-яза белү иң мөһиме түгел

Баланың мәктәпкә укырга баруы үзе өчен генә түгел, гаилә өчен дә стресс. Өйрәнелгән көнкүреш тормышка үзгәрешләр кертергә, кичләрен китап йә телефон тотып түгел, бала белән утырырга туры килә. Эштән арып кайткан хатын-кызга ашарга пешерергә дә, баласына дәрес карашырга да кирәк. Бүлмә белән кухня арасында йөгереп йөрмәс өчен, бала өй эшен кухняда – әнисе янында башкара. Кат-кат аңлата торгач суган тураганда йә бәрәңге әрчегәндә нерв киеренкелегеннән бер минем генә бармак пычакка киселмәгәндер, мөгаен. Әле көндез баланың тәртибеннән дә зарланып укытучы шалтыраткан булса, инде шартларга әзербез!

Британия галимнәре Хоулмз һәм Рейх тикшеренү уздырганнар. Алар билгеле бер вакыйгада кеше кичергән киеренкелекне 1 дән 100 баллга кадәр бәяләнгән. Һәр үзгәреш стресс тудыра икән. Хәтта ял да. Ул 13 балл белән бәяләгән. Мәктәпкә барганда кичергән стресс 25 балл күләмендә. Күченү йә эштәге проблемалар өчен борчылуга караганда зуррак бу. 7 яшьлек бала өчен әлеге киеренкелек тагын да авыррак. Хәзер мәктәпкә кергәнче балаларны психологка алып бару гадәти хәлгә әйләнә башлады. Психолог баланың эмоцияләрен, хисләрен, үзара мөнәсәбәтләр кора белүен тикшерә. Әле бит баланың баш мие бар. Мәктәптәге күпчелек проблемалар да аның эшчәнлеге белән бәйле. Баш мие функцияләренең никадәр үсеш алганын нейропсихологлар билгели.

– Мәктәпкә әзер булмаган балалар күп. Әйтик, беренче сыйныфка килгән кайбер бала 35 минут буе дәрестә утырып тора алмый. Моның сәбәбе – тәрбия җитмәү түгел, ә бала тудыру процессына бәйле патологияләр. Гиперактивлык һәм игътибар дефициты синдромы бар. Балалар арасында бу синдром бик еш очрый башлады. Ул баш мие эшчәнлеге бозылу белән бәйле. Мондый балаларга, гомумән, махсус нейропсихологик коррекция таләп

иттелә. Бу бик катлаулы юл. Бала белән хәтта берничә ел эшләргә кирәк булырга мөмкин. Әлбәттә, андый балаларга парта артында утыру үтә дә авыр. Стресс өстенә стресс. Үзе үк үз халәтен аңламый, җитмәсә, аны ачуланалар, – ди табиб-нейропсихолог Динара Шакирова.

Мәктәпкә барганчы укый-яза белү иң мөһиме түгел, ди табиб. Гомумән, хәреф өйрәтә башлаганчы, баланың базасы булырга тиеш. Шул вакытта гына аңа уку җиңел бирелачәк. Теләге булмаган баланы «мәктәпкә барасың бар» дип кенә укырга өйрәтү аны психологик яктан көчләүгә тиң. Чөнки ул моңа әзер түгел. Шуңа теләми дә. Ә ничек әзерләргә соң? Казанда беренчеләрдән булып нейропсихологияне өйрәнгән тәҗрибәле табиб Динара Шакирова әйтүенчә, баланың баш мие эшчәнлеге 5 яшькә формалаша. Шуңа күрә бу яшькә кадәр аның хәтерен, игътибарын, фикерләү сәләтен, пространствода фикерләвен, мантыйгын үстерергә кирәк. Ул бары тик уеннар аша гына мөмкин. Һәр функция өчен 3–5 төрле уен булса яхшы. Мәсәлән, без кечкенә балалар белән шакмаклы уйныйбыз. Әмма зурая төшкәч ул уеннар онытыла. Балага кызыгы бетте, дибез. Ә бу уеннарны бары тик катлауландырырга гына кирәк икән. Мәсәлән, «Никитин шакмаклары», «Пифагор квадраты» уеннары баланың акыл үсешенә файдалы.

– Әгәр баш миенең бер функциясе генә үсми кала икән, балага укырга авыр булачак. Ышаныгыз, бала булдыра алган бар биремнәрне эшләргә әзер, чөнки аны мактаячаклар. Әгәр эшли алмый икән, киреләнә башлый, теләге бетә. Ә әни кеше аны ялкау дип сүгә. Бу һич ялкаулык түгел. Күз алдыгызга китерегез, сезгә кытай телендә язылган текстны укырга бирәләр. Сезгә ул кызык түгел, чөнки аны укый белмисез, – ди нейропсихолог.

Мәктәпкә баручы балалар арасындагы тагын бер проблема – күз хәтеренең начар үсүе. «Башлангыч сыйныф укучыларына диагностика үткәргәндә 80 процентының күз хәтере булмавы ачыклана», – ди Динара Шакирова. – Чөнки әтиәниләр баш миенең бу функциясен



Нейропсихолог Динара ШАКИРОВА: «Бала бар биремне эшләргә әзер, әгәр аңламый икән, киреләнә башлый, теләге бетә».

үстерүгә әллә ни игътибар бирми. Балага шигырь өйрәтеп, аның ишетү хәтерен яхшыртабыз. Ә күз хәтерен үстерү өчен бала белән махсус утырып уйнарга кирәк. Мәсәлән, мемори карточкалары уены. «Күз хәтере камил була икән, бала татарча да, русча да, инглизчә дә җиңел укырга өйрәнәчәк», – ди табиб.

Үкенергә калмасын

Кайбер вакытта баланың күз хәтере дә, ишетү хәтере дә, игътибары да үсмәгәнлеге ачыклана. Аңа дислексия диагнозы куялар. Бу бала белән бары тик вакытында махсус уеннар уйнарга кирәк булган. Баш мие функцияләре кирәгенчә үсмәү югары сыйныфларда проблемага әверелә. Аның никадәр куркыныч булуын аңлар өчен табибның эш тәҗрибәсеннән бер мисал.

Нейропсихологка 6 нчы сыйныфта укыган баланы алып киләләр. Укый алмаганы өчен дәрәҗәле мәктәптән башка мәктәпкә китәргә тәкъдим иткәннәр. Хәтта акыл эшчәнлегендә проблемалары бар дип тамга да салырга өлгергәннәр. «Диагностика үткәрә башлагач, малайның табигатьтән бирелгән акылы барлыгы ачыкланды. Фикерләү сәләте дә камил, мантыйк та эшли. Әмма ул 1–2 нче сыйныф программасын үзләштермәгән. Гап-гади саннар рәтен белми. Мәсәлән, күңеленнән йөздән җидене алу аңа авырлык тудыра. Билгеле, моны белмәгән бала катлаулы мисаллар эшли алмый. Алгебраны да, физиканы да аңламый. Ә проблема гап-гади. Гадәттә, без балаларны шигырь сөйләргә өйрәткән кебек бердән унга кадәр санарга өйрәтәбез. Бу әле саннар рәтен белү дигән сүз түгел. Кайбер балалар 5 саны белән 5 карандашны чагыштыра алмый, саный белә, әмма саннарны дөрес күрсәтми. Моңа игътибарлы булырга кирәк», – ди нейропсихолог.

Баш мие эшчәнлеген дигностикалау һәм коррекция ясауның «алтын

Айсылу ЛЕРОН, блогер, пиар белгеч:

– Нурихан беренче сыйныфка барганда гаилә белән стресс кичердек дип әйтә алмыйм, чөнки бу икенче тәҗрибә иде. Барысына да әзер идек. Нәрсәдер килеп чыкмаса орышмадык, апасы да аңа ярдәм итте. Апасыннан үрнәк алып, үзе дә мөстәкыйль булырга тырышты. Малай кеше шуграк инде ул. Пычранып кайтулар булды. Киемнәр ешрак алыштырылды, юылды. Башлангыч сыйныфларда кием югалтулар еш була инде. Әйберләрен барлап йөрергә өйрәттем. Дәрескә әзерләнгәндә дә сумкасын бергә тутырдык. Мәктәптән кайткач, бүген нәрсәләргә өйрәндегез, дип сораштык. Класста кайбер балалар мәктәптә укырга әзер түгел иде. Шуның белән берникадәр кыенлыклар булды булуын. Җәйге каникуллардан соң балалар үсеп, дәресләрдә утыра алырлык булырлар дип өметләнеп калабыз.



Фото: www.freepik.com

вакыты» – 5–6 яшьләр. Нәкъ менә шушы вакытта баланы тикшерү зарур. Баш миенең кайсы функциясенә нинди ярдәм кирәклеген ачыклап, коррекция ясыйсыз икән, бала мәктәптә белем ала башлагач, үзегезгә үк җайлы булачак. Башлангыч сыйныфларда авырлык белән булса да «куып җитәргә» була әле, ә 12 яшьләрдән соң – мөмкин түгел. Бу яшьтән соң, булган инструментлар белән, энциклопедик белем генә туплана, ә баш мие функцияләре үсми.

Сул кул – тәти кул

Мәктәпкә әзер булмаган балалар арасында ике төрле проблема бар. Берсе туган вакыттагы травмалар белән бәйле булса, икенчесе – вакытында бала белән шөгыльләнмәү. Аннан соң каш ясыйм дип күз чыгарган әти-әниләр дә бар. Сүз – сулагай балалар турында. Җир халкының 15 проценты – сулагай. Бу һәр җиденче кеше дигән сүз. Тик мондый кешеләргә караш башкачарак. Совет заманы шаукымы бу. Тәти кул – уң кул дигән фикерне ишетеп үскән буын без, мәсәлән. Шәхсән үзем көчләп уң кул белән язарга өйрәтелгән бала. Мәктәптә каләмне сул кулга тотмас өчен, ул кулымны артка куярга кушалар иде. Ә бу тамырдан дөрес булмаган, чөнки ул баш мие эшчәнлеген боза. Сулагайлар иҗади, креатив кешеләр, әмма игътибарсызлар. Аларның болай да уңагайларга караганда укуда проблемалары күбрәк. Мәҗбүри рәвештә баланы уң кул белән язарга өйрәтү ул уңагай булачак дигән сүз түгел. Аңа уку тагын да авырлаша, чөнки баш мие эшчәнлегенә көчләп үзгәрешләр кертелә. Бу – бала өчен зур стресс. Ул тотлыга башлый, йә нервлы тик барлыкка килә, астын юешләтү дә шуның белән бәйле булырга мөмкин. «Идеалда сулагай балалар өчен аерым мәктәп ачу яхшы булыр иде, аларга белем бирүдә башка төрле алым кулланырга кирәк. Әмма бу әлегә мөмкин түгел. Сулагай баланы уң кулы белән язарга өйрәтергә ярамый! Табигатькә каршы бармагыз. Кечкенәдән балага игътибар итегез: уенчыкларына кайсы кулы белән үрелә, әйберләрне кайсы кулы белән төртеп күрсәтә, каләмне кайсы кулына тота», – ди Динара Шакирова.

Әти-әни амбициясеме, бала мөмкинлегеме?

Баланы мәктәпкә биргәнче, аның нәрсәгә сәләте барлыгын ачыклау яхшы булыр. «Моның өчен баланы читтән күзәтергә кирәк», – ди нейропсихолог, педагог Нуршат Галимова. Моннан кала, кешенең табигый потенциалын анализлый торган махсус диагностика да бар. Ул баланың нәрсәгә һәвәслеген, фикерләү төре нинди булуын, эмоциональ интеллектын ачыклый. Бу да мәктәптәге тормышны җиңеләйтәчәк. «Бала 5 яшьтән үзенә нәрсә кирәген белә. Әмма без аны ишетмибез, үз амбицияләребезне күчерергә тырышабыз», – ди Нуршат Галимова. Шуңа белгеч баланы ишетергә өйрәнергә киңәш итә.

Баланы ишетү үтә мөһим, бигрәк тә дәрес әзерләгәндә. Өй эшләре бала өчен дә, ата-аналар өчен дә аерым бер зур стресс. Ул инде хәтта мәзәккә дә әйләнгән. «Улым, сиңа бүген өй эше күп бирделәрме?»–«Әни, сиңа бүген кычкырырга да кычкырырга инде» ише анекдотлар, кызганыч, тормыштан алынган хәлләр. Әмма аңладык инде: баланың баш мие эшчәнлеге функцияләре үссә, нәрсәгә сәләтле икәнлеге ачыкланса, «кычкыру» проблемасы бетәчәк. Ләкин күп әти-әниләр бу диагностика турында белми, белеп тә йөрми. Ул бала өчен өй эше эшләүне кулай күрә. «Аңа ярдәм сораса гына булышырга кирәк. Сезнең «бишле»не алганчы, үз «икеле»се йә «өчле»сен алу хәерлерәк. Тик моның өчен баланы ачуланмаска гына кирәк. Ул яныгызга килеп бу хакта курыкмый әйтә белсен», – ди Нуршат Галимова. Күп очракта ата-ана, балама нигә начар билге куйдыгыз, дип, укытучыга дәгъва белдерә. Ул бит баланың белми калуы өчен борчылмый, ә билге өчен көрәшә. Укытучыдан, балам нәрсәне аңламады икән, дип сораштыру дөресрәк булыр, мөгаен.



Илнар ХӨСНУЛЛИН, журналист:

– Аяз мәктәп тормышына бик җиңел кереп китте. Иртән тору, җыенып укырга чыгып китү безнең өчен тамчы да мәшәкать булмады. Тик шуклык артыгы белән бирелгән безнең малайга. Һәрвакыт вакыйгалар үзәгендә булу гадәте бар. Тәҗрибәле һәм сабыр укытучыбыздан хәбәр килгәч, улыбызның тәүге каникулына бер көн кала әтисе кулына каеш алды. Әнисе белән апасы күрмәгәндә, дус белән иптәш арасындагы аерманы аңлатырга тырышып карадым. Дөрес, хатын да, үзем дә баланың, бигрәк тә малайларның тик утырганын күз алдына да китерә алмыйбыз. Әмма мәктәптә төп кеше укытучы булырга тиеш, дигән фикер өстенлек итә. Аяз, апасы кебек, сәгатьләр буе өй эше эшләп утыра алмый. Аның каравы, китап-дәфтәрләр, каләм-фломастерлар, алмаш кием һәрвакыт җыелган булыр. Дөрес, бервакыт артыгын да кыланып куйды. Әти-әниләрнең үзе эшли алмаганны баласына тапшыра торган гадәте бар бит инде. Шулай итеп, Аязны музыка мәктәбенә дә урнаштырдык. Хыялда – әтисе башлап ташлаган баян иде. Әмма сайлана торгач, флейтага тукталдык. Тырыша торгач, ноталар да таныла, көйләр дә чыга башлады. Әмма малайлар флейтада уйнамый икән. Аяз шундый сүз ишетеп кайткан. Безне күндерә алмагач, чыгу юлын үзенчә тапкан. Флейтаны ике өлешкә сүтеп, мәктәпкә яртысын гына алып барган. «20 ел укытып мондый хәлне әле күргән юк иде», – диде укытучысы. Флейта бетергән кәефне футбол белән бассейнда табып, өйгә кайтып җиткән арада онытылган дәресләрне кич әнисе белән искә төшереп, югалган киемнәрне бер атнадан табып, малайлар гына түгел, кызлар белән дә аралашып, мәктәпнең беренче елы узып та китте. Хәзер инде укырга вакыт: балалар бүлмәсендә яңа өстәл барлыкка килде.

Укытучы + әти-әни = дуслык!

Гаджет тотып үскән балаларны укырга җәлеп итү бик авыр. Җитмәсә, бүгенге мәгариф системасында бер сыйныфта 30–40 бала укыткан укытучының һәр укучыга вакыты җитеп бетми, ул аларны укырга уен аша да җәлеп итә алмаска мөмкин. Моның өчен өстәмә өйрәнүләр, белем кирәк. Ә укытучы кәгазь боткасына баткан. Шуңа күрә дә аңа әти-әниләрнең ярдәме кирәк. «Белем бирү – мәктәп бурычы» дип кенә карау дөрес түгел. Балагыз укырга керә икән, дүртенче сыйныфка кадәр аның белән бергәләп шөгыльләнергә әзер булыгыз. Өйдә шөгыльләнмисез икән, мәктәп игътибары гына аңа җитмәячәк.

Казан шәһәренең 18 нче татар гимназиясе укытучысы, 30 ел буе башлангыч сыйныф балаларына белем биргән Гөлфия Насыйбуллина да, укытучы белән әти-әни бербөтен булып тәрбияләгәндә генә нәтиҗә була, ди.

– Иң элек баланың укырга теләге барлыгы, кызыксынуы, кызыксынуы, күзаллавы, сорауларга җавап бирә белүе, аның психологик яктан әзер булуы зарур. Әти-әниләр баланың сөйләменә дә игътибар итсеннәр иде. Кайбер балалар авазларны дөрес әйтми. Бу аларда комплекс тудыра, язган вакытта да авырлыклар китерәчәк, – ди укытучы.

Мөгаллимәнең ата-аналарга тагын бер киңәше: мәктәп тормышында актив катнашу. «Мәктәп яшәешегезнең бер өлеше була икән, бала моңа сөенәчәк. Әти-әниләр дәресләрдә катнашса, төрле мастер-класслар үткәрсә, табигатьтә бергәләп ял итсәләр, бу да бала өчен мотивация булыр. Бала мәктәптән курыкмый, әти-әни үзе борчыла. Ә борчылу балага да күчә. Мәктәп – кызыклы дөнья ул», – ди Гөлфия Насыйбуллина.

Мәктәп – балалар бакчасы түгел. Анда һәр балага игътибар да җитеп бетмәскә мөмкин. Төннәр буе ватсаптагы ата-аналар төркеменә укытучыны, мәктәпне сүгеп язганчы (ә кирәкме соң ул ата-аналар оештырган мәктәп чаты? Шәхсән үзем ул чатка килгән хәбәрләрне укымыйм. Билгеле бер чара өчен акча җыярга кирәк булса, шалтыратмый калмыйлар. Ә мәктәп программасы турында кемнең нәрсә уйлавы миңа бөтенләй кызык түгел – Ч. Г.), бала белән шөгыльләнсәк, һич булмаса, бергәләп әдәби китап укысак йә берәр кызыклы кино карасак, аның киләчәк тормышы өчен файдалырак булыр иде. Мәктәпне, укытучыны хөрмәт иткән әти-әнинең генә баласы үз остазына хөрмәт белән карый. Билгеле, остаз укучыларын яратса. Баланың күңелендә беренче укытучысы, беренче мәктәп еллары турында матур хатирәләр калдыру бары тик бездән һәм укытучыдан тора.

Гүзәл БАҺ, җырчы:

– Беренче улыбыз тынычрак иде, уртанчысы шуграк, урынында тик утыра алмый. Шуңа күрә мәктәпкә киткәч, тәртибе буенча шактый проблемалар булды. Улыбызга өйдә һәрвакыт аңлаттык. Шөкер, ел ахырына мәктәп кагыйдәләренә күнекте. Укый башлагач, кичке тугыздан калдырмый йокларга яткыра башладык, чөнки көне буена бик арыйлар. Өй эше бирмәсәләр дә, өйдә текстлар укыттык, күчереп яздырдык. Шәхсән үзем беренче сыйныфтан ук укый башлау гадәтен кертү яклы мын. Беренче көннән үк сумкасын үзенә тотырырга өйрәттек. Җаваплылык нигезе шуннан башлана ул. Өй эшләрен башкарганда балалар белән үзем утырам. Кызуканлылык белән эш итәргә ярамый, аңлашып, тыныч кына утырырга кирәк. Бер кеше дә белеп тумаган. Ул бит бала! Үзем дә укыткач, күрәм, баланың үзен тотышыннан, өс киеменнән үк өйләрендәге атмосфераны аңлап була. Мәктәпкә бөтен нәрсәне бала өйдән алып килә. Өйдә иң элек гармония булырга тиеш.



Белгеч киңәше



Солтания ГАТАУЛЛИНА, психолог

- Ике атнага булса да, беренче сентябрьгә ял алырга тырышыгыз.
- Сентябрь-октябрьгә кардиналь үзгәрешләрне планлаштырмагыз.
- Онытмагыз: бала хата ясарга да хокуклы.
- Беренче сыйныфта баланы спорт секцияләренә яки түгәрәкләргә бирергә тырышмагыз. Әгәр сезгә музыка һәм спорт белән шөгыльләнү тәрбиянең кирәкле бер өлеше булып тоелса, түгәрәкләргә уку башланганчы бер ел кала яки беренче сыйныфның икенче яртыеллыгыннан йөртә башлагыз.
- Мәктәп кагыйдәләрен һәм нормаларын бала белән тикшерегез. Аларның кирәклеген һәм максатын аңлатыгыз.
- Балагызга мәктәптә төрле укучылар булачак дип аңлатыгыз. Ихтимал, ул барысы белән дә дуслашып китә алмас. Балалар арасындагы конфликтлар, әлбәттә, котылгысыз, бу очракта кискен рәвештә шелтә белдермәгез, ике якны да аңларга тырышыгыз. Укытучы белән элемтәдә булыгыз.
- Көн тәртибен төзегез, аның үтәлешен бергәләп күзәтегез. Булачак беренче сыйныф укучысына яңа режимны мәктәпкә кадәр үк өйрәтә башлау яхшырак, акрынлап йокы вакытын көйләгез. Балагыз кичке тугыздан да соңга калмыйча, шул исәптән ял көннәрендә дә, йокласын өчен ныклык һәм үз сүзегездә торуыгызны күрсәтергә туры киләчәк. Йокларга сәгать ярым кала телетапшырулар карауны һәм шау-шулы уеннарны туктатырга кирәк.
- Бала өчен өй эшләрен эшләмәгез. Ярдәм сорап килсә генә булышыгыз. Кечкенә генә уңышлары өчен дә мактагыз, аны ничек бар шулай кабул итегез. Иң мөһиме: билге түгел, балагызның бәхетле, сәламәт булуы. Һәрвакытта балагыз яклы булыгыз.



Фото: Анна Арахамия

АК ГӨЛЛӘРДӘН ҖАН ҖЫЛЫСЫ АЛЫП...



Алсу
ШАКИРОВА

Яшьлек килә! Җиңел дә ул, дәртле дә! Кыю, чибәр! Ә күңеле – сайлаган һөнәренең символы булган ак чәчәкләрнең үзе кебек – самими, чиста, пакь. Алдында – чиксез мөмкинлекләр. Барыр юллары сикәлтәле булса да, җиңәрлек ул. Яшьлек килә! Һәм... юл бирәсе килә бит! Ромина САДЫЙКОВА кебекләргә юл биреп, өметле күзләр белән артыннан карап каласы килә...
2006 елда ук 8 яшьлек бәләкәй Роминаның «Сөембикә» журналының юбилей саны тышлыгына эләгүе очраклы булмаган. Татарстан белән генә чикләнмичә, Россиякүләм һәм халыкара матурлык бәйгеләрендәге җиңүләре белән Татарстанны, аның традицияләрен, мәдәниятен дөньяга таныткан Ромина ул.
Уналты ел узган! Бүген безнең тышлыкта – яңа Ромина. Кулындагы И. М. Сеченов исемендәге Беренче Мәскәү дәүләт медицина университетының кызыл дипломы – яңа уңышлары шаһиты.

Ромина, исемең гадәти түгел. Кем сайлаган?

– Бу исемне әти-әнием бик ошаткан. Ләкин исем кушучы мулла хупламас дип шикләнгәннәр. Исем кушучым – Мәрҗани мәчетендәге бик гыйлемле, хөрмәткә лаек Габделәхәт хәзрәт: «Әйбәт исем, кушабыз! Ромина – борынгы татар исеме, максатына туры тидерүче, теләгәненә ирешүче мәгънәсен аңлата» – дигән. Гомумән, безнең гаиләдә исемнең мәгънәсенә бик зур игътибар бирелә. Әби-бабаларымның исемнәре нәрсә аңлатканын да кечкенәдән белеп үстек.

2006 елда «Сөембикә» журналы тышлыгында чыкканыңны хәтерлисеңдер. Ул вакытта ук, уңыш арты уңышка ирешеп, сәхнәләрдә зур хезмәт куеп үскәнсең. Халыкара бәйгеләрдә ил данын яклау, чыннан да, тырышлык, үҗәтлек сорый. Ә син әле бала гына...

– Балачагым искиткеч матур үтте. Үземне гел принцесса итеп тойдым. Өйдә дә, сәхнәдә дә, гомумән, тормышта да. Әти-әниемнән алган бу җылылыкны, мәхәббәтне гомер буе саклыйсым, үз балаларыма да бүләк итәсем килә. Бакчага сирәк йөрдем. Күп вакытым әниемнең әнисе – Рәхимә әбием янәшәсендә үтте. Бәләкәй чакта нигәдер яшьтәшләрем белән аралашырга яратмадым мин. Олылар белән сөйләшү күпкә кызыграк тоела иде. Бу гадәтемә әни бераз борчыла башлады хәтта. Яшьтәшләре белән аралашсын дип, мода театрына алып барды. Миңа ул вакытта 4 кенә яшь иде әле. Кастинг вакытында подиумга чыкканымны хәтерлим. Шулкадәр ошаттым! Әһә, минем урын шушында икән, дип уйлап куйдым хәтта. Шулай да беренче бәйгедә сәхнәгә чыккач, зал тулы кеше күреп елап җибәрдем. Ә бүләкләү тантанасына сәхнәгә чакыргач, мин инде елмаеп кына тордым. Кулыма зу-ур чәкчәк тоттырып куйдылар. Авырлыгы! Ә мин моны сиздермим, профессионалларча елмаерга тырышам.

Аннары Сочи, Мәскәү, Лондон, Каһирә кебек башка шәһәрләрдә җиңүләр яуладым. «Нәни мисс Вселенная» исемен яулап, «Мисс Вселенная» Оксана Федорова белән эшләргә туры килде. Ангелина Вовк, Инна Чурикова кебек танылган шәхесләр белән эшләү бәхетенә дә ирештем. Алар тормышымны театр белән бәйләргә тәкъдим иттеләр хәтта. Ләкин 11 яшемдә бу юнәлештә үсүемне дәвам итү теләгем калмаганын аңладым. Ул көнне әни әле дә искә ала. «Бер әйтүең белән дәлилли белдең», – ди.

Гомеремнең бу чоры бик күпкә өйрәтте мине. Чын тормыш мәктәбе уздык анда. Матурлык, тышкы кыяфәт белән генә чикләнмичә, һәр чыгышка тирән мәгънә, идея салып әзерләделәр бәйгеләргә. Безнең белән профессионаллар командасы эшләде. Кая гына барсак та, Татарстанны бөтен байлыгы, муллыгы, матурлыгы, куәте белән күрсәтергә тырыштык. Читек кисәк – Арчаныкы, хәситә таксак – чын көмеш тәңкәлесе, пуанте, пачка тектерсәк – Зур театрда, музыка яздырсак – танылган композиторлардан. Кулда гел чәкчәк иде минем. Бик күп дәрәҗәле кешеләр, жюри әгъзалары күңеленә ачкыч табарга ярдәм итте бу милли ризык. Уңышларымны күздә тотып, төрле тантаналы чараларга чакыра башладылар. Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев, мине танып, яңа җиңүләрем белән котларга онытмый иде. Әтиләрчә куанып: «Син тагын җиңгәсең бит!» – дип, иңнәремнән кочаклый. Мода театрында алган белемнәр үз-үземә ышанычны арттырды. Әле дә халык алдында чыгыш ясарга курыкмыйм, үземне тота белләм.

Мондый тыгыз графикта «эшләр» өчен нинди мәктәптә укырга кирәк соң? Җитмәсә, киләчәктә иң көчле уку йортларының берсенә керерлек тә булсын әле...

– Беренче сыйныфтан Казанның 18 нче мәктәбендә белем алдым. Шулкадәр яратам мәктәбемне! Бервакыт аны башкага алыштырырга туры килде. Бик яхшы заманча мәктәпкә урнаштырдылар мине. Ләкин үз мәктәбемне оныта алмадым... Ничек итсәм иттем, кире үз мәктәбемә күчерделәр. Мин моның белән бик горурланам! Казанның иң яхшы мәктәбе дип саныйм мин 18 нче мәктәпне. Башка беркайда да булмаган үз традицияләре бар аның. Баланың потенциалын күреп, үстерә беләләр, тормышта үз урынын табарга ярдәм итәләр. Чын шәхесләр тәрбиялиләр. «Иң мөһиме – катнашу түгел, җиңү!» дип, лидерлар үстерәләр. Табиб белгечлеген сайлаган укучылар да күп чыга аннан. Директорыбыз – Надия Мәсгут кызы Шевелева көчле укытучы гына түгел, искиткеч кеше дә. Мәскәү шәһәрен күңелемә салган остазым ул. Хәзер мәктәп бераз үзгәргән инде, ә мин шул коңгырт баскычлы мәктәбемне әле дә сагынып искә алам...

Табиб һөнәрен сайлавың да очраклы түгелдер... Әниең – танылган галимә, медицина фәннәре докторы, профессор Эльмира Минһаҗева. Үз-үзеңә таләпләрне дә югары куясыңдыр?

– Әйе, бу даирә минем өчен бик якын, шул мохиттә үстем. Әни миңа һәрвакыт үрнәк булды. Табиб – хатын-кыз өчен дә, булачак әни өчен дә иң яхшы һөнәр дип саный идем. 3 яшьтән әнигә ияреп аның эшенә йөри башладым. Казан медицина университеты баскычларыннан менеп-төшеп уйнаганда үземне шунда укучы студент итеп хис итәм. Ак плащымның итәкләре җилфердәп торырлык итеп университет коридорларыннан кызу-кызу атлап йөрергә дә ярата идем. Имеш, мин табиб, өстемдә ак халат... Әле дә берни үзгәрмәгән икән! Мин әле дә шулай йөрергә яратам!

Әни – минем өчен авторитет. Нишләсәм дә, аның кебек була алмам төсле. Шул ук вакытта әнине кабатларга теләмим, үз юлымда уңышка ирешәсе килә. Шуңа күрә белгечлек сайлаганда да башка юнәлешкә өстенлек бирдем. Алай гына да түгел, әнинең уңышларын миңа тамгаламасыннар өчен, 18 яшем тулгач фамилиямне дә алыштырдым. Әлбәттә, әти-әни ризалыгы белән. Хәзер мин нәселебез фамилиясен йөртәм. Студент тормышын яңа фамилия белән яңа шәһәрдә башладым.

Абитуриент Ромина һәм дипломлы Ромина бер-берсеннән аерыламы?

– Бик нык аерыла! Казанда укыйсы килә иде бит минем. Мәскәү дип бөтенләй хыялланмадым. «Тәвәккәлләп карыйк, ошамаса кире кайтырга беркайчан да соң түгел», – дип тәкъдим итте әни. Кулда юллама да бар, баллар да җитәрлек, алтын медаль белән тәмам-



ладым мәктәпне. Ә күңел Казан дип өзгәләнә… Утырам университет алдында елап. Минем каршыда, шундый ук эскәмиядә минем кебек үк абитуриент кыз елап утыра. Телефоннан сөйләшә: «Бу минем иң зур хыялым иде бит, ничә ел көтеп яшәдем, әзерләндем, ә баллар җитми, керә алмыйм», – дип елый. Ә минем барысы да җитә, теләк кенә юк. Язмыш ирониясе…

Беренче сессиядән соң, чыннан да, кайтырга да уйлаган идем. Чит шәһәрдә берүзем. Университетның күпсанлы корпуслары бөтен Мәскәү буйлап таралган. Бер пар белән икенчесе арасы – сәгать ярым. Студентлар барып җитеп өлгерсен өчен шулай эшләгәннәр. Шуңа күрә уку көне иртәдән кичкә кадәр сузыла. Саллы медицина китапларын, атласны, киемнәрне күтәреп, Мәскәүне аркылыга-буйга йөрисең. Төркемдәшләр белән метро янында очрашабыз да корпус эзләргә китәбез. Югалып йөрибез, соңга калабыз кайчак… Юлга бик күп вакыт китә, шунысы ардыра иде. Беренче курста шимбә көнне дә укый идек әле. Киләсе атна расписаниесе буенча лекцияләргә әзерләнергә бер якшәмбе көн кала. «Нигә болай азапланам соң? Казанда да шул ук белемне алыр идем. Нәрсә җитми соң миңа?» – дип аптырамаган көнем сирәк булгандыр. Беренче курсны тәмамлаганда мин инде башкачарак, төптәнрәк уйлый башладым. Мондый мөмкинлек бөтен кешегә дә бирелми, аны кулдан ычкындыру юләрлек булыр дип фикер йөрттем.

Медицина юнәлешен сайлаган студентлар белем алган китап авторлары минем укытучыларым, белемне беренчел чыганактан алдым. Дипломлы, квалификацияле белгеч буларак хәзер үзем белән горурланам. Мәскәү университетындагы укуга караш та бик ошый. «Тигезләр арасында беренче» диләр аның турында. Күбрәк үзлектән өйрәнергә туры килде фәннәрне. Коллоквиумнар, укытучы белән әңгәмәләр еш уза, хәтта дискуссиягә керү дә тыелмый. Мин хәзер аңлыйм: вакытында тәвәккәлләп, «комфорт зонасы»ннан чыгуым үз җимешләрен бирде. Бирәчәк тә әле! Иң мөһиме – үзеңне җиңәргә кирәк. Ә Казан медицина университетына килгәндә, чыннан да, Россиядә аның дәрәҗәсе дә, рейтинглары да югары.

Буш вакытыңны ничек уздыра идең? Казанны сагындыңмы?

– «Тусовкалар» – медуниверситет студентлары өчен сирәк бәхет. Күбебезнең моңа вакыты юк иде. Дүшәмбе иртәнге сигездән башланган уку шимбә кичке җидегә кадәр бара. Бер ел тирәсе укыгач, туган телемне бик нык сагына башладым. Метрода барганда бер татар сүзе ишетелсә дә, колак шундук тотып ала. Бер станциядә татар көе ишетеп, төшеп тә калганым булды. Метродан чыгып, шул көй ишетелгән якка йөгердем. Чыннан да, бер егет гитарада татар көе уйнап утыра икән… Мәскәүдә «Татар җыры» концерты узган көннәрне Кремль тирәсе татар сөйләменә тула. Ә без шунда якында гына укыйбыз. Йөрәгемә май булып ята туган тел! Шулкадәр горурланам, сөенәм, сагынам!

Шулай итеп, мөмкинлек булганда Татарстаннан килгән студентлар белән дә, башка төбәктән чыккан татарлар белән дә таныша, аралаша башладым. Бергә булырга тырышабыз, бар чараларга йөрибез. Ләкин бу очрашуларыбызның бер формасы юк иде. Бервакыт университетта укучы танышларым тулай торакка кунакка чакырды. Нинди ризык белән сыйларга икән дип баш ватам. Югыйсә өйдә – фатирда гөбәдия, өчпочмак, бәлеш пешерүнең бер кыенлыгы юк миңа. Ләкин тулай торакта мич юк. Кыстыбый пешерергә булдым. Башка төркемдәшләр дә килгән иде. Кайсыбызны кырып карасак та, татар инде без, дип шаярта-шаярта кыстыбый ашадык. Шуннан соң якташ студентлар оешмасы булдыру идеясе туды да инде. Татарстанның Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиллеге аша рәсмиләштереп, университетта укучы студентларны, укытучыларны, укып чыккан табибларны берләштергән татар якташлыгына «Ак чәчәкләр» исеме бирдек. Рәисе, нигез салучысы буларак, «Ак чәчәкләр»не мин җитәкләдем. Оештыру эшләрен, якташларга ярдәм итү, төрле чараларда катнашу буенча эшчәнлекне җәелдереп җибәрдек. Татар мәдәниятен һәм татар милли ашларын тәкъдим итә алуыбыз белән горурланам! Мәсәлән, Сеченов исемендәге университетта узган Unity Food Fest гастрономик фестивалендә катнаштык. Укуны тәмамласам да, «Ак чәчәкләр»не кураторлыкка алырга телим. Минем кебек чит шәһәрдә берүзе калган ватандашларым, татарстанлылар өчен дә файдалы булыр идем. Монда дуслар бар, монда ярдәм итәчәкләр, син берүзең түгел – яшь студентлар, абитуриентлар шуны белсен иде.

«Минем Казаным» һәм «минем Мәскәү». Синең өчен нинди алар?

– Минем Казаным – җанны җылытучы, йомшак, ягымлы, рәхәт, йөрәккә якын. Казанда һава да икенче төрле, исе үк башка аның… Минем Мәскәү – актив,

ыгы-зыгылы, тиз ритмлы, кызыктыручан, ләкин сине якын китерми, һәрвакыт дистанция тота.

Сезнең чор студентларына пандемия вакытында укырга туры килде. Синең өчен сынау чоры булдымы ул, әллә яңа мөмкинлекләр ачылдымы?

– Ковид белән бәйле чикләүләр медицина юнәлешендә укучы студентлар өчен башка сыймаслык киртәләр тудырды. Без дә берара читтән торып укуга күчтек, пациентлар белән эшләү чикләнде. Табиблыкка укучы студентлар дүртенче курстан соң шәфкать туташы булып эшли ала инде. Тәҗрибә туплар өчен, чикләүләрне ничек тә урап узар өчен кардиология бүлегенә һәм реанимациягә эшкә урнаштым. Дежурлыкның, тәүлек буе эшләүнең нәрсә икәнен шунда белдем. 20 минут кына йоклап алырлык та вакыт булмады. Төне буе пациентлар кабул итеп, анализлар алып, карточкалар тутырып, системалар куеп чыгасың да иртән укырга китәсең. Бик яхшы тәҗрибә булды ул минем өчен. Шәфкать туташы эшен белгән табиб башка төрле инде ул, күп әйбернең сыйфатын контрольдә тота ала, дәвалауның нәтиҗәсе дә уңай була.

Ковид белән авыру артып киткән чорда волонтер булып Татарстанга кайттым. Аннары университеттан практикага җибәрделәр. Кызыл мәйданда урнашкан ГУМда вакцина ясау пунктына ике кеше кирәк икән! Без дустым белән бик теләп риза булдык. Мәскәүдә ачылган иң беренче, иң зур пункт иде ул. Минем өстәл аша көн саен 100 дән артык кеше үтте. Кремль хезмәткәрләре дә, танылган кешеләр дә ясатты вакцинаны. Бик җылы хисләр калдырды ул. Көн саен унике сәгать эшләү дә ялыктырмады безне. Кызыл мәйданда эшләве ни тора бит! Шуңа күрә пандемия чорын да үз файдама куллана алганыма сөенәм. Мин үземне башка яктан ачтым, үзгә тәҗрибә тупладым. Һәрнәрсәнең хәерлесе бар!



«Үзәк телевидениедән еш кына корреспондентлар килеп сюжетлар төшереп китәләр. Мине, шаяртып, «Россиядәге вакцинациянең рәсми йөзе» дип атый башлаганнар иде хәтта».

Табибларның эш сәгатьләре чикләнми гадәттә. Син үзеңне тулысынча эшеңә багышларга әзерме? Бәлки, әниең юлыннан китеп, фәнни медицинаны сайларсың?

– Тормышта һәрнәрсә баланста булырга тиеш дип саныйм. Табиб – минем һөнәрем, эш ул. Кеше тормышын рухи яктан үсүгә, гаиләгә, балаларга, үзенә, сәламәтлегенә, әлбәттә, эшенә дә тигез бүлергә тиеш. Төрле юнәлештә үскән кеше генә камиллеккә омтыла ала. Шул балансны сакламау, бер юнәлештә генә үсү киләчәктә проблемаларга китерергә мөмкин. Хәзер мин дипломлы, аккредитация узган белгеч, табиб булып эшли башлауга бернинди киртә юк. Ләкин мин ординатурада укуны сайладым. Узган юл белән чагыштырганда ике ел күп тә түгел бит. Хыялым – Мәскәүдә тагын да зур тәҗрибә туплап, шул белемнәрем белән Татарстанга кайту. Мин сайлаган белгечлек бездә бик кирәк булачак, анысын төгәл беләм. Татарстанга файдалы буласым килә. Республика җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов та шулай ди бит – өйрәнеп кайтып, белемне монда кулланырга кирәк. Бернәрсә дә очраклы түгел. Безнең университетның слоганы да, беләсезме, нинди? «Чтобы расти – надо держаться корней». Никадәр мәгънә салынган бу сүзләргә! Аларга нәсел тамырлары да, туган җир дә, укытучылар да, остазлар да, тормыш кыйммәтләре дә сыйган. Бу сүзләр минем күңел түрендә...

Мәскәүдә яшәүче татар кызы шәхси тормышын кора аламы? Татар егетләре белән кайда танышырга була?

– Теоретик яктан моңа бер киртә дә юк. Әйткәнемчә, Мәскәүдә Равил Әхмәтшин җитәкчелегендә Татарстанның вәкаләтле вәкиллеге эшләп килә, анда Яшьләр советы оештырылган. Мәскәү татарлары автономиясе бар. Татар мәдәни үзәге урнашкан атаклы Асадуллаев йортын белмәгән кеше юктыр. Яшьләр өчен бик күңелле чаралар уза ул үзәктә. Анда танышырга да, уйнарга да, аралашырга да була. Яшьләр өчен ифтарлар уздыралар, никах нигезләре белән таныштыралар. «Что? Где? Когда?» тапшыруы форматында бик кызыклы «Чикләвек» уены уздырыла, минем дә катнашкан булды. Анда ачылып китеп уйныйбыз: холыклар, көчле яклар сизелә. Бик лаеклы, укымышлы, тәртипле, акыллы егетләр бар. Шулай да Мәскәү татарлары Казан татарларыннан бераз аерыла. Әйе, охшаш яклар күп, телебез бер, ләкин үзебезнең Татарстан егетләре күңелгә күпкә якынрак. Безнең традицияләр, гореф-гадәтләр, кечкенәдән әби-бабайлардан күреп үскән үрнәкләр бер үк. Шундый гаилә кора алсам, бәхетле булыр идем.

Дусларым арасында гаилә төзүчеләргә карап сокланам. Укуны тәмамлагач, үз гаиләм турында ешрак уйлана башладым. Ә минем йөрәк... әлегә үз тиңен эзли. Һәрнәрсәнең үз вакыты, диләр. Килешәм.

Хәерле юллар сиңа, Ромина! Ак чәчәкләрнең яктысы барыр юлларыңны җылытсын! Шәхси тормышыңда да, һөнәр юлыңда да бәхет юлдаш булсын!

БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛГӘ «ШАХТА» КӨЕ СЕҢГӘН!

Концерт килде безнең Ташлыкка. Мине алып бармадылар. Бала-чаганы гомумән клубка кертү юк иде! Бик яхшы тәрбия булган ул. Әле ул вакытларда яшьләр дә, өлкәннәр дә бер дә сүгенмиләр, тәмәке тартмыйлар иде. Тәртип булган авылда. Кешеләрнең яшәеше ниндидер бер калыпта ага. Яшьләргә тәрбияви карыйлар. Кычкырып сөйләшсәң, матур гына итеп ярамаганын аңлаталар. Тәмәке күрделәрме – беттең син! Ә эчкән кеше бөтенләй авылдан ук сөрелергә мөмкин. Без шулай булырга тиешлегенә ышанып үстек. Урлашу, караклык бөтенләй булмады. Кешеләр җор телле, гел мәкаль белән сөйләшәләр иде. Сөйләмне төгәлрәк, тулырак итә ул. **АВЫЛ КЕШЕСЕНЕҢ БӨТЕН ТОРМЫШЫНА, ЯШӘЕШЕНӘ АЕРЫМ БЕР ТӘРТИП ХАС.**

Бабай белән әби сугышка кадәр Кронштадтякларыннан кайтып төшкән. Культура бар иде аларда. Бабай председатель булган кеше, аны сөргенгә сөрәсе булганнар, ул, йортын сатып, ычкыну ягын караган. Китеп, әйбәт кенә урнашканнар. Озак та үтмәгән: «Мәликә, сугыш исе килә, кайтмый булмый!» – дигән әбигә. Кире әйләнеп кайтканнар. Аннары Зиннур бабай кабат сугышка киткән. Волхов фронтында әсирлеккә эләккән. 1953 елда гына авылына әйләнеп кайта алган ул. Сталин үлгәннән соң, пленда булганнарга да медаль биргәннәр. Аңа да керттеләр. Менә шунда бабайның елаганын күрдем. Бабай кебек көчле кешенең күзендә яшь күрү мине әллә нишләтте! Рәнҗегән иде ул. Сугыштан кайтканнан бирле эш бирмиләр бит аңа. Председатель булган кеше... Анда бара, монда бара. Шабашкаларда йөри, Ташкентларга китә... Йорт тергезәм дип, акча эшләп йөргән инде. **ҮЗ ҖИРЕҢДӘ КИРӘКСЕЗ БУЛУДАН ДА АВЫРЫ ЮКТЫР.**

Бәрәңге алабыз. Сугыштан кайткан эти протез аяклары белән казып китә, җилләсен диптер инде. Парторгмы, авыл советы рәисеме ул шунда... Һәм кинәт кичкә көчле яңгыр килә. Мал-туар кайта, көтүне каршыларга кирәк, сыерны, сарыкларны кертәсе... Укытучы әнинең дә вакыты юк. Берүзе кайсын карарга белми. «Улым, булыш инде», – ди. Минем уенга чыгып таясы килә, урам каера. Мыр-мыр киләм. Шунда әни ялгыш үсеп чыккан бер көнбагышны төбе-тамыры белән кубарып алды да шундый итеп китереп бәрде сыртка! «Әни, әни, ни, булышам...» – дип ничек әйткәнемне дә сизми калдым. Әнигә нинди авырлык китергәнемне аңладым. Шул вакыт акыл кереп калды. **КЕШЕГӘ АКЫЛ КЕРТЕР ӨЧЕН СҮЗЛӘР КИРӘКМИ ИКӘН.**

Өйдә эти ике әйтеп тормый: бер генә карый иде. «Әтиегез!.. Әтиегезгә әйтәм!» – дип куркыта иде әни дә. Сугышмыйча кайткан юк иде анысы. Елап кайтсаң, эти бер генә тондыра – капка астына кереп китәсең. **СУГЫШУЫН СУГЫШТЫК, ЛӘКИН КАПКАНЫҢ ТЕГЕ ЯГЫНДА БЕТӘРГӘ ТИЕШ ИДЕ УЛ.**

Күрше малайлары белән өелеп торган бүрәнәләргә утырып уйныйбыз-уйныйбыз да арыйбыз. Гыйльмулла Җәүдәте кереп китә өенә. Кара ипигә тоз сибеп чыга. Авыз сулары килә инде. Бер генә каптыр әле, дисең. Каптырмый. Бертуганнар Равил белән Назыйм черек бәрәңгедән пешерелгән көлчә алып чыгалар. Мәгъсүмҗан әйтә: «Назыйм, каптыр әле бер генә. Сугышканда яклар идем сине», – ди. «Сфера влияния» бүлешәләр шулай. Мин дә өйгә кереп китәм. Әни үзе пешергән күмәчне калын итеп кисә дә сыпырып кына май яга. «Чыккач, иң беренче Мәгъсүмгә каптыр. Аннары башкаларга...
ҮЗЕҢӘ ЗУР ӨЛЕШ КАЛДЫРМА!» – ди. Үзе ачык тәрәзәдән чәчәкләр арасыннан нишләр икән дип карап тора. Мин инде әз-әзләп каптырып йөрим. Миңа рәхәт! Дусларны сыйлыйм бит! Мине сугышканда бөтенесе яклаячак болай булгач.

Без үскәндә авылда бала-чага күп була иде. Солдатка озатканда 25–30 егет җырлап килә. Гармунчы – бер яктан, яшүсмер егетләр, алабута, кычыткан өзә-өзә, кырыйдан бара. Аларга да тиздән бу көн киләчәк. Без, 40–60 лап бала – алар артыннан... «Китә җаныем Донбасска...» – дип җырлыйлар. Җырның сүзләрен белмибез, көтеп барып, «шул!» дигән җирендә генә кушылабыз. Шул вакытта салам түбәле бәләкәй йортлар дер селкенгәндәй була. Менә шундый вакытта нинди дошман керсен безгә! «Шахта» көе нинди патриотик көй, бер уйласаң! Безнең күңелгә «Шахта» көе сеңгән! Милләт, татар булу белән горурлану... **БЕРКАЙЧАН БЕРКЕМГӘ БАШ БИРМӘ! ШУНЫ БЕЛЕП ҮСТЕК БЕЗ.**

Авылда оста баянчылар күп иде безнең. Минем дә шулар кебек уйныйсым килә. Әти тальян алып кайтып бирде. Ул җиде ел эленеп торды чөйдә. Беркөн кайтты да, таптым мин моңа хуҗа, ди. «Әти, әти, тимә, мин уйныйм», – дип, кулына барып ябыштым. **ҺӘР ӘЙБЕРНЕҢ КАДЕРЕ ЮГАЛТА БАШЛАГАЧ КЫНА БЕЛЕНӘ ИКӘН.** Сәер генә карап торды да, уйнасаң уйна инде, диде. Аның эштән кайтканын гына көтеп торам да тальянны шыгырдата башлыйм. Анда, монда басам. Ишетәм инде: тыңлап тора. Туйдыра бит инде ул әйбер. «Улым, бүгенгә

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, җырчы, баянчы, популяр көйләр авторы, режиссер, язучы, журналист, пародист, юморист Алмаз ХӘМЗИНның тормыш кагыйдәләре



Фото: Анна Арахамия

җитәр инде!» – ди. Әти кайта дип шулай утыра торгач, «Умырзая»ны эләктереп алдым. Ул катлаулы түгел, гел бер үк телләргә басасы. Беркөнне әти кайтты да протезлары белән йөгереп керде сөенеп: «Була бит, улым, була! Молодец!» Аннары бию көен дә өйрәндем. Әти инде шундук хромка да алып кайтып бирде. Бик тиз өйрәндем хромкада да, чөнки азарт барлыкка килде бит. Аннары озак та үтми каяндыр табып баян да алып кайтты. Шулай итеп, авылның беренче баянчысы булып киттем.

Берзаман бездән ерак түгел Түбән Кама шәһәрен сала башладылар. Яктыга чыккан тараканнар шикелле, Шәңгәлче мәктәбеннән шунда киттек, бер авыз сүз урысча белмичә, шәһәр мәктәбенә күчтек. Интернатта бер рус малае гармун алып килде. «Уйнап карыйм әле», – дим. Өйдә гармуным бар иде бит. «Ты же татарин. Как ты можешь играть? Это же русская гармонь!» – ди. Алдым да уйнап җибәрдем, күзе шар булды! «Малайлар, карагыз әле, минем гармун татарча уйный!» – дип кычкыра. Хәзер дә аңлатма бирә алмыйм моңа. **РУС ГАРМУНЫН ДА ТАТАРЧА УЙНАТЫРГА БУЛА!**

9–11 классларны Түбән Камада укыдык. Разил Вәлиев белән бер партада утырдык. Ул – стена газетасы редакторы, мин рәссамы идем. Мәктәптә безгә һөнәр дә бирделәр. Штукатур-маляр булып, үзебез ремонтлар ясарлык булып чыктык. Мәктәпне ремонтлаган өчен безне Волгоградка экскурсиягә дә алып бардылар әле. Соңыннан, фатирлар алгач, Разил дә, мин дә ремонтларны үзебез ясадык. **БЕЗ ЭШЛӘП ҮСТЕК. БЕЗНЕҢ БУЫН БЕРКАЙЧАН ДА, ЭШЛӘТЕП ИНТЕКТЕРӘЛӘР, ДИП ЗАРЛАНЫП ЙӨРМӘДЕ.** Әти-әниләр дә сүзләмәде. Хәзер ата-аналар үзләре тәрбияли алмаган баласын мәктәпкә бирә дә мәктәптән таләп итә башлый.

Урып-җыю чорында – комбайнга, язгы чәчү вакытында культи артына утырырга кызыга идек. Тугызынчы класста машина белән амбарга капчыклап ашлык китерәбез, төне буе ташыйбыз. Салам өюләр, печән чабулар безнең җилкәдә. Амбарга ашлык ташыган вакытта әти «Урал» мотоциклында бер капчык бодай алып кайтты. «Улым, менә бу синең беренче эшләп алган акчаң», – ди. «Безгә дә бирәләрмени?! Шуның кадәр күп итепме?!» – дип шаккаттым. Күзгә яшьләр килә. **БЕЗ АКЧАГА ЭШЛӘРГӘ ӨЙРӘНЕП ҮСМӘДЕК.** Ә хәзер «бишле» алган саен акча бирәләр балаларга.

Киттек Казанга укырга. Минем әти башта ук председатель буласың, диде, өзми-куймый авыл хуҗалыгы институты турында сөйләде. Мин аны аңлыйм. Ул вакытта председатель иң зур авторитет иде бит! Ә минем анда барасы килми. Күңелдә – Алабуганың культпросветы, кәпрәеп гармунда уйнаулар... Авыл хуҗалыгына кердем керүен. Җыр, бию түгәрәкләренә рәхәтләнеп йөрдем. Курс ярым укыдым да әле. Җан тартмый инде. Институттан киткәч тә документны бирми йөрттеләр. Шимбә-якшәмбеләрдә цирк төзелешендә эшләп, аккордно акчалар да алдым. Ике көнгә алты тәңкә эләгә – бу хәйран акча иде ул вакытларда. Әти миннән ваз кичте. Әни инде, «нишлисең соң син анда, бала?!» дип, яшереп кенә акча җибәрә торган иде. «Борчылмагыз, үзем җаен табам», – дип, КХТИ ректоры Кирпичниковка кереп киттем. «Сездә укыйсым килә, сездә – хор бар...» – дим. «Сельхоз» бик яхшы вуз бит. Әйбәт инженерлар чыгаралар. Шунда укы. Хорга безгә йөрерсең», – ди ректор. Минем барыбер укымаска исәп! Хорлар сәбәп кенә бит! **ҮЗЕҢНЕ ТАБУ ӨЧЕН ҖАН ТАРТУ КИРӘК.** Төзелеш институтының промышленность-гражданлык факультетына кичке бүлеккә кереп, көндезләрен балта осталары белән эшләп йөрим. Беләм ул эшне. Бабай белән йортлар салган бар. Үзем төзеп йөргәч, фатир да алырмын әле дип өметләнәм. Бергә эшләгән абзый: «И энем, квартира бирә торган булсалар, 25 ел эшләп мин алган булыр идем инде. Әле һаман бирмиләр!» – димәсенме! Башка бәрде! Бетте! Җитмәсә, армиягә повестка килеп төште!

Армия хезмәтен Грузиядә – ракета гаскәрләренең космик частенда үттем. Яшерен серләрне саклаучы бик кирәкле кеше идем мин! 0-10 дигән бик мөһим приказ бар, шуңа гына буйсынам! Унбишләп сейф. Ачкычлар, печатьләр – кесә тулы, галифе чалбар тутырык. Яшерен мәгълүмат саклангач, өчәр-дүртәр катлы ишекләр, тәрәзәләр дә пәрвез шикелле. Сигнал проводкалары сузылган... Шулай утырганда Илһам абый Шакировка охшатып «Кара урман»ны җырлап җибәрдем... Һәм бер заман мине машбюрога чакыралар. Анда командир хатыннары утыра иде. «Алмаз, шулкадәр матур тавышың! Безгә дә җырла әле!» – диләр. Җырлыйм. Шуның өчен чәй белән сыйлыйлар. «Кайсы телдә җырлыйсың?» – дип кызыксыналар. Бераз вакыт үткәч, часть командиры хатыны әйтә: «Безгә Тбилисидан генераллар кунакка киләчәк. Син шунда җырламассың микән?» – ди. «Татарчамы?» – дип сорыйм. «Билгеле, татарча! Сиңа костюмнар алдык. Татар дустыбыз дип таныштырырбыз», – ди бит бу. Җырладым! **ТУГАН ҖИРДӘН ЕРАКТА, БАШКА ХАЛЫКЛАР КАРШЫНДА ТАТАРЧА ҖЫРЛАУ НИКАДӘР МӘРТӘБӘ, ГОРУРЛЫК ИКӘН УЛ. МОНЫ АҢЛАТЫП КЫНА ДА БУЛМЫЙ!**

Студент чак. Келәттә йоклыйм. Бабай уята: «Улым, тор инде. Сыер көтүенә син дә чыксаң, ике чират берьюлы үтәр иде...» «Хәзер, бабай, хәзер...» Йоклыйм һаман. Биштә көтү куалар, ә мин дүрттә кайтып кына яткан булам. Керә дә: «Улым, тордыңмы?» «Тордым, бабай, тордым... биш минут кына ятам да...» «Улы-ым...» Сикереп торасың инде. Һәм ул көтү көтеп кайту – син эшләгән зур эш! Син кирәк! Барысы да тәрбия бит аның. **МЕНӘ ШУШЫ ЯХШЫ ЭШ ЭШЛӘВЕҢӘ КУАНА АЛУ ҺӘМ АНЫ БӘЯЛИ БЕЛҮ БЕЗДӘ БУЛЫРГА ТИЕШ.**

НӘРСӘ ЭШЛӘСӘҢ ДӘ, ВАК-ТӨЯК ИТЕП КЕНӘ КАРАРГА ЯРАМЫЙ. Милләтең өчен кирәкме бу? Аны шул югарылыкта бәяләргә кирәк. Авылың бар синең. Кайтып,

ниндидер җыр җырлагансың күкрәк киереп. Күрдегезме, дип. Ә ул җырың синең бер тиенгә тора микән соң әле? Ул халыкка нәрсә бирә? Әти-әниеңә хурлык түгелме шулай йөрүең? Бу эш дип аталамы соң? Менә шунысын уйлый белергә кирәк. Халык бит ул шундый. Әнә Илһам абыйдан да сораганнар: Син бирәр эштә эшлисеңме соң?» – дип. «Минем эшем шул бит инде», – дигән. Анализлый белмәгәннәр сораган инде.

Син музфакта кемдә укыдың, дип сорыйлар иде. Хәмзинда, дия идем. «Хәмзин кем соң ул?» – диләр. Үзем, дим. Максим Горький әйтмешли, тормыш – минем университетларым. Нәкъ шулай. **ҮЗЕҢДӘ БУЛМАСА, КЕМДӘ ГЕНӘ УКЫСАҢ ДА, БАШЫҢНЫ БӘРЕП, ТӨЕП УКЫСАҢ ДА, БУЛМЫЙ ИНДЕ УЛ.**

Телевидениедә эшләгәндә Илһам абый Шакиров белән Күн авылына барып, тимерчелектә бер видео төшердек. Тимерче алачыгына керү белән төшерә башла, дип, операторга әйтеп куйдым. Илһам абый сандалны, учакны, һава өрдерә торган күрекне күрде. Бөтенесен күздән кичереп, кыскычка тотынды. Тырма тешләрен күмеп куйган идек – аларын да тапты: кыскыч белән кыстырып алды. Дулкынланудан куллары калтырый үзенең. Чүкечне алды да, сандалга бәреп, теке-теке суга башлады, көй чыгарган кебек булып китте. Кайчан төшерәсез, ди. Төшердек инде, дим. «Белдеңмени син, минем әти тимерче иде бит!» – ди. Билләһи, белмәдем, дим. «Кулларым калтырый. Әти искә төште...» – диде Илһам абый. **КЕШЕНЕҢ КҮҢЕЛЕН КУЗГАТУ ӨЧЕН ТИЕШЛЕ КЫЛЛАРЫНА КАГЫЛА ГЫНА БЕЛЕРГӘ КИРӘК.** Бөек җырчыны менә шулай ача алуыма сөенәм. Кайткач, «Җырланмаган әле безнең җыр»га фонограмма куйдырдым. Шуны нибары бер тапкыр күрсәттеләр эфирда! Ә үзе шулхәтле ошаткан иде...

Пединститутның музфагында укыганда «Саз» ансамблендә җырлап йөри идем. Дүртенче курс, дәүләт имтиханнары бара. Ә мин «Саз»ның солисты булып Мәскәүгә Бөтенсоюз конкурсына киттем. Съездлар Сараеның Концертлар залында «Ай былбылым» белән «Уфа ни өчен матур?»ны җырладык. Бер генә җырны алдылар. Мин пас булдым. Тамаша залында карап утырам. «Саз» чыга, икенче яктан Брежнев чыга. Чыга да утыра, тыңлый, кереп китә. Тагын «Саз» чыга, тагын Брежнев... Режиссерлар әйтте: «Генеральный секретарьга «Саз» ошаган икән!» – ди. «Ай былбылым» белән Гран-при алды ул вакытта «Саз»! Татар җыры Генеральный секретарьны да мөкиббән итте шулай. **КАЙБЕР МАКТАУЛАР ҖИҢҮДӘН ДӘ КЫЙММӘТРӘК.**

Музфакның ниндидер юбилее иде. Табигать шартлары аркасында самолетлар очмагач, Ренат Ибраһимов Мәскәүдән кайта алмады. Василевский оркестрына җырлый идем мин. Ибраһимов урынына Василевский комиссиягә мине тәкъдим иткән. Мин «Туган ягым»ны җырларга тиеш. Шул вакытта әти килгән иде Казанга. «Мин концертка китәм, әти, җырларга тиешмен анда. Бармыйсыңмы?» – дим. Минем болай йөрүләремне яратмаганын, бармасын беләм бит инде. «Барам», – диде бит! Сәхнәгә чыгар алдыннан шулкадәр нык дулкынландым! Бәхеткә, җырым әйбәт килеп чыкты. Опера театрының арткы фойесыннан килә бу шыгыр-шыгыр протезы белән. Мондый малай белән җитди сөйләшергә кирәк бит инде! Шатланганын артык сиздерми. Шулай да кулын сузды да: «Улым, сиңа гомер буе комачаулаганмын икән», – ди. Иң шәп мактау сүзе булды бу минем өчен. Кырыс булса да, искиткеч кеше иде әти! **ҮЗЕМӘ ГЕЛ ӘЙТӘ ТОРГАН ИДЕМ, МИН ӘТИ КЕБЕК БУЛАЛСАМ, БӘХЕТЛЕ БУЛЫР ИДЕМ!** Ул шулкадәр намуслы булды! Гомере буе партоешма секретаре булып эшләдә, халык бик яратты үзен! Ул башкалар хөрмәт итәрлек югарылыкка иреште.

Пыр тузып рус эстрадасына бии яшьләр. Нишләп бездә шундый җырлар юк соң, дим. Шаяра-шаяра гына Разил Вәлиевнең «Үпкәләмә миңа» дигән шигыренә җыр яздым. «Саз» белән телевидениегә дә яздырдык. Тулай торак янышнан узып барам кич, шул җыр яңгырый! Яшьләр котыра-котыра бииләр! Шундый җырлар китте. Уйлый башладым: **ПҮЧТӘК КЕНӘ ТОЕЛГАН ТЕМАДАН ЗУР ПРОБЛЕМА ЧЫГАРЫП БУЛА ИКӘН БИТ.**

Мин укытучыларга әйтәм инде, нигә сез рус балаларын җәфалап, татар теленә нәфрәт уятып өйрәтәсез? Нигә «икеле» куясыз? Ике сүз өйрәнеп килсеннәр – куй «бишле»! Икенче көнне ул өч сүз өйрәнеп килер. Татар теле яраткан фәненә әйләнер. Безгә кушалар, системасы шулай бит, диләр. Система бетте хәзер! Юк ул! Хәйлә табып, система дигән сүзгә төренәләр. **БАЛАДА КЫЗЫКСЫНУ УЯТЫРГА КИРӘК!**

Җырчыларга һәрчак әйтәм, хәләл продукция бирергә кирәк тамашачыга! Алар аны аңламый. Шуннан әйтәм инде, син көен язмаган, сүзен язмаган, аранжировкасын үзең эшләмәгән, тавышыңны да Ходай Тәгалә биргән. Ходай Тәгалә тавыш бирмәсә, җырчы да була алмас идең. Ә син бу җырны кем язганын да әйтмисең. Бу – хәрәм. Сине тыңларга килгән кеше түләп кергән – хәләл акчасына килгән. Син бу җырның авторларын әйтергә тиешсең. **ҺӘР БАЛАНЫКЫ КЕБЕК, ҖЫРЛАРНЫҢ ДА ӘТИСЕ, ӘНИСЕ БУЛА.**

Мин шикләнеп карыйм: юморны аңламаган кеше тулы микән? Бик тулы түгелдер. Чөнки тулы түгел икәнен белсә, төзәтер иде бу ягын. Әгәр дә белмәсә, бик мәхлук ул. Безнең мәктәпләрдә юмор һәм сатира белән тәрбияли башлау кирәк. Балаларыбыз ни өчен басынкы безнең? Чөнки аларга юмор тәрбиясе бирелмәгән. Киләчәктә мәктәп программаларында юмор-сатира булган бер фән барлыкка килүен телим. **ЮМОР – КЕШЕГӘ БЕР ДӘВА, ЮМОР СТРЕССЛАРДАН САКЛЫЙ.** Юморы булган кеше җитәкчеләр янына керергә дә куркып тормый.

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.



БЕЗ БИТ АВЫЛ БАЛАЛАРЫ



Мәдинә АВЗАЛОВА

Кукмарада эшли башлаган «Туган авылны торгызабыз» программасы яшь гаиләләр өчен зур мөмкинлекләр ача.

...Нигә шулайдыр ул, әллә күңелгә бик тигән, әллә бүгенге көнгәчә мөһим һәм актуаль булып кала биргән шул югала, бетә баручы авыллар турында сүз чыкса, моннан бик күп еллар элек булган вакыйга, дөресрәге, бер очрашу искә төшә. Ул чагында да җәй уртасы, түзә алмаслык эссе көн иде. Чит төбәктәге районнарның берсеннән командировкадан кайтып килеш. Машинабыз авыл дисәң, авыл түгел, алты-җиде йорттан торган кечкенә генә урамнан узып бара. Су эчеп алыйк дип, түбәсе кыйшая башлаган, искереп беткән бер өй янында тукталдык. Капка без шакуга ук ачылып китте. Каршыбызда басып торган әби безгә шактый вакыт сәерсенеп карап торды.

– Адаштыгызмы әллә? – диде ул, ирен чите белән генә елмаеп.

– Су эчәсе килә бит, әби...

– Шулай дисәгез генә... – Суым да бетеп килә әле, – диде әби, сулы стаканын сузып. – Чишмә ерак, бара алмыйм. Күршем булыша.

Шофер «ерак чишмә»дән су алып кайтып биргән арада әби миңа моң-зарын түгеп ала. Кайчандыр зур авыл булган икән ул. «Газы да, суы да юк. Балаларга эше дә юк. Менә шулай таркалды авыл. Минем дә ике малай шәһәрдә. Чакыралар, бармыйм. Хәзер чакырмыйлар инде», – ди әби сүзен йомгаклап.



Сергей ДИМИТРИЕВ, Кукмара муниципаль районы башлыгы

– Безнең Кукмара – республикадагы иң эре авыл хуҗалыгы районы, бүгенге көндә көчле аграр төбәкләрнең берсе ул. Мин моны горурланып әйтәм. Аның эштән курыкмый, яңалыклардан тайпылмый торган тырыш, эшчән халкы киләчәге турында кайгыртып, әллә ниләр майтарырга әзер.

Бер килүендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, районыбыз эшчәнлегенә югары бәя биреп: «Кукмара – Татарстанда бик дәрәҗәле, тотрыклы үсештә баручы, кыю максатлар белән яшәүче үрнәк һәм республикада орденлы бердәнбер район. Аның байлыгы – тырыш халкы», – дигән иде. Тырыш шул бездә халык. Бу сүзләр, иң элек, авыл хуҗалыгы эшчәнлегенә кагыла.

Соңгы елларда илкүләм проектларны, федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру ярдәмендә халыкның тормыш сыйфатын яхшырту, шәһәр һәм авылларны төзекләндерү, районның инвестицион активлыгын үстерү мөмкинлекләре тагын да арта төште. «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү», «Авыл җирлекләренең заманча йөзе» дип исемләнгән федераль проектларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә үзәктә һәм авылларда гаҗәеп зур эшләр башкарылды. Хәзер авылны танымассың да. Ул шәһәрдән бер ягы белән дә калышмый. Әлбәттә, бу программаларда үсү перспективасы булган җирлекләр һәм авыллар гына катнаша ала. Демографик хәле, халык саны, өстәмә эш урыннары да хәлиткеч роль уйный биредә. Ә сөтчелек буенча лидер булган районыбызда моңа мөмкинлекләр җитәрлек. Җирле мәсьәләне хәл итү өчен үзарасалым программасы да зур мөмкинлекләр тудырды. 2014 елдан башлап, төзекләндерү, урам юлларына капиталь ремонт уздыру, янгын куркынычсызлыгы чараларын булдыру һәм башка шуның ише көн кадагындагы мәсьәләләрне хәл итүгә ярты миллиард сумнан артык акча юнәлтелде. Шуның 112 миллион сумнан артыгы халыктан керде.

Җирле үзидарә органнарының мөһим бурычы – эш урыннары булдырып, халыкны эш белән тәэмин итү, эшмәкәрлеккә уңай шартлар тудыру. Бу максатны күздә тотып, «Кукмара» сәнәгать паркына инвесторлар, резидентлар җәлеп итү юнәлешендә зур эш алып барыла: без кирәкле белгечләр, эшче һөнәрләре буенча кадрлар әзерләүгә дә җитди игътибар бирәбез. Авыл кешеләренә генә түгел, шәһәрдән кайтып эшләргә теләүчеләргә дә юл ачык.

Һичшиксез, федераль, республика программаларының максаты бер – авылларны саклап калу, үстерү һәм яшьләрне авылда калдыру. Шуны күздә тотып, республикабыз җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов һәм хөкүмәтебез, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы ярдәме белән Ядегәр һәм Югары Чура җирлекләрендә «Туган авылны торгызабыз» исемле республика тарихында булмаган өр-яңа проектны башлап җибәрдек. Югары Чура авыл җирлегендә алты шәхси хуҗалыкка терлек тораклары төзелеп, сыерлар саны 144 кә җитте. Ядегәр җирлегендә дә хәзер кызу эш бара. Бу проект шәхси хуҗалыкларда сыер санын арттыруның иң кулай, отышлы юлы дип уйлыйм. Ә иң мөһиме – ул яшьләрне авылда калдыруга, алар өчен югары технологияле эш урыннары булдыру белән беррәттән, яшәү дәрәҗәсенә тәңгәл килерлек лаеклы хезмәт хакы, уңайлы торак белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Ул, безнең арттан чыгып, машинабыз күздән югалганчы карап калды. Күрәсең, бу урам аша үтүче бик сирәк. Әбинең безгә бик гаҗәпләнеп каравы да шуңадыр.

Хәзер ул вакытлар моңсу истәлек булып тарихка кереп бара. Авыллар бүген яшәү өчен уңайлыгы, мөмкинлеге ягыннан шәһәрдән һич кенә дә калышмый. Ләкин шуңа да карамастан, яшьләрнең шәһәргә китүе, анда төпләнеп калуы дәвам итә. Башкача әйтсәк, әлеге дә баягы проблема кала бирә. Авылны ничек киләчәкле итәргә? Авылны гөрләтеп яшәтердәй егет-кызларны ничек кызыксындырырга? Баксаң, аның юлы гап-гади: аларны күңелләренә ятышлы, үзләре теләгән эш белән тәэмин итү! Кукмара районы башлыгы Сергей Димитриев инициативасы белән моннан бер еллар чамасы элек гамәлгә кергән «Туган авылны торгызабыз» программасы нәкъ менә шул проблеманы хәл итүгә йөз тота да инде. Бу эшләрнең барышын үз күзләребез белән күрү өчен без Казаннан кул сузымында гына урнашкан шул якларга юл алдык.

Иң башта әлеге проектны беренчеләрдән гамәлгә кертә башлаган Югары Чура авылына тукталабыз.

...Авылны торгызуга, яшәртүгә илтәчәк яңалык белән танышырга керешкәнче, район башлыгы киңәшчесе Равия Кәримуллина безне авыллар буйлап сәфәргә алып чыгып китә. Җитәкченең әйткәне белән килешәбез: әйе, авыл бүген бөтенләй башка. Шушы җирлектә генә дә бер урта мәктәп, аның ике филиалы, хоккей һәм волейбол, баскетбол мәйданчыклары, фельдшер-акушерлык пунктлары... Һәр өйгә газ, су кертелгән, асфальт юллар турында әйтмибез дә инде. Торгызасы торгызылган биредә. Хәзер инде әлегәчә төп проблема булып кала биргән егет һәм кызларның акчалы эш эзләп шәһәргә китүен генә туктатасы бар.

Әлбәттә, бу эшләрнең башы, иң элек, инвесторларга килеп тоташа. «Монокорм» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы җитәкчесе Алексей Леонтьев, Теләче сөт комбинаты директоры, «Нәүрүз» кооперативы җитәкчесе Раилә Хисмәтуллина шикелле алга карап фикер йөртә торган инвесторлар булмаса, тормышчан, гаять кирәкле эшләрнең гамәлгә ашмый калуы да ихтимал.



Раилә ХИСМӘТУЛЛИНА, Югары Шәмәрдән авылында туып-үскән, Ядегәр урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Лаеш авыл хуҗалыгы техникумында белем алган, Теләче сөт комбинатына директор булып билгеләнгәнче, «Вамин»ның бөлгенлеккә төшкән заводын аякка бастыруда катнашкан, инвестор. Раилә Нәкыйповна кооперативның ни өчен «Нәүрүз» дип аталуын шулай аңлата: «Карлыгачларны мин яз белән тиңлим. Күз алдына китерегез: бар дөньяда яз исе, җир ачылган, көннәрнең җылыга тартылган чагы. Бер уйласаң, без дә бит иртәгәсе көнгә өмет уятырдай эшләр башкарабыз. Шәһәргә китим микән, авылда калыйм микән, дип, ике юл чатында калучылар бар. Эшсез йөргән кешеләр бар. Шундыйларга юл күрсәтүче дип саныйм мин үзебезне».

«Бәхетебезгә күрә»

Өлешенә тигән көмешен зур бүләк итеп кабул иткән Денис Михайлов «Монокорм» мини-сөт паркы җитәкчесенең тәкъдиме буенча бу эшкә моннан бер ел элек бик теләп алынган. Югары белемле экономист әле Казанга, әле Чаллыга китеп, «шабашка»да йөри алмый бит инде.

...Элек бу урында басу булган. Бүген биредә үзе бер олы хуҗалыкны хәтерләтеп, алты зур корпус күтәрелгән. 144 сыерлы алты шәхси ярдәмче хуҗалык дигән сүз бу. Шуларның берсе – Михайловларныкы. Егет әле шул хуҗалыкларның мөдире дә. Без аны бәләкәй кызчыгын җитәкләп фермада сыерлар карап йөргәндә очраттык. «Кызык аңа», – дип елмая әтисе. Кызык булгач, әйбәт инде. Димәк, ферма хуҗасыз да, эшче кулларсыз да калмас.

Узган елның ноябреннән башланган эш гөрләп дәвам итә. Гаилә дәүләт субсидиясе исәбенә районның «Восток» нәселле терлекләр үрчетү хуҗалыгыннан 24 сыер сатып алган.

– Маллар бәйдә түгел, аслары чиста, каралган. Кирәкле бөтен витамины булган азыкны «Монокорм» кооперативыннан алабыз. Шуңа сөтне дә әйбәт бирәләр, – ди, эшеннән канәгать калып, Денис.

Әйтүләренә караганда, тәүлегенә бер сыердан 28 литр чамасы сөт савып алына икән. Әлегә шулай. Чөнки аларның максаты булганы белән генә чикләнми. «Биредә бөтен эш автоматка җайлаштырылган. Болай булса...» – ди егет алдагысын күз алдына китереп.


«Авылны яратабыз!»

Бүген үземнеке дип әйтә алырдай шәхси хуҗалыкта җир җимертеп эшләп йөргән Рамил Мусин да бетмәс-төкәнмәс эше, мәшәкате булган, аның каравы, кереме дә шөкер генә итәрлек таныш та, таныш та булмаган бу «дөнья»га Раилә Хисмәтуллина ярдәме белән килеп эләкте бит инде.

Шулай дип кабатларга яраткан Гөлназ белән Рамил Мусиннардан: «Нәрсәсен яратасың аның?» дип сорау мәгънәсез, файдасыз. Гөлназ санап китә башласамы... Сызылып аткан таңнары, очсыз-кырыйсыз болыннары, көзләрендә тук башакка кинәнеп, әкрен генә җилдә тирбәлгән алтын кырлары, бер чыгып китсәң, кайтып керә алмастай серле урманнары, күлләре... Юк ла, санап бетерә алмый ул сихри дөнья гүзәллеген. «Их-х, – ди ул янә хыялына бирелеп, – җәен кәрзин туты-



Денис Михайлов хатыны Татьяна һәм кызы Сафия белән.



рып җиләген җыясың, көзен гөмбәсен... Ә һавасы нинди чиста! Кайчак шәһәргә туганнарга барабыз да, бер-ике көннән «үзегез генә исән-сау торыгыз», дип, тизрәк кайтып китү ягына карыйбыз. Без – авыл балалары. Чыгып китсәң, ишегалдында йөргән тавык-чебешенә кадәр сагындыра».

Кукмара районы Ядегәр авылы егетенең киленне Балтач районы Норма авылыннан барып алуы бер дә гаҗәп түгел. Үзләре әйтмешли, «алар бер дулкында». Уйлары да бер, эшләре дә... Шуңадырмы, «Нәүрүз» кооперативы җитәкчесе Рамилгә: «Фермада эшләп карамыйсыңмы?» – дигәч, алар Гөлназ белән икәүләшеп бертавыштан шундук ризалык бирделәр. Нигә эшләмәскә?! Рамил терлек ярата. Әле менә эше дә юк чак. Тегендәмонда сугылып, акчалы эш эзләп йөрүдән бик туйды ул. Казанга китеп тә эшләп карады. Булмады. Үз вакытында Кукмара аграр көллиятендә тракторчы-машинист һөнәрен үзләштергән иде. Һөнәрсез түгел ул. Тик аның да әллә ни кирәге чыкмады. Ә хәзер менә шундый җаваплы, мавыктыргыч эшкә алынуына куанып бетә алмый.

– Әйе, бик авыр, мәшәкатьле эш, – ди ул сораштыра башлауга. – Ләкин ул тырышлыкның нәтиҗәсе дә әйбәт бит. Әлегә акчасы 50 мең тирәсе чыга. Алга таба алай гына булмаячак ул. Артачак. Без бит эшли генә башладык әле. Хуҗалыкта бүгенге көндә 13 сыер. Ферма 24 баш сыерга исәпләнгән. Без монда дүрт хуҗалык. Һәрберебезнеке шулай булырга тиеш. Малларны Смоленскидан үзебезнең акчага кайтарттык. Дәүләт биргән субсидия ярдәм итте. Корпусны арендага алдык.

Хуҗалыкта бөтен эш автоматка көйләнгән. Сөт саву да, малларга азык бирү, асларын чистарту да... Беркем дә биредә бидон күтәреп, көрәк тотып йөрми. Заманы башка диюебезнең билгеләре фермаларның бүгенге торышы аша да әнә шулай бик яхшы чагыла.

Маллары яныннан кайтып кермәгән ире турында Гөлназ яратып, аны мактап сөйли.

– Рамил белән 2006 елда өйләнештек, – ди ул, истәлекләренә бирелеп. – Бер-бер артлы өч бала алып кайттым. Шул арада секретарь-референт булып та, бухгалтер, почта начальнигы булып та эшләп алдым. Хәзер менә – җирлек башкарма комитетында. Рамил монда рәтле эш таба алмагач, чыгып китеп эшләп йөрде. Өч баланы туйдырырга, карарга кирәк бит. Алай йөрүен үзе дә, мин дә ошатмадым. Ничек инде өй тулы баланы, хатынны ташлап китәсең?! Үз хуҗалыгыңда, үзеңә эшләүгә җитәме соң?! Без хәзер бик бәхетле. Балалар да үсеп килә. Олысы – Камилебез тугызынчы сыйныфта, уртанчы улыбыз Раил – алтынчы сыйныфта, кече кызыбыз Лилия әнә бишенче яше белән бара. Һәркайсының үз шөгыле, үз йөкләмәсе. Баланы бәләкәйдән эшләтеп үстермәсәң, соңыннан әйттең ни, әйтмәдең ни аңа. Камил кайчак әтисе белән фермага баргалый. Өйдә дә минем кул арасына керә, тегесен эшли, монысын... Үзенчә ярдәм итәргә тырыша. Авыл җирендә эш бетәмени?! Шуның белән кызыклы да ул. Елларны гел бергәләшеп үткәрәбез. Без Рамил белән бакчада пылау пешерәбез. Бала-чага әтиләре ясап куйган чатырда мәш килә. Безнең өчен шунысы да бик җитә. Бу программа шәхси хуҗалыкта эшләүчеләргә, әгәр ихтыяҗы бар, мохтаҗ икән, йорт салып бирүне дә күз алдында тота. Бәлкем, алга таба андый бәхеткә дә ирешербез.

Максаты авылларны яшәтүгә, яшь гаиләләргә ярдәм күрсәтүгә, җыеп кына әйткәндә, шушы изге гамәлләр аша туган җиргә тирән мәхәббәт уятуга төбәлгән бу башлангычның якты киләчәгенә һич тә шигебез юк. Ул әкренләп тамыр җәя бара. «Бу эшкә инвесторлар гына кушылсын. Шунсыз булмый, фермасы төзелсә, хуҗасы да табылыр, сыерлары да булыр...» Безне озата йөрүче җитәкче шулай ди бит әнә.

Фото: Анна Арахамия, Айдар Саттаров



Рамил Мусин төпчеге Лилия белән фермада.



«Без дус һәм тату гаилә». Гөлназ һәм Рамил Мусиннар балалары Камил, Раил һәм Лилия белән.



Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янында сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыгызга җавап табарга ярдәм итәр. Рубрикабызның кунаклары – Татарстанның атказанган артисты Лилия МУЛЛАГАЛИЕВА һәм аның кызы ИЛЬВИНА.

Ильвина, әниең, балалар блогер булсын иде, ди. Моңа мөнәсәбәтең?

– Мин каршы. Шәхсән үземә кирәкми дип саныйм. Төрле үсмерләрнең кызыксынулары төрле бит. Кемгәдер, бәлки, социаль челтәр йолдызы булу ошыйдыр. Миңа ошамый. Анда нинди генә комментарийлар язмыйлар. Берәр видео куйгач, мыскыллы сүзләр язсалар, мин ябылачакмын, күңелем яраланачак. Мин башкаларны карарга яратам. Андый кешеләр дә булырга тиеш бит. Гомумән, социаль челтәрләр белән дус түгелмен. Фотога да, видеога да төшәргә яратмыйм.

Чынлап та үсмерләр фотога төшәргә яратмый. Моның сәбәбе нәрсәдә икән?

– Ачылырга теләмиләрдер... әйтә алмыйм... Селфи ясап йөрүчеләрдән түгел мин. Әни төшәргә кушканда гына фотога төшәм. Фотода матур чыкмыйм кебек тоела. Үзем фотографияләр ясарга яратам. Әмма берсен дә интернетка чыгармыйм. Ә болай ютуб карыйм. Моңсу булса, шундагы видеоларны карап нерв киренкелеген бетерәм. Ә социаль челтәрләр аша трендлар белән танышам.

Ә китаплар белән ничек хәлләр?

– Ой... «Сәләт» лагерына барып кайтканнан соң китаплар белән кызыксына башладым. Җәй дәвамында дүрт китап укыдым. Төрле жанрдагы бик кызыклы китаплар иде.

Телефонда күп утыруыңа әниең ачуланамы?

– Әйе! Ә мин телефоннан сериаллар карарга яратам. Әни урамга чыгарга куша, ә мин җәйне бөтенләй яратмыйм. Җылыны, җәйге табигатьне яратмыйм. Кышны яратам. Карны, шугалакны... Фигуралы шуу – минем хобби.

Кызык, мәктәп балалары, киресенчә, җәйне бик ярата. Каникуллар бит!

– Мәктәптә уку авыр булмаса, җәй көне дә уку булуын теләр идем. Контроль эшләрдән генә ял итәсем килә. Миңа җәй бик озын булып тоела. Каникулларны яратам, әмма ял итәргә бер атна да җитә. Зур компанияләр, кызлар белән йөрергә яратмыйм. Ялгызлык күбрәк ошый. Үз-үзем белән сөйләшү рәхәтрәк. Ә җәй ул – өй, әнигә булышу, балаларны карашу...

Үземнән беләм, олы балага бала карау әлегә инде ул. Син апа кеше, энеләреңне-сеңелләреңне кара, диләр. Бу синең дә ачуыңны китерәме?

– Китерә дә инде... Әмма мин Ильяс тугач бик шатландым. Беренче тапкыр бәби күрдем! Ильясны үзем карадым. Әни концертларга киткәндә алып кала идем. 8 яшь иде ул вакытта миңа.
Ә Илһамны бергәләп карадык. Бишенчебез туса, бик тә кыз булуын теләр идем. Мин карар идем аны. Иң мөһиме: сеңелкәш булсын. Әйе, апам булса, бөтенләй кайф булган булыр иде. Апалы кешеләр – бәхетле кешеләр. Апа абыйга караганда якынрак, якын дус кебек, барысына өйрәтә.
Ә Данил мине һаман үчекли генә. Сеңлем туууга өметләнәм әле мин.

Ә әниең синең өчен иң элек әниме, иптәш кызмы?

– Әни. Ул минем әни!

Синең әниең – танылган җырчы. Горурланасыңмы?

– Әйе, әмма миңа Лилия Муллагалиева кызы дип караулары бөтенләй ошамый. Әни – әни ул, ә мин ул – мин. Үз ихтыяҗларымда аның исемен кулланып яшисем килми. Башкаларның да бу гадәтләрен хуп күрмим.

Ә сәхнәгә тартыласыңмы соң?

– Юк. Миңа үз тавышым да ошамый. Ачык буласым килми минем. «Понты» дигән төшенчәгә исем китми.

Әниең белән бергә кичергән иң рәхәт мизгел?

– Балачакта без икәү генә Дубайга ял итәргә барган идек. Гомумән, әни белән икәү генә берәр кая бару рәхәт. Без күп балалы гаилә булгач, бу бик сирәк әлегә. Без, гадәттә, бөтенебез бергә йөрибез...

Киләчәгеңне ничек күз алдына китерәсең?

– Әти-әни мине спорт буенча китәр дип уйлый. Мин дә шулай уйлыйм. Хореограф та буласым килә. Әни үзенең хыялын чынга ашыруымны тели – көнчыгыш биюләре белән шөгыльләнергә киңәш итә. Бу шөгылең белән акча да эшли аласың, ди. Әлегә булдыра алмыйм. Ул биюләр минем өчен нык ачык. Бию ошый, әмма көнчыгыш биюләре генә түгел. Мин, гомумән, фигуралы шуу буенча профессиональ рәвештә шөгыльләнер идем, әмма инде соң.

«БЛОГЕР БУЛУ ЗЫЯН ИТМИ»

Лилия, кызыгыз Ильвина белән холкыгыз охшашмы?

– Безнең туган көннәр аермасы берничә көн генә. Икебез дә Үлчәүләр. Үлчәүләр – үзләренә кайвакытта ышанмый, күп нәрсәне үлчи, бар кешене җайлап йөри. Бу яктан без охшаш. Әмма Ильвинада күбрәк әтисе холкы. Әтисе кебек спортчы ул. Кечкенәдән спорт белән шөгыльләнде. Кирелек икебездә дә бар. Мин дә шундый идемме соң, дип сорыйм кайчак әнидән.

Ильвинаны аңламаган чакларыгыз бар, димәк?

– Бар инде, ничек булмасын?! Ул гел мин әйткәнне генә эшләп торырга тиеш түгел. Без, әниләр, ничек кенә заманча булырга тырышсак та, башкачарак фикер йөртәбез. «Алай итми идек, без мондый түгел идек», – дип, балаларны үзебез белән чагыштырырга яратабыз бит әле. «Ул бит син! Син шулай эшләгән! Ә мин ничек күрәм, шулай эшлим», – ди ул вакытларда кызым. Әле аның күп нәрсәгә карашлары формалашып бетмәгән, төрле җирдән мәгълүмат җыя торган чоры. Бер-ике елдан соң һәрнәрсәгә үз карашы булыр дип уйлыйм.

Хәзер балалар, нигездә, интернеттан мәгълүмат ала. «Дөнья пәрәвезе»ндә кызыгызның нәрсә туплавы белән кызыксынасызмы?

– Барын да контрольдә тотам дип әйтә алмыйм. Әйе, алар хәзер гаджет балалары. Моны аңлыйм һәм интернетта актив булуларын телим. Социаль челтәрләрдә үз аккаунтларыгызны булдырыгыз, фото-видео төшерергә иренмәгез, дим.

Менә бит! Гадәттә, әниләр социаль челтәрләр баланы боза, вакытын бушка уздыра, ди. Ә сез аның балаларга файдасын нәрсәдә күрәсез?

– Блогер була икән, текст язарга, хатасыз язарга, видеолар төшереп, монтажларга өйрәнә. Нәрсә язый, ничек язйм икән дип уйлый. Димәк, фикерләргә өйрәнә. Үз контентыңны булдыргач, кешенеке белән дә кызыксына башлыйсың. Чагыштырасың, нидер аласың. Ул яктан социаль челтәрләр күп нәрсә бирә. Әйбәт итеп блог алып барасың икән, реклама буенча хезмәттәшлек тәкъдим итә башлыйлар. Бу да кирәк! Әмма минем Ильвина моңа каршы. Ул үз битен алып барырга яратмый, кирәк тә санамый. Мин үзем социаль челтәрләрнең файдасын күп күрәм, утырырга вакытым гына җитми. Ә ул кечкенәдән өйрәнсә, бу аның тормыш рәвешенә әйләнә. Җитмәсә, анда бөтен видео, фотолар саклана. Үскәч, үзен карый ала. Хәзер бит альбом төзеп утырмыйсың.

Социаль челтәрләрдә утырып, балаларның укуга карашлары салкынаймасмы? Ни генә дисәк тә, аларның төп бурычлары классик белем алу бит әле.

– Үсмерләр инде үз графигын үзе төзи башларга тиеш. Ильвина, мәсәлән, үзенә кирәк булгач, физик әзерлек буенча көнгә берничә тапкыр шөгыльләнә. Аңа әйтеп торасы да юк. Әлбәттә, балалар гаджетта үзләренә файда алыр өчен генә утырсын иде. Шуңа күрә дә беренче сыйныфка укырга кермичә, балаларга телефон бирмәдек без. Алар аңа кызыкмадылар да. Кунакка килгән балаларга да телефоннарын алып куярга кушам. Шөгыльләнергә шөгыль җитәрлек бездә. Спорт мәйданчыгыбыз, бассейныбыз бар. Әтисе спортчы булгач, аларны һәрвакыт ни белән булса да мавыктыра. Өч улыбыз да – хоккейга, Ильвина колга белән сикерүгә йөри. Аларның вакытлары юк.

Ильвинадан соң ике улыгыз бар. Кыз кеше булгач, миңа булыш, энеләреңне кара дисең, бит инде. Көнләшү булмадымы?

– Юк, сиздермәде. Алар, чынлап та, бер-берсен карап үсәләр. Өйдә балалар үзләре генә калган вакытлар да бар. 6 яшьлек Ильяс энесен алып кала иде инде. Бик җаваплы һәм мөстәкыйль алар минем. Сәхнә артында үскәнгә дә шулайдыр ул. Зурлары ашарга пешерә белә. Ильвина токмач басып кисә.

Балалар белән гел сөешеп кенә яшәмисең. Үпкәләүләр, үсмерлек чорында ишекне шапылдатып чыгып китүләр дә була. Ул вакытта сез нишлисез?

– Тынычлыкта калдырам. Нидер әйтеп җиткерергә кирәк икән, мин инде аны әйтәм һәм ишекне үзем ябып куярга мөмкинмен. Әйтәм бит, минем Үлчәү булуым ярдәм итә. Җитез булсам да, сабырлыгым зур минем. Аннан соң балаларым да үзем кебек беркатлы. Үпкәлиләр дә шунда ук онызалар.

Киләчәктә Ильвина сезгә ошамаган һөнәр сайласа, нишләр идегез?

– Нинди һөнәр сайласа да риза. Үз тамагыңны туендырырлык һөнәрең белән бергә хоббиларың күп булсын, дим. Биисеңме, җырлыйсыңмы, керфек үстерәсеңме, маникюр ясыйсыңмы – мөһим түгел. Белгечлегем буенча гына эшлим дигән фикер дөрес түгел, минемчә. Буш вакытың бар икән, акча эшләргә кирәк. Көтеп утырырга ярамый хәзер.

Сез – җырчы, җитмәсә блогер әни. Балаларга вакытыгызны ничек җиткерәсез?

– Балаларга әкиятләр укып утыра торган әни түгел инде мин. Аларның сабырлыклары да җитми, үзем дә яратмыйм димме соң. Әмма балаларга вакытым җитә дип уйлыйм. Гастрольләргә дә еш чыгам дип әйтмим. Ике-өч көннән соң үлеп сагына башлыйм. Беркая да чыкмыйча, өйдә пешеренеп, җыештырып, балалар тәрбияләп кенә дә ята алам.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Фото: Анна Арахамия

Килен һәм кайнана… Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Иреңнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.
«Сөембикә» журналы белән берлектә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен үстерү мәсьәләләре комиссиясе «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы игълан итә. Ул ел дәвамында барачак, һәм аларның иң эчтәлеклеләре журнал битләрендә урын алачак. Сездән хатлар көтеп калабыз!





РИЗА-БӘХИЛ МИН...



Римма ЖӘББАРОВА

Бу тарих – сабыр хатын-кыз язмышы. Татар хатыны ниләр күрми дә, кемнәр хакына сабыр итми, диярсез. Әйе, сынаулар узып яшәгән гаиләләр аз түгел. Ләкин кайнанасы һәм кайнатасы хакына күпкә сабыр иткәннәр... Шулай ук күп микән?
«Үзем дә көчле, нык булганмын. Ә кайнанам исә искиткеч кеше иде! Бу истәлекләр аның рухына дога булып ирешсен...» – дип башлады сүзне Әгерҗе шәһәрендә яшәүче укучыбыз Римма Җаббарова.



Сигез бала үстек без. Әти – сугышта яраланып кайткан инвалид – бик кызу кеше. Рәхәт яшәдек дип әйтә алмыйм... Ашарга җитмәгәч, яхшы гына йортны мунча кадәр генә кечкенә бер өйгә алыштырдык. Җиргә сеңеп беткән, туфракта утыра иде дип хәтерлим. Идән астындагы бакаларына кадәр... Бер көнне апам банкка укучылар кирәк дигән сүз ишетеп кайткан. Кыш көне иде бу, 16 декабрь. Япь-яшь кыз бала гына бит әле, куркып кына булса да, калтыранган кулларым белән ишекне ачып кердем. Банк җитәкчесе – сугышта катнашкан Каюм абый Кәримов өстәле артында утыра.

– Сезгә укучылар кирәк дип ишеттем, – дим.

– Әйе, кызым, кирәк. Ләкин эш бик күп бит бездә, – ди Каюм абый, сынап.

– Ә мин бер эштән дә курыкмыйм! – дим.

Гариза яздырдылар. Эш биргәннәрен көтеп утырам. «Бүген кайтып тор, иртәгә эшкә килерсең», – дип озатты мине Каюм абый.

Эшкә киеп барырга күлмәк тә юк иде, апа үзенекен бирде. Минем кебек яшь кызлар берәр ел укучы булып йөри. Ә мине дүрт айдан машинкада эшләүче оператор итеп күтәрделәр, бер елдан инде җаваплы башкаручы булдым, үземнең штамп та бар иде.

Декабрьдә эшкә урнаштым, майда банкка Рафаэль килеп керде... Район башкарма комитетының физик культура һәм спорт бүлегендә эшли иде ул чакта. «Борыныңны чөеп горур гына утыра идең. Минеке булачак бу кыз дидем», – дип искә алып сөйләде соңыннан.

Танышып бераз вакыт узгач, танцыга чакырды. Кайтып барганда: «Римма, мин инвалид бит», – ди бу. Аны алгарак уздырдым да: «Йәле, карыйк, нинди инвалид

икән?» – дим. Ә ул шулкадәр оста йөрергә җайлашкан – үрдәк сыман гәүдәсен бер аяктан икенче аякка авыштырып йөри, аягы кыска икәнлеге сизелми дә.

Рафаэль Төньяк Украинада ракета гаскәрләрендә хезмәт итә. Бер төнне аларны тревога белән йокыларыннан уяталар – ракета җибәрергә кирәк. Рафаэль сөйләгәнчә, ул вакытта ракеталарны горизонталь рәвештә җибәргәннәр. Билгесез сәбәпләр аркасында ракета, очып китә алмыйча, шунда төшә. Бик күп солдатлар яралана, үлүчеләр дә була. Рафаэльнең аягы өч җирдән сына, бик күп кан югалта ул. Жгутлар да салмыйча, аны 27 чакрым ераклыкта урнашкан район үзәге хастаханәсенә озаталар. Барып җитеп, табиблар кулына хәрби билетын тапшыра да аңын җуя. Аннан соң берни хәтерләми... Ике шәфкать туташы аңа турыдан-туры кан җибәрәләр. Шулай итеп, табиблар аның гомерен саклап кала. Яралы аягы 3 сантиметрга кыскарак булып кала. Бик яхшы спортчы булган ул гарнизоннарында. Утызлап Грамотасы бар. Шул хәлдән соң да кыска аягы белән дә чаңгы буенча зональ ярышларда берсен дә уздыртмаган Рафаэль.

Шушы хәлләрне белгәннән соң, аны гел кызгана идем. Шуңа күпне гафу иттем дә инде. Кешедән ким булмасын дип яшәдем гомер буе. Алгарак киттем әле...

1968 елның 4 июлендә Рафаэльгә кияүгә чыктым мин. Аның туган көнендә. Ул чакта Ижау шәһәрендә мотоцикллар чыгара торган заводта эшли иде инде. Көндезге унбердә эшкә килде дә:

– Матур күлмәгеңне ки, паспортыңны ал да, киттек язылышырга! – ди. Кияүгә чыгуыма шулкадәр сөендем ул чакта. Мин Рафаэльне бәхетле итәргә тиеш! Шундук риза булдым. Шаһитларыбыз да очраклы кешеләр генә: берсе – Башкарма комитетның баш хисапчысы, икенчесе – Тәбәрле авылы мәктәбе директоры. Язылышкач, кибеткә барып бер ликер, бер килограмм шоколадлы конфет алганыбызны хәтерлим. Шуннан... Рафаэль үз өенә, мин үз өемә кайтып киттек. Нишләп болай дип, бер дә сорамадым. Аерым яшәп тордык шулай.

Тагын күпме йөргән булыр идек әле, белмим. Безнең язылышкан хәбәребез Рафаэльнең әнисенә – Нәгыймә әнигә барып ирешкән. Ишетүгә үк кайнана буласы кешем минем әти-әни янына сөйләшергә килгән. «Язылышканнар инде алар, никах укытыйк», – дигән. Үз әниләремдә никах укыттык та, печәнлектә төн кунып, икенче көнне әнинең коймагы белән чәй эчеп, Рафаэльләргә кайтып киттек. Килен булып төшүем шул булды.

Мин килгәндә Нәгыймә әнигә – 64, Габдрахман әтигә 65 яшь иде. Кайнанам белән кайнатам мине үз гаиләләренә бернәрсәсез кабул иттеләр. Беренчедән, ишле гаиләдә үстем, муллык күрмәдек. Икенчедән, кияүгә чыгуым да кешенеке төсле булмады дисәм, һич арттыру булмас... Килен бирнәсе дип күрсәтерлек пәрдә түгел, бер кулъяулык та алып килә алмадым. Күлмәк, пәлтә ише киемем дә юк. Нәгыймә әни белән Габдрахман әти халатка, күлмәккә дип, үзләре миңа штапель тукыма бүләк иттеләр. 25 квадрат метрлы кечкенә генә йорт – ятып йоклар урын да юк. Әтинең урыны түрдә иде, безгә шунда җәйделәр, пәрдә кордылар. Әти үзе идәнгә ятты...

Әти белән әни мине ким-хур итәргә теләмәгәннәр, күрәсең. Әни әйтә: «Римма, кибеткә барып кайт әле, ашъяулык, җәймәләр бар микән?» – ди. Карап кайттым, бар. Әни миңа акча тоттырды.

– Бар да, шуларны алып кайт. Беркемгә белгертмә, Розага да әйтмә, синеке дип әйтербез, – диде. Роза – Рафаэльнең бердәнбер исән калган туганы. Тормышка чыгып, аларның бакча башында гына яшәде. Минем бернәрсәсез килгәнне әни үз кызына да белгертмәде хәтта. Һәм беркайчан да кабат искә төшермәде ул чакларны...

Рафаэльләр гаиләдә җиде бала үскәннәр. Бер энеләре кечкенә чакта – 5 яшендә үк үлгән. Элек мин Рафаэльне генә кызгана идем. Нәгыймә әнинең тормышта күргән авырлыклары турында ишеткәч, аларның тыныч тормышы, бәхетле картлыгы минем өчен беренче урынга басты. Шулкадәр хәсрәт күргән кешеләр алар...

Олы уллары Рөстәм сугышка киткән. Бер генә хаты килгән дә, хәбәрсез югалган. Аңа 23 яшь булган. 21 яшендә шулай ук сугыш кырында вафат булган Әхтәм абыйны бакчадагы сыерчык оясы хәтерләтә. Сугышка киткәндә элеп киткән ул аны. 1943 елда килгән соңгы хаты әле дә саклана. «Хәзергә сау булыгыз», дип, кәгазьгә эре итеп язып җибәргән. 1944 елның 16 мартында Смоленск шәһәрендә вафат булган. Олы кызлары Сәлимә дә 27 яшендә ачы язмышка дучар була. Кышкы салкында урамда барган чакта кинәт тулгагы башлана да шунда бәбили. Беркем дә өенә кертми, ярдәм итми аңа. Бала да, үзе дә исән калмаган... Асия исемле кызлары Казанда хәрби госпитальдә шәфкать туташы булып эшләгән. Бер яралы солдат үләр алдыннан Асия апага йөзеген бүләк итеп калдырган. Истәлеккә киеп йөргән ул аны. Ә ире моның өчен ачу саклаган, көнләгән, күрәсең... Эшләгән җиренә килеп, үз куллары белән Асия апаның гомерен өзгән...

Берсеннән-берсе аяныч бит! Олы яшьтәге әти-әнисе булгач, Рафаэльне армиягә алмаска да тиеш булганнар. Ә ул үз теләге белән киткән. Озак кына хатлар килми торгач, бер көнне Рафаэль белән бергә хезмәт иткән дустыннан хат килеп төшкән. Бер сүз дә юк – рәсем генә икән ул хатта. Карават өстендә бер кеше сузылып ята... Рәсемне күрүгә, бу улларын да үлгән дип уйлаган әти белән әни. Военкомат аша хәрби часть белән элемтәгә кергәч кенә теге ракета төшеп яралану тарихын белгәннәр. Әнә шундый сагыш-борчу аша килгән бәхете ул Рафаэль әти-әнинең. Югалта язып яңадан кавышкан балалары. Ничек рәнҗетим аларны? Китәрлек сәбәпләрем күп булса да, әнинең яхшылыклары алардан өстен булды.

Эштән кайтып ашарга утыруга, әти белән әни торып чыгып китәләр иде. Тынычлап ашасын, бездән читенсенмәсен дип эшләделәр алар моны. «Ябыга күрмә, туйганчы йокла, матур киен», – дип кенә торды миңа әни. Әле дә хәтерлим, өйләнешеп тора башлагач телогрейка киеп, яулык бәйләп суга киттем. Кайткач, әти: «Римма, болай йөрмә бүтән. Яшь бит әле син, матур киен. Үткән кеше сиңа борылып карарлык булсын», – диде. Әни үзе гел матур киенде. Тегүче дә иде әле ул. Күзләре көлеп кенә тора иде аның. Беркайчан кеше сөйләмәде. Юмартлыгын инде сөйләмәсәм дә, аңлашыла...

PRESSA

Бу кадәр бала хәсрәте күрсә дә күрер икән адәм баласы.

Рафаэль белән безнең тормыш бозылмасын дип тә саклаучыларым иде алар. Бакча башында гына яшәгәч, Роза апаның безгә арт капкадан гына керә торган гадәте бар иде. Ә әти анда йозак элеп куя. «Кызлы йорт – безле йорт», – ди әни. Ягъни, кызлары да безнең тормышка тел-теш тидермәсен, арага кермәсен.

Ә Рафаэль бер дә тыныч кеше түгел иде... Вулкан белән чагыштырам мин аны. Банкта эшләгәч, кирәк җирдә сүзем үтте минем. Нефтебаза директоры эштән киткәнен ишеттем дә, районның беренче секретаре белән сөйләшеп, Рафаэльне шул урынга урнаштырдым.

20 ел эшләде ул анда. Башка нефтебаза директорлары алдында дәрәҗәлерәк булды һәрвакыт. 1975 елда тиенләп җыйган акчабызга машина алдык. Әгерҗедә дә аз иде әле машиналы кешеләр. Анда да хәстәрен күрдем, инвалид мин, дип, кеше янында кимсенеп йөрмәсен дип, ирем хакына тырыштым. Кызганыч, Рафаэль ул машинада юл һәлакәтенә эләкте. Эштән кайтканда карасам, капкалар ачык, халык җыелган. Миңа да бу хәсрәтле көн килде, ирем үлгән дип уйладым. Әти-әни ничек күтәрер тагын? Карасам, Рафаэлем басып тора. Ул шатланганнарым! Ә ул елый... «Елама, консерва банкасы гына бит ул, үзең исән!» – дим. Бик еш искә алды әле ул бу сүзләремне.

Нинди хәлдә кайтып керсә дә, йөгереп барып озын толымнарыма төреп кочаклап алдым, утыртып ашаттым, аякларын юып йокларга яткырдым. Мин түзәм, сабыр итәм, җайлыйм... Иң мөһиме гаиләдә тынычлык булсын. Әниләрне дә саклыйм... Кызулыгы белән аларга начар сүз әйтмәсен, кул тидерә күрмәсен, дим.

Бервакыт Рафаэль кайтып керде. Нык салган. Сизеп торам, тавыш чыгарырга да маташа... Ә икенче көнне бик мөһим очрашуы булырга тиеш. Эшкә бара алмаячагын чамалыйм. Район хастаханәсенең баш табибы янына бардым да, авырый дигән справка хәстәрләп кайттым. Икенче көнне иремә справканы суздым. Әни шулчак куркуга калды: «Милициягә бардыңмы, утыртырга телисеңме?» – дип, мине гаепләргә маташа. Аның газиз баласы бит, нишләсә дә, җаны өзгәләнә, гафу итә... Аннары, справка икәнен аңлагач, үзенә дә читен булды.

1969 елда әтигә инсульт булды. Озак та тормыйча әнигә дә шул ук бәла кагылды. Әти ярты ел гына яшәде шуннан соң. Үләр алдыннан үзе янына чакырып, караватына утырырга кушты.

– Римма, риза-бәхил бул. Син гаепсез булганда да гаепләгән чаклар булгандыр. Безнең кебек матур, озак, тату яшәгез. Картаймыш көнегездә бернигә дә йөдәмәгез. Кешегә йөрмә... Дөнья авырлыгы сиңа кала, – диде. Кулы төшеп китте дә җан бирде...

«Дөнья авырлыгы» дип үз улын да исәптә тотып әйткәндер инде әти... Аның тормышы, язмышы минем кулда калачагын аңлап, сабыр бул, килен, дип әйтүе булгандыр олы кешенең. Аларга булган рәхмәтем үзләре бакыйлыкка күчү белән дә беркая да китмәде, әлбәттә. Әти-әнинең миңа эшләгән яхшылыкларын бер дә истән чыгармадым. Рафаэль мине ярата иде, белеп яшәдем мин моны. Шуны белүем җитте. Барган җиреннән бүләксез кайтмый иде, сораган бөтен әйберне алып бирде.

Инсульт булганнан соң, әни дүрт ел яшәде. Эштән кайтып киемнәрен юам да, төнлә су буена чайкарга төшәм. Караңгыда чормага менеп керләрен элә. «Әй рәхмәт, Римма! Балаларың бәхетле булыр, менә дигән кешеләргә кияүгә чыгарлар», – дип сөенеп ятты. Тәмле ризык алып кайтсам, балаларга: «Әбиегезгә бирегез», – дип тоттырып чыгарам. Әй куана иде шуңа. Нык зурларга тырыштым. Бөтен серләремне дә гомер буе үз әниемә түгел, кайнанама сөйләдем бит мин. Аның киңәшләренә колак салдым. Чирләгәндә мунчага алып барып яхшылап юындырдым, чәчләрен тарап үрдем. Чиста булсын дип тырыштым.

Бервакыт «Ижминводы» санаториена юллама бирделәр. Йортны калдырып китәргә теләмәдем, Рафаэль үзе генә китте. Үзе кайткач, мине дә җибәрде. Санаторийда төшке ашны ашап бетерүгә яныма официантка килеп, иремнең монда чит хатыннар белән күңел ачканы турында әйтеп куймасынмы! Мине ток бәрдемени... Ләкин шундук җавабын таптым. «Шуннан? Ул монда ял итәргә килде бит! Безнең әтәчнең өч тавыгы бар әнә. Иртән ишекләрен ачып чыгаруга бездән ике йорт читтә яшәүче күрше тавыклары янына чаба. Бөтен ирләрнең дә моңа көче җитми әле!» – дидем. Гаҗәпләнүдән авызын япты теге хатын. Бу хакта Рафаэльгә сөйләп тә тормадым...

– Әй сагынырсың мине, Римма. Ничек түзәрсең... – Рафаэльнең соңгы сүзләре шул булды. Бик авыр кичердем аның китүен. Тормышымны яңадан уйлыйм да, Ходай биргән сабырлык, күркәм холык белән бик бәхетле гомер кичкәнемне аңлыйм. Ирем белән 52 ел бергә яшәдек. Шушы бәхетемә нигез салучы зирәк, акыллы кайнанам икәнен бик яхшы аңлыйм. Сигез ел инде менә, шушы йортта ялгызым хәзер. Рафаэльне искә алмаган көнем юк, күңелемнән аның белән сөйләшеп йөрим...

Бервакыт радиодан Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның гаилә кыйммәтләре турында сөйләгәнен ишетеп, туры эфирга шалтыраттым. Шул сөйләшүдән соң тормыш тәҗрибәм белән уртаклашуымны сорап, Дәүләт Советыннан хат килде. Рәхмәт хаты да алдым әле. Фәрит Хәйруллович ул игътибарын әле дә рәхмәт белән искә алам!

Балалар, өйне сатып, үзләре янына күченергә чакыралар. Ә мин теләмим... Бакчада нарат төбендә Рафаэль үз кулы белән салган җәйге веранда әле дә тора, өй салганчы ук төзеп куйды аны. Ул вакытта такталары да юк, эштән берәмләп ташыды аларын да. Җәен без шунда йоклый идек. Хәзер наратта ябалаклар оя корып бала чыгара. Шулкадәр матур алар! Агач башында абыйсы сугышка киткәндә элеп киткән сыерчык оясы да тора. Ничек калдырып китим бу кадерле җиремне? Язмышымнан бик риза-бәхил мин, әти-әни! Сез күрсәткән кыйблага тугры булып яшәдем. Сезнең алда да, Ходай каршында да бурычымны үтәдем. Сезне сагынып яшисе генә калды...

Казан–Әгерҗе–Казан.



ТЕЛӘК

Марат
КӘБИРОВ,
язучы

Безнең авылда элек бер әби гел бер дога укып йөргән. Бөтен белгәне шул булган инде. Бер мәлне мулладан әлеге доганың мәгънәсен сораган. Мулла аңлатып биргән инде:

– И-и Раббым, хәерле казалар бир, дигән мәгънәне аңлата бит бу, – дигән.

Теге әбинең артык исе китмәгән:

– Әйтәм аны, кәҗәм үлә дә страховой түлиләр, – ди икән.

– Шулай да Ходайдан каза сорама, – дип елмаеп куйган мулла.

Үзем дә шул әби хәленәрәк калдым әле. И-и, әллә нигә шулай диясе иттем шул инде. Ни белән бетәчәген белсә, кеше бар сүзен дә үлчәп әйтер, эшен дә уйлап эшләр иде дә. Хәер, уйлап эшләнгән эшнең дә барысы да син теләгәнчә килеп чыкмый.

Көтмәгәндә әнинең аягы шеште. Сызлана инде бу. Чирле кеше чәүчәләгрәк тә була бит инде, теләген шундук тормышка ашырмасаң, үпкәләп, үртәлә башлый. Чирле кешене бик үпкәләтәсе килми. Үз әниеңне бигрәк тә. Кызганыч та инде. Алай итеп, болай итеп караган булам, массаж ясаган булам, дарулар сөрткән булам. Файдасы тими инде. Үрсәләнеп, өзгәләнеп тик ята. Аптырагач, кочаклап аркасыннан сөйдем инде: «И-и Ходаем… Әнинең авыртуларын үземә бирсәң иде!» – дидем.

Аптыраганнан әйтәсең бит инде андый теләкләрне. Гомумән, Ходайга ялваруларның барысы да чарасызлыктан. Берсе дә уңышлы килеп чыкмый. Әллә уңышлы чыкканнары онытыламы. Бәлки, шулайдыр да, адәм хәтерендә читтән килгән әйбәтлек озак яшәмидер.

Тик бу юлы барысы да тиз булды. Хуҗалыктагы вак-төяк эшләрне карап керүгә, кинәт кенә аяк авырта башлады. Нәрсә булды икән дип карасам, шешеп чыккан. Бераздан үтереп сызларга тотынды. Бер дару да басмый моны, укол да, крем-мазьлар дә ярдәм итми.

Берәр сәгать чамасы үкереп яткач, чүт кенә тынгандай булды. Мин аксаклый-аксаклый әни яткан бүлмәгә кердем. Баштарак ник шулай дип әйтүемә бераз үкенсәм дә, күңелдә могҗизага ышаныч, Ходайга рәхмәт хисе чиксез иде. Югыйсә бер җиргә бәрмәдем, кыек басмадым. Мондый сызлауның шулай кинәт кенә барлыкка килүенә бер сәбәп тә юк иде. Шулай булгач, Ходай минем теләкләрне ишеткән булып чыга бит инде.

Миңа гел әнинең аягы төзәлгәндер, авыртулары басылгандыр кебек тоелды. Бер мизгелгә үземнең шушы теләгем аз гына әйбәтлек кебек күренде. Карап үстергән әнкәң өчен мондый гына сызланулар әллә ни бәя түгел ич. Үз гамәлем өчен сөенү тойгысы авыртуны да бераз басып, күңелне дә яктырткандай булды. Хәтта бүлмәсенә кергәндә иреннәргә елмаю да кунды бугай әле. Һәрхәлдә ул кырыс кына итеп:

– Нәрсә елмаясың? – дип сорап куйды.

– Аягыңның авыртуы беттеме? – дидем мин ашкынулы бер ышаныч белән.

Тик әнинең аягы төзәлмәгән, сызланулары бетмәгән иде. Шуңа ул ыңгырашуга охшатыбрак:

– Әйе менә, бетә ди сиңа, – диде.

Тик минем ышаныч зур иде:

– Тиздән бетәчәк!

Мин нигәдер бар күңелем белән сабый балага әверелдем. Өлкәннәрнең сабыйлыгы – сантыйлык инде ул. Шуңа беркатлырак кешеләрне «сакаллы сабый» дип тә йөртәләр. Мин дә ун-унбиш минут саен әни янына кереп:

– Сызлавың басылмадымы? Шешең кайтмадымы? – дип аксаклап йөрдем.

Аптырагач ул әйтеп куйды:


– Нәрсә минут саен сорап торасың инде, ничек бетәргә тиеш соң ул шул арада?

Чирнең килүе генә тиз, китүе озак икәнен ансыз да белә идем. Тик күңелдә ышаныч көчле иде. Юк, аяклар һаман төзәлмәде. Өмет өзелде инде бераз. Тик Ходайга үпкәләп булмый. Үзем гаепле. Аның сызлануын миңа бир дип түгел, ә авыртуны бетер, савыктыр әнине дип теләргә иде. Ходайга теләкләребез ирешә торган мизгелләр буладыр, бәлки. Без генә шул чакны кулдан ычкындырабыздыр, юк-бар теләкләр теләп, юк-бар нәрсәләр сорап коры калабыздыр. Югыйсә дөньяда могҗиза бар бит инде ул.



«БЕРЕБЕЗ ДӘ БУЛӘК ТҮГЕЛ...»







Киләсе елның гыйнварында Ансар белән өйләнешүебезгә утыз ел була. Энҗе туебызны билгеләп үтәчәкбез! Өч дистә ел гаилә тормышы өчен аз вакыт түгел, шуңа күрә яшьләргә – яңа кавышучыларга сүз әйтергә, кайбер киңәшләремне бирергә хакым инде бардыр дип саныйм.

Башкалар ирләрен яманлаганда, иремнең бер кимчелеген дә таба алмыйм. Мин бит аңа үзем чыктым – берәү дә мәҗбүр итмәде.

Мин тулы, тик тавышлы гаиләдә үстем. Әти кеше аракыны гаиләсеннән өстен күрә икән, хатыны өчен дә, балалары өчен дә зур афәт бу. Хезмәт хакын эчеп бетереп баруы өстенә, өйдәге әйберләрне дә чыгарып сата иде әле ул. Ул чакта авылда безнең кебек дүрт почмаклы өйдә ялгыз әбиләр генә яшәгәндер яшәсә, кәҗәне дә сауса алар гына сауган-дыр. Сөт, май, ит кунак ризыгы иде бездә. Анысына гына түзәр идең, тынычлап үз урыныбызда йоклаган төннәребез дә бармак белән генә санарлык булды.

Әни бик үткен, уңган хатын булганга гына ач яшәмәдек: ул бәйли, чигә, тегә иде. Әти мәрхүмнең исемен каралтасым килми, тик сабый чакта бәгырьгә сеңеп калган авыр хатирәләр, үпкәләүләр, илленең теге ягына чыксам да онытылмый. Без үсеп җиткәндә айныды ул үзе, тик бераз гына соңарды: абый аның юлыннан киткән иде инде. Их... Шунда әни: «Иң авыры – баланыкы икән», – диде...

Бу җөмләләрне үземне кызгандыру өчен түгел, ә бер нәрсәне аңлату өчен генә яздым: булачак иремнең әти кебек булуын теләми идем.

Мәктәпне алтын медальгә тәмамладым. Хыялым – пединститутка керү, укытучы булу иде. Укытучыларның әле хөрмәтле чагы! Тик безне, комсомол «путевкасы» биреп, колхозда сыер саварга калдырдылар. «Юкса сыерыгызны көтүгә чыгартмыйбыз, салам, печән, ашлык бирмибез», – диде партком секретаре. Ул вакытта безнең дә сыерыбыз бар иде инде. Укытучылар исә дәшми калуны кулайрак күрде...

Шулай итеп, бер ел сыер саудым. Алдагы елда, бер фәнне «бишле»гә биреп, институтка укырга кердем. Группадашларымнан бер яшькә олырак булгангадыр, староста итеп сайлап куйдылар. Менә бу урында: «Безнең өчен нәрсә әйбәтрәк икәнен Ходай үзебезгә караганда яхшырак белә», – диясем килә. Әгәр бер елга колхозда калдырмасалар, булачак ирем Ансар белән бер группада укымас идек без.

Ансарга хәтле дә йөргән егетләрем булды минем, ә кияүгә менә аңа чыктым. Һәм бер тапкыр да үкенгәнем булмады... Шулай итеп, V курста, гыйнвар аенда «Чәчкәләрнең нигә кирәге бар?» дип җырлап, туй иттек без. 1993 ел иде бу. Илдә үзгәрешләр башланган, СССР дигән бөек держаканың таралган вакыты. Яшь белгечләр буларак безнең инде беркемгә дә кирәгебез калмаган чак.

Ансар III курстан соң ук Татар яшьләр театрында эшли башлаган иде. Мин Казанның 27 нче татар гимназиясенә урнаштым. Торыр җиребез юк! Гыйнвардан майга кадәр өч җиргә күчендек. Аннан Ансар мине Островский урамындагы тузган торакларның берсенә алып кайтты. Чормага! Әйе, чын чормага. Ансар анда ике урында гына бөтен буена басып тора ала иде – калган җирендә бөкрәеп йөри. Кайчандыр бер бай анда ат сбруйларын тоткан диделәр. Алгарак китеп әйтим, Ансар белән үз фатирыбыз 30 яшьтә генә булды, ә машинаны 36 яшьтә генә алдык. Монысы – өйләнешүгә ирләреннән фатир-машина таптыра башлаган кызлар колагына иде.

Теге чормага беренче мәртәбә аяк баскан мизгел гел хәтердә. Ишек төбендә үк бер тычкан үлеп ята... Җәлт кенә иремә күтәрелеп карадым. Аның күзендә яшь иде... (Озак еллар бергә яшәгәч кенә ул чактагы күз яшьләренең сәбәбен сорадым. Үлгән тычканны кызганудан чыкмаган бит инде ул яшьләр... «Ир-ат башым белән яшь хатынымны шушындый хәрабәгә яшәргә алып кайтканыма гарьләнеп еладым», – диде ул.) Ә мин... Мин шат идем: чөнки монда үзем хуҗабикә булачакмын! (Үз гомеремдә бер тапкыр да иремнән буй җитмәслек нәрсә сорамадым, аның җанын байлык сорап талкымадым. Минем өчен иң кадерлесе – саулык һәм тынычлык. Ә Ансар янында җаным һәрвакыт тыныч булды.)

Шул чормада ярты ел Ансар белән (декабрьдә аны армиягә алдылар), бер ел берүзем тордым. (Шуннан бирле әле дә төннәрен утсыз йоклый алмаганымны гына әйтим дә...) Бөтен уңайлыклар урамда, мичкә утын ягам, ашарга пешерергә, су җылытырга, кер кайнатырга – бер комфоркалы плитә... Ансар Казанда хезмәт итте, аннан шул ук хәрби частьта хезмәткә калды. Без берәүләрнең 9 квадрат метрлы почмагында тордык. Зөһрәбез туды. «Балагыз булмас» дигәннән соң!.. Бу урында Ансарыма һаман рәхмәт укыйм: өч ел эчендә ул мине ялгышып та гаепләмәде, киресенчә, елаганда мине гел юатты.

1999 елда иремне Чечняга җибәрделәр. Сугышның икенче дулкынына барып керде ул... 3 яше дә тулмаган кызым белән кеше почмагында яшәп калдым. Әтиебездән беренче хат ай ярымнан гына килде... Ничекләр түзелгән?! Ансар хәзер дә әйтә: «Минем белән берәр хәл булса, гаиләм урамда кала дип уйлап әрнедем», – ди.

Шөкер, исән-сау кайтты ул. Андагы хәрби чараларда катнашкан өчен түләнгән акчага Балтачта ике бүлмәле фатир алып, районга күченеп кайттык. Ансар эшкә милициягә урнашты, мине Балтач гимназиясенә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары итеп алдылар.

Яшь гаилә булып оешып кына яши башлаганда, әти-әнинең безгә ярдәме күп тиде. Әни белән Ансар бигрәк тә килештеләр. Мин Ансар

Ирен бүтәннәрнең ирләре белән чагыштыру – хатын-кызларның иң зур хатасыдыр.

белән сүзгә килгән чакларда, алар әти белән гел кияүләре ягына бастылар, аны улларыдай якын күрделәр. Ирем үзе дә: «Әнкәй янына кайтам да китәм», – дип шаярта иде (ул минем әти белән әнине «әткәй-әнкәй» дип йөртте). Шуңа да икебез арасында нәрсә булса да, әти-әнигә сиздермәдем. Без дуслашачакбыз, ә алар Ансарга берәр сүз әйтсәләр (монысы мөмкин хәл түгел иде, билгеле), уртада гаепле булып калырлар дип уйладым. Әни үлеп киткәч, иремнең ничек өзгәләнгәнен күрсәгез... Авырып киткәч, әнине больницада мин – төнлә, ә Ансар көндезләрен карады. Кызганыч, әниебез безнең арадан иртәрәк китте шул.

2005 елда без китаплар сату белән шөгыльләнә башладык. Фатирыбызны сатып, йорт алдык. Ансар, полиция начальнигы урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелеп, подполковник булып отставкага чыкты. Хәзер полициядә гражданлык хезмәтендә. Карантин вакытында өй янында ашамлыклар кибете ачып җибәрдек. Ул кибетне баштанаяк ирем алып бара, мин китаплар белән генә шөгыльләнәм. Әни вафат булгач, әти белән абыйны тәрбияләү дә безнең өстә калды. Әтиемдә Паркинсон авыруы иде – ике елга якын урында ятты. Ансар берара әти белән абыйның икесен дә үзебезгә яшәргә алып килде. Аңардан «синекеләр шундый, мондый» дигән бер сүз дә ишеткәнем булмады.

Иремнең бер яраткан сүзе бар: «Беребез дә бүләк түгел», – ди ул. Әйе, без икебез ике гаиләдә үскән, ике төрле тәрбия алган кешеләр. Өстәвенә, йолдызнамә буенча да туры килмибез: мин – Арыслан, ул – Үгезбозау. Безнең гаиләдә дә төрле вакытлар була. Әмма Ансар бик сабыр, түзем кеше, тик аның сабыр савытлары тулсамы?! Мондый вакытларда эндәшми калырга тырышам: әйтәсе фикеремне барыбер җиткерәм мин аңа, тик ул суынгач, аралар җайлангач.

Хатын-кызда хәйләкәрлек, зирәклек тә булырга тиеш дип саныйм. Аннан сабырлык, сабырлык һәм тагын бер мәртәбә сабырлык. Кеше өйрәтүе бик җайлы диярсез. Шулай... Тик яши-яши аңлыйсың: бер-береңә юл куеп, хөрмәт итсәң генә, тормыш алга бара. Безнең бүгенге тормышыбызны гына белгән кешеләр аны гел шулай булган дип уйлый. Юк, мең тапкыр юк! Чын мәгънәсендә бер кашыктан башланды ул: барысын икәү эшләп булдырдык. Иремне гел шулай мактап кына торгач, күпләр мине ире җилкәсендә ятучы бер иркә хатын дип уйлый. Бу урында, гадәттә, елмаеп куям... Китап сәүдәсе белән шөгыльләнә башлаганда машинабыз да юк иде әле. Базар сумкасына тутырып, китапларны башта «попутка» белән ташыдым. Китапның авырлыгы аның! Ике кулымның ничек сызлаганын үзем генә беләм... Баумандагы «Китаплар» кибете янында «Мәгариф» нәшрияты бар иде. Менә шуннан «Кольцо»дагы трамвайга Бауман буйлап алагаем ике зур сумка белән китап күтәреп төшәм. Танышлар гына очрамасын дия-дия атлыйм. Группадаш кызлардан качып калган чаклар да булды. Аннары трамвай белән Компрессор заводы тукталышына кадәр барам да, сумкаларымны такси белән Балтачка җибәрәм. Үзем тагын ике сумка белән рус китаплары яки дисклар алырга барам. Инде машиналы булгач, район мәктәпләренә китап сатарга йөрү дисеңме?! Авылларда юллар начар, машина белән көчкә керәм (бу урында рульгә иремнән 9 елга алданрак утыруымны әйтсәм дә буладыр. Шәт, Ансарым үпкәләмәс). Ничә еллар Сабантуйларда дисклар сатуны әйтимме?! Бу вакытларда ирем бик булыша алмады, чөнки полиция хезмәткәре бәйрәмнәрдә үзе дә гел эштә ул. Бер елны рәттән тугыз Сабантуйда эшләдем, Кировка, Мари Иленә кадәр барып саттым. Мәктәптән китеп, бер белмәгән базар мөнәсәбәтләренә килеп кергәндә, ат йөрәкләре булган икән миндә дип хәзер хәйраннар калам! Тик... тешемне кысып китап ташыганда да, үҗәтләнеп Сабантуйларда сату иткәндә дә, барыбер үземне иң бәхетле хатын-кыз итеп тоя идем. Ни өченме? Чөнки янымда яраткан Ансарым бар иде. Әмма, әйткәнемчә, ир ышыгында, ул тапканга әзергә-бәзер булып кына яшәмим мин.

Бездә эш бүлешү дигән нәрсә бөтенләй юк. Ирем идән дә, кирәк булса, керен дә юа. Өйне дә юып чыга ала! Бәлеш тә сала, өстәлне дә шаккатарлык итеп әзерли. Бакчаны гөлләр итеп тота. Ә ул үстергән чебиләр бишәр килограммга кадәр җитә. Аңа карап, иремнең бер җире кителми, ирлек дәрәҗәсе дә төшми. Киресенчә, аңа хөрмәтем арта гына бара. Мин гомер буе юлыма аны чыгарган өчен Ходаема һәм әнкәйгә – кайнанама рәхмәт укыйм.

Иң зур бәхетебез турында әйтергә онытып торам икән: 44 яшемдә иремә Аяз исемле ул бүләк иттем! Балаларым өчен аның нинди әти булганын сөйләп кенә бетерә алмам... Миңа караганда, балалар өчен Ансарның йокысыз төннәре күбрәк булды бугай.

Ансар белән икебезгә гел рәхәт безнең – сәгатьләр буе сөйләшеп утыра алабыз. Минем дә, иремнең дә җан дусларыбыз юк. Кызыбыз Зөһрә инде буй җитте, Казанда яши, югары белемле юрист. Кирәк чакта, хатын-кыз буларак, аның белән киңәшләшәм. Алар да әтисе белән сәгатьләр буе нидер хакында сөйләшә алалар. Ул вакытта читтән генә карап, җаным-тәнем белән куанып йөрим, балаларымны шундый әтиле иткән Ходайга

рәхмәт укыйм. Тугрылык, хезмәт сөючәнлек, алынган эшен ахыргача җиткерә белү, үз сүзендә тору, киң күңеллелек, тиз арада кирәкле карар кабул итә алу, һәркем белән уртак тел таба белү һәм тагын бик күп, бик күп сыйфатлар хас минем Ансарыма! Дөрес, кызымның әтисе белән үпкәләшеп алган чаклары да була. Йөрәгем өзелсә дә, катышмыйм. Чөнки баланы берсе орышканда, икенчесе яклаган гаиләдә моның ахыры бик хәерле булмаганын күреп үстем. Кызым белән улыма, яшь аралары 18 ел булса да, киләчәктә бер-берсенә терәк булырга кирәклеген аңлатырга тырышам. Безнең үзебезгә моны сендермәделәр. Зөһрәгә: «Энеңә нихәтле кайгырту, ярату бүләк итсәң, киләчәктә ул сиңа аны меңе белән кайтарыр», – дим. Кызыбыз 11 нче класста укыганда авырга уздым мин. Зөһрә Казанга укырга чыгып киткән көзне таптым Аязны. Ул аны бик көтеп алды, исемен дә үзе кушты. Киләчәктә дә бер-берсен хөрмәтләп, дус булып яшәсеннәр дип теләк телим.

Акланмаска, чәпчемәскә, җае килгәндә бер-береңне мактарга, яратканыңны әйтеп торырга, бер-береңне кимсетмәскә, бер-береңнән гаеп эзләмәскә, бөтен нәрсәнең бервакыт үтәчәген һәрчак истә тотарга – гаиләдә бәхетле булуның төп нигезе шушы. Проблемалар килеп чыкса, уртага салып сөйләшергә, аңлашырга. Шунда ук аңлашып булмаса, сабыр итәргә! 30 елга якын бергә яшәп, минем бер тапкыр да иремнән аерыласым килгәне булмады. «Ир-ат күңеле – 60 бүлмә, шуның һәрберсенә дә кердем дип уйлый күрмә», дигән әйтем бар. Бик дөрес ул! Ярату, үзара хөрмәт булса, барысы да уза.

Ансарга кияүгә чыкканнан бирле, бер ир-егеткә дә ир-ат итеп караганым юк, ул да читләргә күз атып мине кимсетмәде. Юк, мин бар яктан да идеаль хатын-кыз түгелмен: көйсез-кәефсез чакларым да, хаклы булмаган чакларым да бар. Тик иң яхшы ягым – мин тугры һәм ышанычлы. Иремне беркайчан да беркемгә дә алыштырмаячакмын! Ул хаклы булмаса да, аның яклы булачакмын.

Сүзгә килгәч, ачуланышкан вакытларда, эшләр зурга китә башласа, бер нәрсәне күз алдына китереп карагыз: сез ирегездән башка да яши аласызмы? Мин – юк! Шуңа күп вакытта, хәтта үзем хаклы булсам да, авызымны ябам. Горур ялгыз булганчы, парлы килеш калам. Ә җиңелү?! Тормышта иң мөһиме бу түгел... Аннары минем балаларым әтиләреннән кала тагын кемгә кадерле соң?!

Гаиләгә бик кирәкле тагын бер сыйфатны язасым килә: без күп проблемаларны юмор ярдәмендә җиңәбез. Урынын һәм вакытын белеп кулланса, ул өйдә кайчак авыраеп киткән атмосфераны җиңеләйтеп җибәрә. Балтачка кайткач, Ансар күп еллар түй-юбилейларга тамада булып йөрде. Әлеге дә баягы акча җитмәгәнгә инде... Аннары әле без аның белән полиция, мин укыган мәктәп, минем туган авылым өчен КВНнар, спектакль-концертлар әзерли идек. Болар безнең гаиләне тагын да берләштерде, ныгытты. Улыбыз балалар бакчасына йөргәндә, Ансар тәрбиячеләр белән спектакль әзерләп, үзе дә уйнап, районда беренче урынны алдылар.

Һөнәре буенча Ансар да минем кебек – укытучы. Әмма нинди генә эшкә алынса да, ул аларның барысын да «бишле»гә башкара. Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрында эшләгәндә төп рольләрне уйнады. Хәрби хезмәттә чакта солдатларының иң ышанычлы дусты булды. «Грозный, но справедливый», – диләр иде аның турында. Милициягә эшкә кергәч, подполковник дәрәҗәсенә җитте. Ике тапкыр районның Мактау тактасына куелды, республика буенча бирелгән диплом-грамоталарын санап та тормыйм. Полициядә аның кул астында эшләгән егетләр: «Безне эшләтә дә, мактый да белде – беркемнән дә кыерсыттырмады», – дип искә алалар. Мин товарга чыгып китсәм, урыныма басып, китап сата. Ашамлыклар кибетенең барлык документ эшен үзе алып бара. Сатучылар берәр сәбәп белән эшкә чыга алмаса, аларны да алыштыра. Тырышлык, үҗәтлек, максатчанлык – менә бу чын ир-егет сыйфатларының барысы да бар аңарда.

Безнең гаиләдә акчаны Ансар тота, гаилә кассасы да аңарда. Без гел хөкүмәттән ссуда алып торабыз: берсен түләп бетерәбез дә тагын алабыз. Өйләнешкәннән бирле акчаның тотрыклы булганы юк: ссудасыз ерак китә алмыйсың. Барлык керем-чыгымнарны санау, түләүләрне вакытында күчереп бару Ансар өстендә. Ул исәпли, ул җиткерә. Ашаган белми, тураган белә диләрме әле? Ә син нишлисең соң диярсез. Минме? Мин иремне яратып, чын күңелемнән мактап, үсендереп, аңа рәхмәт укып торам, чөнки ул – минеке, берәү генә, кабатланмас! Кимчелекләре бардыр бит дисезме? Ә менә анысын инде чит кешеләргә белү кирәкмәс...

Көн саен, гадәттә, кич белән табын артында үткән көн турында сөйләшәбез, иртәгәге көнне планлаштырабыз. Әйе, без дә шушы катлаулы заманның «эшем кешеләре»: ике бизнесыбыз бар, быел улыбыз белән икенче сыйныфка барабыз – класс тормышында актив катнашабыз. Тик менә шушы кичке сөйләшүләребезне көтеп алам. Рәхәт миңа яраткан кешем белән кара-каршы сөйләшеп утырулар. Рәхәт һәм тыныч!

Безнең өебез дә, машинабыз да артык зур түгел, башкаларда булмаган байлыгыбыз да юк. Аның каравы, Ходай сөеп биргән зур хәзинәм – ирем, ике балам бар!

Гөлнур ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА.
Балтач.

Фото: гаилә архивыннан.

МӨСЕЛМАН МОДАСЫ ДИГӘН ТӨШЕНЧӘ БАРМЫ?

Бу сорауны без әхлаклы мода өлкәсендә эксперт, «Modest Covered»ка нигез салучы, Fashion Iftar проекты авторы Җәннәт МИНҺАҖЕВАга бирдек.

Мин, юк, дияр идем. Төгәлрәге, әхлаклы, инсафлы модага игътибарны юнәлтер идем. Ул мөселман хатын-кызларына гына түгел, башка дин вәкилләренә дә карый.

Дөньяда әхлаклы мода – «modest fasion» буларак билгеле. Әлеге юнәлешнең башы 2017 елга барып тоташа. Хәлимә Аден хиҗапта беренче модель буларак дебют ясый. Шулай ук Лондонда, Истанбулда, Дубайда, Джакартада һәм минем команда канаты астында Россиядә мода атналыклары уздырылды.

Ләкин төренеп йөрүдә аермалыклар бар. Әхлаклы мода киңрәк төшенчәдә каралып, анда ябык киемнәргә катгый кагыйдәләр таләп ителмәсә дә, исламда гаурәт дигән төшенчә бар. Ягъни кием сыланып тормаска, кул чуклары, йөз һәм тубыктан аяклар гына күренеп торырга, чәчләр капланган булырга тиеш.

Мөселман хатын-кызы образ тудырганда, трендлар артыннан кумыйча, эчке үзгәнә һәм стильгә таяна. Ләкин ул теге йә бу ел фасылында актуаль булган төсләр, фасоннар һәм аксессуарлардан да файдалана ала.

Традицияләргә иярү шулай ук һәр кешенең үзеннән тора. Россиядә аеруча күп сүз кузгата торган нәрсә – исламда төрек, гарәп модасы дигән нәрсә юк. Кара абаялар да дин тарафыннан кертелмәгән. Ул, барыннан да бигрәк, гарәп халыкларын кояштан саклый торган милли кием.

Күпмилләтле ил саналган Россиядә дә соңгы вакытта, таяну ноктасы буларак, тамырларга мөрәҗәгать итү күзәтелә. Шунысы куанычлы: Татарстанда да образны традицион татар элементлары – изү, бизәкләр белән баета башладылар.



БЕЛЕШМӘ:
Хәлимә Аден 2016 елда АКШта узган гүзәллек бәйгесендә хиҗап кигән беренче җиңүче модель булды. Һәм ул мөселман кануннарын сакларга тырышып, модель буларак уңышлы карьера ясады. Хәлимә Кениядә качаклар лагеренда туган. Аның гаиләсе чыгышы белән Сомалидан: 90 нчы еллар уртасында Африка кыйтгасында барган иң канкойгыч сугышлардан качып киткән булганнар. Әнисе унике көн буена җәяүләп Кениягә барып җиткән. Хәлимәгә 6 яшь булганда, ул әнисе һәм энесе белән Америкага күченгән. Сугыш вакытында әтисе белән элемтә өзелгән. Дөнья Хәлимәне хатын-кыз модасында ябык киемнәргә өстенлек биргән юнәлеш – modest fashion йөзе итеп кабул итте.



Фото: Хәлимә Аденның социаль челтәреннән.

никах студиясе
«Muslim Express»

САТУ ҺӘМ ПРОКАТКА БИРҮ

Кәләшләр һәм никах кунаклары өчен күлмәкләр

Кияү егетләре өчен түбәтәйләр һәм камислар

- Казан, Карбышев ур., 50
- Әлмәт, Ринат Галеев ур., 3, пав. 222

8-917-399-74-88

muslimexpressru Реклама

КИЕМ ТЕГҮ

*ваклап һәм күпләп сату**

- махсус эш киемнәре
- балалар, ирләр һәм хатын-кызлар киеме
- тукыма һәм фурнитура сайлау

БРЕНДЛАРГА ТЕГӘБЕЗ

- бирка һәм этикетка
- төргәкләү

уңайлы бәяләрдән – югары сыйфат

**10 данәдән күпләп сату бәяләре*

Казан, Бертуган Петряевлар ур., 5 йорт, 5 корп, 302 оф.

8-953-499-99-23

vk.com/poshivrf

Реклама

Затлы милли күлмәкләр, эшкә кияр өчен уңайлы классик костюмнар, озын жилет белән чалбарлар, туникалар, никах күлмәкләре, тюрбан-яулыклар.

Альбина Фазлыева кибете

Казан, Тукай ур., 23 5/1
Туфан Миңнуллин ур., 14/56
(«Туган авылым» комплексы),

Татарстан, Балтач, Ленин ур., 64

8-919-633-82-08

Реклама

Nikah dress studio

никах өчен дизайнер күлмәкләре студиясе

никахка / көндәлеккә / кунаклар өчен күлмәләр / намаз укыганда кияр өчен үзебездә тегелгән уңайлы, стильле, сыйфатлы мөселман киемнәре

8-999-169-74-20
8-927-413-15-03

«НУРЛЫ» мөселман галереясы
Казан, Париж Коммунасы ур., 25/39 йорт

Реклама

ILSIYAR

SUNNAH· CLOTHING · BRAND

ILSIYAR – шәригать буенча мөселман киеме
Хаҗ өчен киемнәр
Буе размер белән тәңгәл килә
Һәр яңа киемне үзебездә сыныйбыз
Казан һәм дөнья буйлап китереп бирү мөмкинлеге бар

Казан шәһәре, Габдулла Тукай ур., 23
8-905-025-64-68
8-903-342-30-17
VK.com/ilsiyar_ru

Реклама

Никах өчен күлмәкләр, тантана кунаклары өчен киемнәр, көндәлек мөселман киеме

Казан, Чистай ур., 88

Париж Коммунасы ур., 25/39 («Нурлы» мөселман галереясы)

8-986-918-35-16

yuliya_mansurova

Реклама

Рифә Рахман шигырьләре хис-тойгылар өермәсе кузгата алуы белән тансык, һәрчак көтеп алынган... Хикәяләрендә – чынлап ярата белгән, эчке дөньясы бай кыз образы, көтелмәгән сюжетлар, көтелмәгән чишелешләр... Аның китаплары исемнәре белән үк үзенә тартып, укыйсыны китереп тора. «Төнге кояш», «Күзгә төн күбәләге», «Керфекле тәрәзәләр», «Мине генә уйла!», «Коела йолдыз», «Синең янга узсам...», «Айлы күлдәвекләр»... Шагыйрәнең үзен исә иң беренче китабы исеме белән «Шук алма, моңсу алма» дип атыйсы килә. Шук-шаян да, уйчан-моңсу да, хыялый-романтик та ул.
Язучы һәм шагыйрә, журналист, әдәбият галиме, мөгаллимә Рифә Рахманны гомер бәйрәме – 60 яшьлек юбилее белән котлыйбыз! Иҗат уңышлары телибез!

Рифә РАХМАН

СИН – ШӘМӘХӘ КӨЗЕМ МИНЕМ

Килен булып төшсәм

Шигыремне сиңа бүләк итәм,
Кәләш мирасымда – тик шигырь.
Кыскасы бар аның, озыны да.
Ул – чәчәкләр чиккән сөлгедер.

Ул тастымал түгел кул сөртелгән,
Ул башъяулык сыман – саф, чиста.
Килен булып төшсәм йортыңа мин,
Шигырьдән аш салам һичьюкта.

Шигырь укып чыгам төн буена,
Хисләр төне диеп атарсың.
Кыз куенына кергән зәфафыңда
Шигырь ятагында ятарсың.

Таңнар атар, шигырь укып кына:
Кичкә кадәр җитмәс ахыры.
Шагыйрәгә ярәш йөзек бирә
Ир-атларның бары батыры.

Ихлас сөйгәннәре, нечкәләре,
Күңеленә үтеп кергәне.
Ул төн узар, әмма шигырь сөйләр
Гомерең буе зәфаф мендәре.

Ак-кара, димәскә...

Йолдыз яктысында вәгъдә бирәм
Яндырмаска сине, сөймәскә.
Шундый уен да бар: ул башлангач,
Авыз – йомык, кирәк көлмәскә.
Сөям-сөймим дигән бәхәсләргә
Вәгъдә бирәм һичбер кермәскә,
Ак-кара дип сине атамаска,
Кагылмаска сиңа, тимәскә.

Вәгъдәм тотсын мине, үтәмәсәм.
Шул минутта йолдыз йотылсын.
Ымсындыр син мине. Ымсындыр син...
Миңа җәза булсын шул ымсын.

Ә мин күрәм!

Җил күренми, диләр,
Ә мин күрәм:
Кара күлмәгенә киенә дә
Йөгерә ул һәр көн
Таң белән!
Тәрәзәмә килә –
Сөртә корым.
Ишегемә килә –
Каралта!
Шәһәр җиле,
Хәтта таңгысы да,
Никтер кара төсләр ярата.
Җил күренми, диләр,
Ә мин күрәм.
Су янында
Карап басып торам.
Үзе күрмәсен дип,
Кумасын дип,
Таллар арасына
Качып торам.
Җил күренми, диләр.
Ә мин күрәм,
Таллар арасыннан кулны сузып
Тотам аның
Зәңгәр күлмәгеннән.

Эзләп йөрим

Таныш урыннарны эзләп йөрим.
Шәһәр бакчалары бик якты.
Тынычлыкны урлый торган сагыш,
Төнгә кергәч, төртеп уятты.

Алып чыкты икәү бергә йөргән
Тыкрыкларга, күлләр янына.
Ялгыз куырылган агачлар бар...
Күңел шуңа сине сагына!

Су өсләре тыныч кына тора.
Дулкын тынган. Суда – ай эзе.
Йөзләрендә синең чалымнарың!
Ә бит ай да бүген берүзе!

Күл өстендә йөзгән кошлар да так!
Нинди төн бу?! Нинди ялгызлык?!
Хәтеремдә генә яшимени
Күңел тынычлыгы, ямь-кызык?..

Хәтеремдә генә сакланамы
Йокы баскан төннәр, көннәрем?..
Төн йокыңны алып китәм, дидең.
Хак булган бит әйткән сүзләрең!

Үзгәреш

Авыл урамыннан атлыйм.
Утлар сүндерелгән.
Без үскәндә лампа иде,
Димен күңелемнән –
Балачакта шуңа күрә
Серле иде төннәр.
Караңгыдан кайтып кергәч,
Төшле иде мендәр.
Авыл урамыннан атлыйм,
Этләр кала өреп.
Алар юаш һәм бик тә аз
Була иде элек.
Таяк, фонарь ала идек,
Ялгыз булсак, юлга.
Капшар өчен төртеп аны
Уңга-сулга, уңга...
Баткак иде, тайгак иде,
Чокыр-чакыр, ташлар.
Ай яктысы иптәш иде
Күп чак ялгыз башка.
Кайтып керсәң төн катында
Тәмам арып-талып,
Әти аш җылыта иде,
Олы мичкә ягып.
Әби җылы оекбашлар
Суза иде кулга.
Барам авыл урамыннан...
Юк шул кайсыгыз да...
Әни генә көтә хәзер,
Әле ярый исән!
Капка төбендә торган ул!
Юктыр һичкем дисәм...

* * *

Л-кә

Яманлыкны санап яхшылыкка,
Яшәгәнмен икән үзең белән.
Чын мәгънәсе кайтты эшләреңнең,
Карадым да читләр күзе белән.

Мәгънәләре кайтты бөтен сүзнең,
Бөтен эшнең, синнән аерылгач.
Тик файдасыз: булмый очып, кочып,
Канатларың ирдән каерылгач.

Ә мин риза кабат саташырга,
Бәяләргә сине, аңламаска!
Риза кабат үлеп яратырга –
Аек акыл белән карамаска.

Көнне – төнгә, төнне көнгә тиңләп,
Ничек кенә сине акларга соң?
Инде үзем сиңа ышанмагач,
Беркатлыдай ихлас якларга соң?

* * *

Син шәмәхә көзем микән минем,
Син миләүшә күзле яз микән?
Нигә һаман сиңа үпкәлим мин,
Биргән назың бик тә аз микән?

Үпкәләтер эшләр эшләдеңме,
Әллә берни эшләмәдеңме?
Яннарыма иртәләрен килдең,
Юри миндә кичләмәвеңме?

Назлар бирмәс өчен, матур сүзләр
Әйтмәс өчен, миңа эңгердә
Килмисеңме? Иләс-миләс хисләр
Үтәр дисең мәллә күңелгә?

Зәңгәр чәчәк аткан җәй түгел син,
Сары чәчәк аткан яз түгел.
Син – шәмәхә көзем минем. Йә хуш,
Минем яшьтә ул да аз түгел.

Чыбыксыз телефон

Сөйләшербез, имеш, шалтыратсаң,
Кавышырбыз, имеш, яратсаң.
Алло, алло, дисең ераклардан,
Мин, исәнме, димен бу баштан.

Инде мине югалтмассың, дисең,
Килеп торыр, имеш, хәбәрем.
Алло, алло, дисең мең-мең кабат,
Кирәкмәгән кебек сәламем.

Искә төште бала чагыбызның
Капка төбендәге кичләре.
«Телефонның чыбыксызы» аша
Без җиткерә идек хисләрне.

Ә ул татлы сүзебезне боза,
Серне ача иде ятларга.
Сине сөям, диеп кычкырсам да,
Кемне, димә инде, йә Алла!

Серенада

Таң җиле, сәлам илтсәңче ярыма,
Килсен ул елганың сул як ярына.
Хисләрнең елга кебек ташкан чагы,
Баксын ул күзгә каршы яктан гына.

Таң җиле, хатлар илтсәңче ярыма,
Җилдереп барып җитсәңче янына.
Хатларым төшеп китсә кулларыннан,
Уйлармын, сүзе үтте, дип, җанына.

Таң җиле, көйләр илтсәңче ярыма,
Ул көйләр дәшсен иде тугаема,
Ризалык биргән кебек кавышуга,
Килсәче елганың сул як ярына.

* * *

Укыма син минем китапларны –
Кулларыңа үзе кермәсә.
Башларыңны тәмам бутамаска
Яхшы булыр, бәлки, шул нәрсә.

Эзләмә син һәрбер шигыремнән
Тормышыңнан алган детальләр.
Кабатлана кеше язмышында
Безгә таныш булган бар хәлләр.

Кабатлана сөю-сөелүләр,
Югалтулар килә артыннан.
Боларны бит үземнеке кебек
Шигыремә кертер хакым бар.

Укыма син минем язганнарны,
Кемдер өчен атап язмыймын.
Оныттым мин сине, оныттым мин!
Онытмадым, диеп алдыймын.

Мин сакламыйм хәтта балдагыңны,
Тәрәзәмнән аттым мин аны.
Китапларны ыргыт уякларга:
Бетсен янып, калмый кузлары.

Китабым бар кибет киштәсенә
Карап тормый гына үтсәң син,
Тияр файдаң: яңа мотив-тема
Шигыремә кертеп китәрсең.

Хуш, сөеклем!

Хуш, сөеклем!
Хуш, күзләрнең
Кара керфеклесе!
Саклап яшә
Узган җәйнең
Минле генә төсен.

Хуш, карлыгач,
Хуш, сандугач,
Хуш син, серле кошым!
Салкыныннан качып китәм
Бу ел килер кышның.

Хуш, кадерлем,
Иреннәрнең
Өзеп үпкәннәре!
Ят җилләрнең
Синең яктан
Читкә эткән мәле.

Хуш, сөеклем,
Хуш, күзләрнең
Кара керфеклесе,
Битеңдәге алмаларның
Көрән төрткелесе!



Укучыларыбыз аны язмалары аша яхшы белә, теленнән, стиленнән үк танып ала: Асия Юнысова язган дип яратып укыйлар. Геройларның язмышы белән кызыксына башлыйлар. Сүзнең тәмен белеп, рәхәт бер дулкында онытылып укырлык итеп яза ул. Повесть-хикәяләрендәме, журналист язмаларындамы, шигырьләрендә сурәтләнәме – бар да җанга ятышлы, мәгънә салынмаган бер генә җөмлә дә юк аңарда. Тирән белеме, бай тормыш тәҗрибәсе, фәлсәфи фикерләре, йөгерек уйлары, сәях җаны, бер-берсен тулыландырып, иҗатын баета. Бүген Асия Юнысованы 75 яшьлек юбилее белән котлыйбыз! Иҗатына илһамлы сәгатьләр телибез!



Асия Юнысова

САЛАВАТ КҮПЕРЕ

(Хикәя)

Зәңгәр ефәк яулык сыман җәйрәп яткан күк читендә посып кына бер нәни болыт эленеп тора икән. Һава торышын чамаларга теләп тәрәзәгә килеп капланган Елена Ниловна шул нәни болыт кисәгенә сынаулы карап алды. Яшәреп тора бит бу болыт. Күптән инде үзен шәһәрләшкән дип йөрүче бу ханымда авыл кызы һаман яши икән ләбаса! Әнә бит башына килгән беренче җөмлә үк аны «сатты». Шәһәр апасы сиңа яңгыр болытын шундаен итеп бәяли белерме: яшәреп тора, имеш! Яхшы дигәндә дә ул: яңгыр яварга охшап тора яки яңгыр булмагае, зонтигымны (һич тә кулчатырымны түгел!) алырга кирәк булыр, дип әйтер. Тәрәзәгә капланган ханым – бала чагын авылда калдырып килгән Зәлинә Наил кызы иде шул. Хәзер менә егерме ел инде ул Мәскәү янындагы Алтын боҗрага кергән Н. шәһәрендә музыка училищесы директоры булып эшли. Дәрәҗәле уку йорты, дәрәҗәле вазыйфа... Урыс арасы. Шуңа күрә ул беренче көннән үк Елена Ниловна булып куйды. Әйбәт яңгырый бит. Телләре сөякле халык балаларына әйтергә-эндәшергә ансат булсын дип уйланылгандыр инде. Татар икәнлеген белеп алучылар да, чын дөрес исем-атыгыз ничек соң сезнең, дип аптыратмый. Нигә ул аларга – Елена Ниловна, и вәссәлам!

«Яшәргән» болыт кисәге ул арада шактый кабарган икән. Зәлинәнең әбекәе теленнән кереп калган сүз инде бу. Болытның «елыйсы килгәнен» аңлата торган бу гыйбарә белән күз яше арасында нинди бәйләнеш бар икән соң? Музыка ноталарын, дирижерлык ымнарын бик яхшы белә дә бит, ә менә кадерле, тәмле телендәге нечкәлекләрне, аерым сүзләргә сыенып калган серләрне аңлап-тоеп бетерми шул Зәлинә-Елена.

Казандагы уку йортын тәмамлаганда кулына юллама алгач, илнең мәдәният үзәгенә якын булам дип, сөенә-сөенә килгән иде ул бу шәһәргә. Төркемдәшләре әнә авылларга да таралды. Ә кызга эшкә билгеләнү кәгазенең «бәхетлесе» эләкте. Яхшы укыганга күрә инде бу. Тырышты шул. Югыйсә музыка мәктәбе күрмәгән авыл кызының нәфис сәнгатькә юлы сикәлтәле булды. Урта мәктәпнең тугызынчы сыйныфында укып йөргән җирдән мәктәпне ташлады да махсус белем бирә торган училищега китеп барды. Кызыл тышлы аттестаты

аны Казан педагогика институтының музыка факультетына китерде. Ә дипломы – Мәскәү янына…

Менә хәзер инде ул мәшһүр каланың алтын түбәтәйле чиркәү гөмбәзләре өстендә уйнарга керешкән яшен чыбыркыларын күзәтеп хозурлана.

«Яшәргән» болыт тәки өлгереп җиткән икән бит – дөбердәтеп ява да башлаган. Авылда булса, хәстәрчән әнкәсе яңгыр суын җыеп калыр өчен ләгән-кисмәкләрне түбә кыегыннан җәһәт аккан яңгыр суына юнәлеш бирә торган улак астынарак куяр иде. Мунчага ярый ул яңгыр суы. Керне дә агарта. Кое суы кебек каты булмый бит ул. Авыл шулай фикер йөртә. Яңгыр һаваны сафландыра, юл тузанын баса, урамнарны юа дип куана шәһәр халкы.

Авыл яңгырының вазыйфасы күбрәк. Мәшәкате дә… Бүгенгедәй дөбердәп яуган яңгыр беренче нәүбәттә тишек-тошыкларны искәртә. Әнисе колагын сагайтып тыңланып ала булыр. Елның елында яңгыр малайлары юлын таба торган нәни тишектән тамчы тамганы ишетелмиме? Ишеткән икән әнисе. Бидрә кертеп куйган. Сыңар-сыңар тамчылар бидрә төбен яңгыратып тамгалап тора. Иртәгә үк туфраксаның шул турысын һәйбәтләп сылап куясы булыр. Алда көзге яңгырлар да бар бит әле. Түшәм өстенә җиңел сөякле Зәлинә менәр…

Елена Ниловна әнисе булып уйлый башлаган түгелме соң? Авылның шул инде аның: мәшәкате белән романтикасы бергә – канга сеңеп калган. Яңгырдан соң урам тутырып зарлана-зарлана кайтып килүче мал-туарны каршылап, җылы абзарга ябасы, җиленenә ябышкан мәтедән аралап, сыерын савасы, адашып калган сарык бәтиләрен юллап алып кайтасы бар. Кичке яңгырдан соң шулайрак була. Ә көндез явып үтеп, ялтырап кояш чыккан җылы яңгырлар – балачагага бәйрәм. Соңгы тамчылар, иртәгәсен дә бик җылы көн булачагын вәгъдә итеп, озонлы һава белән тулган куыкларын кабартып туктауга, яланаяклар урамга сибелә. Яланаякларга «лаклы итекләр» – үзле кара мәте сылап куелган. Бернинди «чебиләр дә» чыдамас моңа. Чыдарлыкмы соң? «Лаклы итек»не фәкать кычытканның үрмә чылбырлары белән генә кыргычлап юып төшереп була лабаса! Шифасы да шул инде аның. Шәһәр балалары аяк чебиләүнең нәрсә икәнен беләләрме икән? Юктыр. Аларның яланаяк йөргәннәре бармыни соң. Зәлинәләр аяк киемен көзен мәктәпкә барганда гына кия торганнар иде.

Елена Ниловна инде хәзер шифалы яңгырдан соң янәдән зәңгәр ефәк яулыгын ябынып куйган аяз күккә карап, үзенең дә сафланып калганын тоя. Тик никтер тәрәзә яныннан китәргә ашыкмый. Тәрәзә пыяласы артында калган авылы, балачагы ымсындырып тота бугай аны. Зәлинәнең яңгырны җибәрәсе килми. Тагын-тагын яусын иде әле. Аның бит яңгырга кушылып тыенкы гына елыйсы – «яшәрәсе» килә. Яңгырга гына сөйләп була торган хатирәләре, татлы сагышлары байтак әле аның.

Тәрәзә пыяласына ябышкан чәнчә бармак бите хәтле бер эре тамчы Зәлинәнең күзенә текәлеп туктап калган. Эленеп тик тора. Яшьле күз диярсең. «Син нигә миңа болай моңсу итеп карыйсың? Мине таныйсыңмы әллә син?» – дип, Тамчы белән сөйләшә башлаганын үзе дә сизми калды Елена Ниловна. Тукта… Кайда күргән иде соң әле ул шушындый мөлдерәмә тамчыны? Гомеренең кайсы җәендә? Хәтерли дә сыман. Мәктәп баласы авылдагы һәр мәшәкатьтә иң кирәкле бер эшем иясе бит ул. Балачагадан башка бер эш тә бармый авылда. Эш чыкмаса, аны уйлап табалар.

«Кырлар патшасы» кушаматы алган кукуруз игү алар авылында көтелмәгәнчә киң колач алуга, мәктәп балаларына яңа вазыйфа табылды. Икешәр-икешәр җитәкләшеп, кукуруз басуыннан карга куасы булды. Кукуруз ике кыяк чыгаруга, басуга каргалар ияләшә. Америкадан кайткан бу яңа төр ашның җиргә җиңелчә генә күмелгән алтын орлыкларын ничектер бик тиз бәяләп алдылар бу кара кошлар. Шунда барып күреп кайтканнардыр дияр идең, алар океан артына кадәр очучы күчмә кошлар да түгел бит инде югыйсә.

Яңгырлы бер иртәдә басудан карга куу чираты Зәлинә белән Сәриягә җитте. Таң йокысын бүлеп, ике кыз бала киттеләр кукуруз басуына. Ярый әле ул заманда сукбай этләр юк иде. Хәзер булсамы… Ә менә каргалар кызлардан алда килгәннәр. Тәмам яктырып бетеп, яңгыр юган ояларда кукуруз орлыклары ялтырап ятачак мизгелне көтеп утыралар. Басу полосасы урман ышыгында – дым ятарга тиешле урында. Кадерләп үстерәләр «Кырлар патшасын».

Каргалар кызларны яратмады. Өнәмичә генә каркылдашып алдылар да, «без юк монда» дигәндәй, шомраеп калдылар. Алай да сыңар күзләре – кызларда, икенчесе – ымсындырып торган яшел кыякларда. Кызлар уяулыкларын сиздереп, көш-көш диешеп, аваз салган булалар, йөгергәләп, кыймылгалап алалар. Бер авырлыгы булмаган бу эш тә ардырды. Алмаш кайчан килә бит әле. Кызларның эчәселәре килә башлады. Су алып килә белмәгәннәр икән шул. Яңгыр явып торганда кем су эчәсе килер дип уйласын инде. Алар да уйламаган шул. Сәрия җаен тапкан әнә – тупыл яфрагын имеп тора. Зәлинә дә тупыл яфрагын сайлады. Чөнки аның яфраклары касә кебек җәлпәк. Яфракка җыелган суы да мул. Зәлинә тәрәзәсенә килгән теге тамчыны шул яфракта күргән иде инде. Алка кашы кебек җемелдәп торган тамчы иде ул. Тәмле, баллы тамчы… Менә шул тамчы бүген аны таныды. Зәлинәнең Тамчы белән уртак олы сере бар икәнен әллә белә микән ул?

Ул елны кукуруз котырып үсте. Кукуруз урманына кереп киткән комбайн бункеры белән күмелә торган иде. Зәлинәләр, Сәрияләр, Нәҗияләр кукуруз чәкәннәренең чәчен үреп, курчаклы уйнадылар ул җәйдә. Яшь җилкенчәк исә кукуруз арасында, ят күзләрдән качып, үбешә иде бугай. Мал-туарга ярар диеп, авыл кешеләре гайрәтле кукурузлар төбен сарган эт эчәгесен җыю белән мәшгуль. Рөхсәт бар



иде. Эт эчәгесе арасына кыстырып чәкәннәр дә кайткалый.

Кукуруз дәвере алар авылы хәтерендә нәкъ менә маҗараларга бай хатирәләре белән кереп калды. Тәмле ашаган сыерлар мул сөт бирде. «Үсә кукурузларым, / Сөям ферма кызларын» дип җырлый-җырлый кукуруз иккән комбайнчы егетләр СССР Халык Казанышлары Күргәзмәсеннән көмеш медаль белән кайттылыр. Мәскәүгә мәртәбәле сәяхәт сыер савучы чибәр кызлар өлешенә дә тигән иде. Уңыш, бәхет, дәрәҗә булган урында мәхәббәт булмый каламы соң инде. Гөнаһлы мәхәббәткә уралучылар да, аннары кавышучылар да булды. Мәхәббәте көчле булу сәбәпле телгә керүчеләрнең берсе Зәлинәгә кодача тиешле чибәркәй иде. Бик матур кыз үстерде ул.

...Кинәт күк йөзе тылсымлы бер матурлыктан балкып китте. Салават күпере! Күпме яшәп, шәһәрдә салават күпере күргәне юк иде Елена Ниловнаның. Абау! Сөбханалла! Аның үзен гел авылдагыча тотасы – яңгырга сөенәсе, салават күперенә сокланасы килә икән ләбаса. Бу хозурлыкка ялгыз гына соклану мөмкин түгел кебек тоелды: «Әй улым, тизрәк кил әле бире, – дип, ул үсмер улын янына дәште. Билгеле ки, русчалатып әйтте: «Радуга! – Аннары капыл гына үзен дөресләде: – Салават күпере!»

Рәсем ясап утырган акыллы улы, кузгалып, әнисе янына килде: «Ты мне раньше не показывала. Я думал «Радуга» – это набор карандашей. У меня же есть «Радуга.» Ой, как красиво! Откуда она взялась?»

Елена Ниловна улына салават күперенең нилектән хасил булуы хакында үзе белгәннәрне сөйләде. Мәктәптән үк ятлап калган «каждый охотник желает знать где сидит фазан» дигән төсләр «ачкычын» да ятлатты. «Барысы җиде төс салават күперендә. Һәм алар гел бер тәртиптә тезелә. – Малайга яңа мәгълүмат бик кызык тоелды. Сорау арты сорау туа торды. Елена Ниловна да салават күпере хакында улына нидер сөйли алуына сөенеп, бала чагында әбисеннән ишеткәннәрен исенә төшерде.

– Фәрештәләрнең Аллаһны данлавы, рәхмәт укуы инде ул. Кайбер кешеләр аны җәйгор дип тә әйтә. Төштә салават күперен күрсәң, яхшыга, мул, бәхетле тормышка юрыйсы. Салават күперен күргән көннәрендә гел уңарсың. Синә исемне Салават дип кушуым да шуңа – гомерең буе эшләрең гел уңып торсынга иде бит инде.

Улы бу мәгълүматтан кинәнеп, рәхәтлек кичереп, янәдән рәсем ясарга барып утырды. Малай үзенең нигә кадерле икәнен моннан ары да Салават күперенә бәйләп яшәп китәр микән? Ә бит сәбәп тирәндәрәк!

Алтын бөҗра шәһәрләре рус мәдәнияте белән яши. Елена Ниловна булып алгач, Зәлинә дә үзендә ниндидер алмашыну тойды. Тик менә әнисенең: «Кызым, яшең чыгып бара. Үзеңә иш тап», – дигән сүзләренә генә бервакыт ярсып китте: «Мин сезгә татар кияүне каян табыйм? Юк анда татарлар!» Алай да Зәлинә иптәш кызы янына Мәскәүгә кунакка баргач, тапты бер татарны. Бу юлы да аңа үз халкының мәдәнияте ярдәмгә килде.

– Безнең Зәлинә дирижер гына түгел, җырчы да бит әле ул! – дип таныштырган иде дус кызы аны үз кунаклары белән. Арадан бер кунакның кызыксынучан карашы кич буе Зәлинәдән китмәде. Аның Елена Ниловна икәнлегеннән дус кызының хәбәре юк иде әле. Шуңа күрә кунаклар кызны Зәлинә дип танып калды.

– Сез татар кызы бит, әйеме? Сезне җырлый дип тә әйттеләр. Җырлагыз әле берәр татар көен? Бик сагындым, – диде теге утлы күзләренә сагыш оялаган бөдрә чәчле, буйчан гәүдәле, җылы куллы ир-ат.

Зәлинәне бу ир-атның кайсы сыйфаты әсир итте – утлы карашымы, аркасына кагылганда тоеп калган кул җылысымы – әллә барысы бергәме? Кыз үзе дә татар җырын сагынган иде. Бик рәхәтләнеп җырлыйсы килеп китте. Бу кешенең күңелен яулап аласы килү дәрте кабынды. Теге ир-атның күзләрендә дә кинәт очкын кабынды. Кызыксыну гына түгел иде бу. Дәррәү үрләгән мәхәббәт ялкыны иде. Мәхәббәтне еллар буе зарыгып көткәндә шулай була – бер караш, бер кагылудан яшен яшьни.

Таныштылар, кавыштылар. Кыздан шактый гына өлкән яшьтәге Саша үзе дә Сәмигулла икән. Өстәвенә, Мәскәүдә фатиры бар. Эше дәрәҗәле. Зәлинәгә мәхәббәте көчле. Менә шулай итеп кинәт бәхет ишелеп төште кызның иңнәренә. Гомерле булсын бу бәхетем дип теләк теләргә уена килгән иде микән?

Күкләр гамәлен белмәссең... Гел шулай уңай гына китәр бу дөньялар дип, ваемсыз гына яшәп ятканда бер ягы кителә дә куя кытай касәсенең. Гел җаваплы эшләрдә эшли торгач, Сашаның йөрәге бик таушалган икән. Ишемия! Беренче тапкыр иренең йөрәк өянәгенә шаһит булгач, Зәлинә коелып төште. Дәваларга! Елына ике тапкыр Кырым шифаханәләренә барыр. Зәлинә аны үзе дә тәрбияле яшәтер. Кайнана исән иде әле. Килененә сокланып туя алмады.

Сәмигулланы чир түгел, фаҗига алып китте. Чираттагы тапкыр Сашасын Кырымга озатырга аэропортка Зәлинә үзе дә барган иде. Югыйсә башка вакытта эштән бик китә алмый. Теге Алтын бөҗра шәһәренә йөреп, училищеда укытуын һаман дәвам итә иде бит әле. Мәскәү фатирына атнага бер кунакка гына килеп йөрешле. Күрешүләр тоташ бәйрәмгә әйләнә торган иде. Сашасын татар җырына коендырып та карады инде Зәлинә. Ире дә, үзе дә бәхетлеләр иде. Муллык булган җирдә бәхеткә бик уңайлы була бит ул. Инде менә, ниһаять, карынының буш түгел икәнлеге дә беленде. Шатлык өстенә шатлык бит бу. Димәк, булачак әти кешегә чирләшкә булырга һич тә ярамый! Барсын әле ул Кырымына. Барсын. Әле Зәлинәнең көмәне вакытны куаламый.

Әйе, һава аланына икәүләп яхшы машинада килделәр. Рейсны көткән арада тын куырып озак үбештеләр. Очыш игълан ителгәч, Зәлинә очу кырын чикләп торган тимер рәшәткә янына килеп басты.

Әнә Сашаны күккә алып менеп китәсе очкыч пассажирларын көтә. Өч атна вакыт бик тиз үтә бит ул. Кояшта янып, яшәреп, савыгып Сашасы ялт итеп кайтып та җитәр. Аннан икәүләшеп бала көтү мәшәкатьләренә чумарлар. Хәер, ирләр өчен түгел инде ул андый ыгы-зыгылар... Кайнанасы да бар бит әле. Ул да белә булыр. Саша әйтми түзмәгәндер лә. Әни малае булып картаеп килә иде бит инде. Хәзер генә ул Зәлинәнеке.

Бүгенгечә бик матур яңгыр явып узган иде ул көнне дә. Елена Ниловна янәдән тәрәзә янына килде. Тәрәзә пыялалары аръягында калган тормышына үрелеп карарга теләгәндәй омтылып куйды. Әйе, ул көнне дә яңгырдан соң, күп вәгъдәләр белән өметләндереп, салават күпере зур дуга ясап сузылган иде. Зәлинә, аның гүзәллегенә сокланып, бер мизгелдә ирен алып китәчәк очкыч хакында да онытып торды. Физика кануннары кызык икән ул. Матурдан-матур җиде төс бер-берсе белән кушылганда ак төс хасил итә икән. Ә менә шул ук төстәге буяуларны бутасаң, кара төс килеп чыга. Нилектән бу шулай? Сәер, бик сәер бу! Аңлашылмый да. Зәлинәнең акылы моны кабул итә алмый.

«Менә болай була ул!» – дигәндәй, кинәт күк урталай ярылып китте. Балкып торган Салават күпере урынында кара упкын хасил булды.

Гарасат бармы әллә?

Үкерү, елау, сиреналар авазы!

Очкыч кая югалды соң?


Юл алдымы, югалдымы?

Зәлинә ни булганын бер тын аңламый торды. Аэропорт репродукторы хәвеф барын хәбәр итәргә керешкәндә дә ул әле чын хәлне кабул итәрлек түгел иде. Аның күз алдында зәңгәр күккә юл алган очкыч шартлаган – җиде төсле Салават күпере мизгел эчендә юкка чыккан. Күк гөмбәзен биләп, фәкать каралык кына калган.

Зәлинәнең бар вөҗүдендә – КАРАЛЫК, БУШЛЫК, ӨМЕТСЕЗЛЕК, ЮГАЛТУ АЧЫСЫ!

Сөйрәлеп кенә Сашаның фатирына кайтты. Атна, әллә аймы узды. Яшь хатын алдында бер генә сорау калды: «Нигә яшәргә?» Карынындагы баласы да шул уйны куәтләде – төште дә куйды. Кайнанасы: «Фатирны бушат! Улымны Кырымга куалап, син генә харап иттең», – дигән җөмлә белән араны өзде. Бала исән калган булса, мөгаен, киленне урамга кумаслар иде. Юк шул – бәхетеңне сыер сөзгәч, дияр иде әнисе. Тик ул берни дә белми. Кызым зур шәһәрдә бәхетле яшәп ята дип белгән ананы нигә борчып газапларга?

Зәлинә, кабат Елена Ниловна булып, укучылары янына кайтып китте. Тулай торактагы урынын тапшырмаган иде әле. Алдан белгән диярсең. Йә, бу бала нигә төште инде? Миңа төшкән кайгыны күтәрә алмады нарасый. Бу буш тормышны ничекләр яшәп китәсе булыр. Бер хезмәттәше тыныч кына юатып куйды: «Мир не без добрых людей!»


Рәсем: Наталья Васильева



Яшәп киткәч, чыннан да «добрый кеше» табылды. Тиңе иде, ләкин безнең халык түгел инде. Әллә шуңа, бала дигәне бүтән хәбәр бирмәде. Болай да кызык түгел икән. Фатир ягы да тулай торак бүлмәсенә берегеп калды.

Җан биргәнгә юне табыла икән лә ул. Кукуруз басуында ярын тапкан кодачасының кызы Елена Ниловнаның чишелеше күренмәгән сагышына нокта куйды. Кукуруз басуының катышы юктыр да, бәлки, әмма студент кыз йөкле иде. Ерак апасының ярдәме белән авылга сафланып кайту нияте белән кунакка килгән кызның гөнаһлы фаразлары акланмады.

Ходай үз аягы белән китергән бәхет бит бу!

Тулай торак бүлмәсенә өмет нуры керде. Бәлки, ризалашыр. Бездән артмас иде.

– Сеңлем, үземдә генә тор. Балаңны миндә яшәп табарсың. Вадим абыең әйбәт кеше. Сабый җанын кыюга юл куясым юк. Бала – бәхет бит ул. Син аны әле үзең аңламыйсың. Кысыр калу ягын да башыңа кертмә. Үз вакыты белән туган бала бәхетеңә юл ачар. Илдә булмаган хәл түгел.

Үз хәленнән куркып калган студент кыз баштарак холык күрсәтеп алмакчы иде. Бер чыкмаса, бер чыга бит инде ул сер дип фикер йөрткәндер инде.

– Юк, юк. Мин бала күтәреп авылга кайтып керә алмыйм. Сезнең бер бүлмәгездә тыгынлап яшәргә дә уйламыйм. Тап, дип кыстасагыз, табармын. Тик мин аны калдырып чыгам.

УЗИдан карадылар. Кыз бала икән. Шул көннән башлап Елена Ниловна бәләкәй кыз турында хыяллана башлады. Чәчләрен үреп куяр микән? Үзенеке төсле кара толымнар булыр микән? Һай тиле, каян килсен ул балага минеке төсле куе чәч! Аның анасы мин түгел лә! Юк, мин. Мин аның анасы! Ходай йөкле сеңлемне минем ишеккә китергән икән, ул миңа: «Син бу балага ана бул!» – дигән. Булам да мин аны!

Шул көннән ул ирен туачак сабый турында уйларга, аны кайгыртырга өйрәтә, ата булу фикеренә күндерә башлады. Әгәренки бу бала аларныкы булып калмаса, Елена Ниловна үзе генә түгел, Вадимы да нәүмизләнәчәк иде.

– Леночка, я нашей дочери придумал имя. Очень красивое. Знаешь какое?!

– Но ты скажи.

– Как у тебя. Но только одна-две буквы будут отличаться – Алина. У татар девочки с такими именами всегда успешны. Они все красавицы. И наша дочь будет и успешной, и красавицей!

– Вадим, тогда УЗИ показало, что будет мальчик. – Сеңлесен кыз белән кызыктыру өчен генә хәйләләгәнен иренә тәфсилләп сөйләп торасы итмәде. Йөкле хатыннарның күпчелеге төшендә кыз бала күреп саташа лабаса.

Елена Ниловна ни әйтсә, шуңа ризалаша торган Вадим бу юлы да бәхәсләшеп тормады.

– Мальчик еще лучше. Мальчику имя выбирай ты. Нас ведь всегда вы – женщины выбираете.

– Если его назову Салаватом, ты не против? Это ради моей мамы... А значение имени очень хорошее.


– Салават дык Салават. В Москве Саввой будет. Ты же все равно его татарскому не научишь.

Менә шул Салават әнә рәсем ясап утыра. Сәләтле малай. Елена Ниловна аны Савва итмәде. Яхшы холыклы Вадим да Салаватка ияләште.

Тукта әле, нишләп соң мин бу баланы туган авылыма ияләштермим. Аны итәк астында күпме яшереп ятарга була. Зәлинә бала тапмый икән дигән хәбәрнең авылда йөргәне булмады. Менә тапкан бит. Үстергән.

Печәннәр өлгергән вакытта өчәүләшеп кайттылар. Зәлинә үз авылында янәдән Зәлинә булу рәхәтен кичерә, егетләре Ык буеннан кайтып керми, урманга бөрлегәнгә йөри, көтү каршылый. Әнкәсе дә урыс киявен мактап туя алмый. Эш рәте белә икән бит кияү балакай. Бөтен техниканы ялт иттереп төзәтеп куйды. Кулыннан эш коралы төшми. Авыл агайлары кебек, һәр каккан кадакка әҗер көтеп аптыратмый. Татар авылында туып-үскән кеше сыман олыны – олы, кечене кече итеп сөйләшә белә. «Берәүгә берәү яраган, баганага терәү яраган» дип, үзалдына сөйләнеп йөри бәхетле әбекәй. Зәлинәнең әнисе дә кызының әни кеше булу тарихын белми. Әллә белеп тә белмәгәнгә сабышамы? Гомергә дә сер бирә торган хатын булмады ул. Сиздерсә, каенсеңлесенең дә серен саткан булып чыга лабаса. Сернең йозакта торганы яхшы.

Салават малай да Сөлекле күлдән юл алып, Ыкка төшә торган чып-чын салават күперен күреп хозурланды. Рәссам булып китә калса, әлеге Салават күпере аның иҗатына илһам нурын сирпеми калмас. Фәкать җиде нурдан кушылган аклык кына көчен җуймасын. Якты нур кирәк кешелеккә.



КИТАП УКУ – ҮЗЕҢНЕ ТАБУ УЛ

Гөлнара САБИРОВА,
«Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире

УКЫРГА МӘХӘББӘТ УЯТКАН КИТАП...

– Төгәл генә әйтә алмыйм, чөнки балачактан күп укыдым һәм ул китапларның кайсысы мәхәббәт уятканын хәтерләмим. Үзебезнең, күршеләрнең, мәктәп, авыл китапханәсен тулысынча укып чыктым дияргә була. Димәк, бөтен татар классиклары укылган. Мәктәп елларында күңелгә нык кереп калаган әсәр – Островскийның «Как закалялась сталь»е. Шулай ук Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләре. Барысы да! Безнең гаилә күп укый иде. Басма матбугатны күп яздырттылар. Республиканыкы гына түгел, федераль газеталарны да алдыра иде әти-әни.

МИНЕ /ДӨНЬЯГА КАРАШЫМНЫ/ ҮЗГӘРТКӘН КИТАП...

– Айн Рэндның «Источник» һәм «Атлант расправил плечи» китаплары. Мин бу фәлсәфи-интеллектуаль әсәрләрне укырга киңәш итәр идем. Беренчедән, бик зур һәм көчле кешеләрнең мәхәббәт тарихлары, икенчедән, көчле рухлы кешеләрнең системага буйсынып һәм буйсынмыйча яшәүләре. Үз сүзе, үз фикере булган талантлы шәхесләрнең һәрвакыт ниндидер басымга буйсынырга йә агымга каршы барырга мәҗбүр булулары турында. Анда икътисад та, түрәләрнең сәяси уеннары да, мәхәббәт тә бар. Күптән түгел әлеге авторның «Мы живые» китабын укып чыктым. Ул Петроградта революция елларындагы тормыш хакында. Шулай ук ошады. Әмма беренче укыган ике китабы берни белән дә чагыштыра ала торган түгел.

ҮСМЕР ВАКЫТЫМДАГЫ КИТАП-ДУСТЫМ...

– Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев һәм Мөхәммәт Мәһдиев китаплары. Бу өч авторны кайта-кайта укый идем.

ӨСТӘЛ КИТАБЫМ...

– Экзюпериның «Кечкенә принц» китабы. Мин аны кабат-кабат укыйм, цитаталарын язып алам, чөнки ул канатлы сүзләргә бай, сүтеп-сүтеп укый торган китап. Анда бик зур фәлсәфә, әмма ул шундый җиңел, рәхәт итеп язылган. Елына берничә кат укыйм, һәм укыган саен яңа яктан ачыла ул.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

– Гадәттә, берничә китапны берьюлы укыйм. Олдос Хакслинең «Остров» дигән әсәре. Бу антиутопия жанрында язылган. Заманча тормышның тасвирламасы, кыйммәтләре турында. Океан уртасындагы утрауда бик ирекле кешеләрнең үзләре өчен камил булган тормыш төзүләре һәм бер кешенең килеп кереп әлеге көнкүрешне җимерә башлавы хакында ул. Бик кызыклы булып чыкты. Шулай ук Ольга Ивановаһың Казан ханбикәләре – Сөембикә, Нурсолтан, Гәүһәршат турындагы трилогиясен, Ремаркның бүгенге көнгә бик нык туры килә торган «Возлюби ближнего своего» романын укыйм.

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДАГЫ ӨЧ ЯРАТКАН ӘСӘРЕМ ҺӘМ АВТОРЫМ...

– Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыят»е һәм барлык хикәяләре. Аны бөтен кешегә, бигрәк тә сүз белән эшләгән кешеләргә, укып чыгарга киңәш итәр идем. Миңа калса, ул – татар әдәбиятының иң матур үрнәге. Аяз Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?» әсәре. Фоат Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» трилогиясе. Соңгы ун елда мине иң тетрәндергән китап.

БАСМА ҺӘМ ЭЛЕКТРОН КИТАПНЫҢ УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ...

– Басма китапның күтәреп йөрергә авыр булуын исәпләмәгәндә бернинди дә тискәре ягын әйтә алмыйм. Бөтен китапны сатып алам. Кемнәндер алып укырга яратмыйм. Китап кибетендә сәгатьләр буе йөрим. Электрон китап та бүләк иткәннәр иде. Телефон өчен дә кушымталар бар. Әмма алар белән файдаланмыйм, чөнки яратмыйм. Миңа китап киштәсендә китапның булуы, аны кулыма алып уку, битләренең кыштырдавы кирәк. Бизәлеше дә әһәмиятле. Китап минем өчен ул – басма китап.

УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ...

– Безнең буын иҗатчылары арасыннан Ландыш Әбударова хикәя-повестьларын укырга киңәш итәм. Безнең чор, безнең турында булуы белән шундый якын алар. Җиңел һәм матур яза ул. Рөстәм Галиуллин хикәяләрен бик яратып укыйм. Гөлүсә Баттал шигърияте күңелемә якын. Минем өчен бу елның ачышы – Фирдүс Гыймалтдинов. Аның ике романы «Буа» һәм «Үзбәк хан». Алар тарихи, бик зур чорны үз эченә алган. «Үзбәк хан», гомумән, гомер-гомергә хатын-кызларның илләр һәм дәүләтләр идарәсенә йогынтысы булуы турында. «Казан утлары»нда басылган бөтен әсәрләрне укырга киңәш итәм. Ул чагыштыру өчен дә, әдәбиятның хәлен бәяләү өчен дә кирәк. Һәм, әлбәттә инде, классиклар. Татар әдәбиятында: Фатих Әмирхан, Ибраһим Сәлахов, Нәби Дәүли, Мәхмүт Галәү, Нурихан Фәттах. Дөньяви классиклардан Ремарк, Айн Рэнд. Иң яраткан авторым Бунинны да әйтми кала алмыйм.





Галәмнең үзе кебек ул: кызык, мавыктыргыч, серле... Тирән! Һәр очрашуда, һәр сөйләшүдә яңа яклары белән ачыла – шуңа да аның белән күрешүләр һәрвакыт үзе бер вакыйгага әйләнә. Бәйрәмгә! Аның таланты сокландыра, горурландыра, шаккаттыра! Музыка дөньясында татар халкының тарихын, татарның катлаулы һәм фаҗигале язмышын аның кадәр чагылдырган моң иясе юктыр әле бездә... Сүзем – композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА хакында. Ул бүгенге көндә Америка Кушма Штатларының Сиэтл шәһәрендә яши һәм иҗат итә. Татарны дөньяга таныту белән шөгыльләнә!



ТАМЫРЛАР Башкортстанның иң төньяк районында – Аскында тудым. Бер төбәктән булсалар да, әтәй авылы кешеләре белән инәйнекеләр бөтенләй бер-берсенә охшамаган. Әтәйнең туган авылы Яңа Казанчыда үзенекен бирми, хокукларын яклый белә торган халык яши. Бик кызу канлылар! Революциягә кадәр руслар агачларын кисәргә килгәч, карт әтәйләр аларга каршы күсәк белән сугышкан. Ә инәйнең авылында – Кышлау-Елгада халык бик йомшак, нигә бу күрше миңа шулай карады, әллә аны берәр ничек рәнҗеттемме икән дип гомер итәләр. Иске Казанчыда урын җитми башлагач, бабайлар Кышлау-Елгага килеп утырганнар. Сазлыклы җиргә. Дөрес, хәзер ул сазлыклар юк инде. Бездән ерак түгел «Танып» дигән санаторий ачтылар – бөтен Россиядән дәваланырга киләләр хәзер.

Инәем 10 класс тәмамлаган. Ул еллар өчен Гарвард университетына тиң бу! Белем алу өчен 60 чакрым җәяү йөргән. Авыл буйлап гел акыл җыя иде: «Менә ул бик акыллы кеше, аны тыңларга кирәк», – дип кайберәүләргә



Гөлнур САФИУЛЛИНА

«ДӨНЬЯ БУЙЛАП ИНӘЙ ТАВЫШЫН ЭЗЛӘП ЙӨРИМ...»

махсус бара иде. Әтәем фельдшерлыкка укыган – чоры өчен шулай ук зур белем. Инәй аңардан олырак, яшь аермалары 4–5 ел. Инәй шадра, ул үзен мин матур түгел дип уйлаган. Әмма «асылынсаң да асыл агачка асылын» дигән сүзе бар иде аның. Әтәй бик көчле табиб булган, кулы фәрештәнеке кебек дип йөрткәннәр. Яшь умарта кортлары балы белән ул хәтта яман шештән дә дәвалаган. Бөтен тирә-юньдәге рус, чуаш, удмурт, мари авыллары аңа йөргән, хәтта Уфадан кадәр килгәннәр. Кешеләр чаналарда кунып-кунып чират көтәләр иде, дип сөйли иде инәем. «Шәмселислам әнә бөтен нәрсәдән дәвалый, табибларның барысын да бер китаптан укытмыйлармыни?!» – дип, районга жалоба белән баручылар булган... Берсендә авылда бер баланың, агач ботагы кереп, күзе чыккан. Әбисе күзне учына салып, аны әтәем янына алып киткән. Әтәем күзне утырткан. Ул егет гомер буе бухгалтер булып эшләгән. Уфада диспансеризация узганда күз врачы: «Күзегезгә җәрәхәт булмаган идеме?» – дип сораган. Сөйләп биргәч: «Ул табибыгыз даһи булган!» – дигән... Бер апа минем үземә: «Эчем авыртып әтиеңә барган идем. Укол кадады да, ампуласын миңа бирде. Утыз ел янымда йөрттем! Берәр җирем авырта башлауга, кулга тотам – булыша. Булышмыйча, аны бит миңа әтәң бирде!» – дигән иде... Халык аңа бик ышанган. Инәем: «Кайчак дару булмагач, «бу бик көчле дару», дип, акбур биреп җибәрә. Тереләләр иде!» – дип сөйли иде. Теле, күз карашлары белән дә дәвалаган ул. «Синең янда рәхәт», – диләр миңа менә кайчакта. Әтәемнән күчкәндер – мин кешеләрдә бер гаеп тапмыйм, алардан матурлык кына эзлим. Андыйларны башкалар, гадәттә, якын итә...

Иртәгә үләсе дигән көнне дә авыруларга укол кадаган әле ул. «Бигрәк матур бит бу дөнья! Нигә кайберәүләр үз гомерен үзе чикли икән? Ничек инде шулай эшләргә мөмкин?!» – дип тә шул көнне әйткән ул. Әтәйгә нибары 38 яшь булган. Йөрәк чире белән туган ул, шуның белән китеп тә барган. Хәзер булса операция ясарлар, гомере алай кыска булмас иде дә бит...

Инәем бик матур җырлый иде. Мин хәзергәчә дөньядан инәемне, аның тавышын эзләп йөрим... Кем җырласа да – филиппинмы, кытаймы, мексиканмы – шунда бер чаткыны тотып алам. Инәемдә, аның көендә дә шул бар иде, дим. Аның тавышы шундый матур иде! Ярый әле магнитофонга яздырып калмаганмын – тыңлаганда сагынуга түзмәс идем хәзер. Хатирә булып күңелнең иң түренә кереп урнашкан. Кунакларга баргач бөтен кеше: «Рафыйга, җырла әле!» – дип сорый торган булганнар. Инәй җырлаган, ә кайткач, әтәем: «Нигә җырладың?» – дия торган булган. Көнләшкән! Кешене үземә җәлеп итү, аның игътибарын тотып тору сәләте миңа әнидән күчкән... Тукайны яттан белә иде. Өтере, сызыкларына кадәр! Бөтен сөйләшүне Тукайга китереп чыгара иде. «Уятмакчы булсаң халык күңелләрен, / тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын...» дип сөйләүләре бүгенгедәй күз алдымда. Аңардан: «Иң нечкә кыллар нәрсә ул?» – дип сорап була иде... Вак-төяк белән шөгыльләнгәнне яратмады, аңа барысы да зурдан кирәк иде. Умарта кортлары тотты. Безгә нефтьчеләр бал алырга вертолетлар белән төшәләр иде. Иң яхшы бал инәйдә булды! Әтәй: «Минсез каласың, сине бал кортлары тартып алып барыр», – дип, бу һөнәргә өйрәткән. «Кешеләр бай, шикәр ашыйлар, без бал», – дия идем кечкенә чакта. Шикәр алырга акчабыз юк иде.



БАЛАЧАК Әтине күмгән көнне бик аз хәтерлим. Халык бик күп җыелганын, миңа конфетлар биргәннәрен, «Кара, кеше үлсә әйбәт икән, конфет бирәләр», – дип куанганымны гына беләм. Андый тәм-томнар безгә сирәк эләгә иде бит...

Без дүрт бала ятим калдык. Инәйнең ике энесе – Мансур һәм Гарифулла абыйлар безне караштты. Ул елны безнең сыер да үлде, эт тә. Бик авыр булды... Ягарга утын юк, салкын. Ә мин бүрәнә арасындагы саламны йолкып чыгарам да, шул тишектән җилне тыңлыйм. Инәй аптырый: «Нигә суык соң бу кадәр?» – ди. Ә мин бөтен җирдән тавыш җыеп йөрим...

Инәйнең Казакъстандагы сеңлесе кайтты да: «Әйдә, бер кызыңны алып китәм, сиңа да җиңелрәк булыр, миңа да ярдәме тияр, идән юарга, табын җыярга ярар», – дип, мине Карагандага алып китте. Авылдан 10 яшьтә чыгып киттем. Инәй русча ике сүз өйрәтте: улица һәм курица. Тик кайсы тавыкны, ә кайсы урамны аңлатканын үзе дә белми иде... Нәфыйга апаның өч улы бар иде. Аларның ике бүлмәле фатирларында бер ел яшәгәч, мине интернат-мәктәпкә бирергә уйладылар. Спорт мәктәбенә барабыз дип чыгып киткән идек, тукталышта ялгыш төштек тә, музыка мәктәбенә эләктек. Апа: «Сиңа бит кайда да барыбер», – диде... Ә анда имтихан бара. Җырлап күрсәтергә сорадылар. Русча бер җыр белә идем – Советлар Союзы гимнын җырладым. Апа әйтә: «Алмый гына карасыннар, син бит гимн башкардың!» – ди. Алдылар! Бер елны Карагандага Сара Садыйкова килде. Ул чакта татарлар яшәгән җирләрдә шулай йөри иде алар. Тәлгать Әхмәтов белән килгәннәре истә. Берсе уйный, берсе җырлый... Мөкиббән булган идем инде. Татар телен ишетәм бит. Авыл телен! «Син Казанга кил», дигән сүзне миңа Сара апа әйтте.

Сагыну булгандыр инде ул... Тик теш табибым әйтмешли, кеше ул шундый хайван, бар нәрсәгә дә ияләшә. Укуга чумдым: рус, казакъ телләрен, музыка өйрәнәм... Авылга 15 яшьләрдә генә кайта башладым. Поездда ике тәүлек кайткач, 20 чакрым җәяү атларга кирәк иде. Урман аша! Инәй шунсыннан курка иде. Кайтып йөрмә диюен тыңламагач: «Һичьюгы, аягыңа сырлы оекбаш ки, бүреләр ашаса, шуннан танырбыз», – дигәне булды... Бер елны кайтам, арттан шәүләләр килә. Күктә туп-тулы ай. Ерак түгел – эскертләр. Берзаман теге шәүләләр: «У-у-ууу», – дип улый башлады. Бүреләр түгелме соң, дим. Җанны учка куюның нәрсә икәнен шунда аңладым. Җиргә утырдым да, елый башладым, тик ул бүреләрчә улау иде... Минем бөтен музыкамда да бүре улавы бар.

Бик авыр чакларда инәемә: «Нигә җибәрдең, сыер савар идем әле», – дигәнем булды. Тик авылда тормыш авыр иде шул. Паспорт та бирмиләр иде бит. Апа читкә алып китмәсә, миңа да бирмәсләр иде. Барысын да холкым аркасында гына җиңеп чыкканмындыр. Миндә әтәем холкы. Мин дә дөньядагы чытырманнар белән сугышам. Элек җәй көне

көянтәләп җиләк җыя идек – безнең якларда кура җиләге күп. Мин гел: «Иң күп җиләк чытырманлык эчендә», – дип уйлый идем. Кереп китәм, тырналып, сыдырылып бетәм. Тулы чиләк белән килеп чыгам, карыйм: бер урында тик кенә чүпләп утырганнарныкы да тулган. Менә шуңа барыбер өйрәнеп булмады – гомер буе алга чаптым.



УКУ Миңа мәктәптә математика ошый иде. Тагын физика, геометрия! Алардан бик көчле идем – бөтен дөньям математикадан гына тора иде. Укытучы мине математика буенча университетка керергә әзерләде. Тик музыка җиңде...

Музыка училищесын тәмамлагач, туган ягыма кайтам да, Аскында музыка мәктәбендә укытам дип хыялландым. Нәфыйга апа вокзалга озата төште. Кулымда – чемодан, кесәдә – 35 сум акча. Уфага поезд төнге сәгать уникедә генә китә иде. Аның кадәр көтмим, дип, Казан поездына билет алдым. Сара апаның «кил» дигән сүзе күңелне кымтырыклап тора бит!.. Консерваторияне барып таптым. Мирсәет Яруллинны да эзләп таптым – композиция укытучысы аңа хат җибәргән иде. Имтиханнар бара. Марс Макаров дигән егет бер чемодан опера алып килгән. Минем дә кечкенә генә дүрт музыкам бар. Икешәр минутлык кына... Нәҗип Җиһановка алар ошады. «Бишле» куйдылар! Музыка училищесы дипломында, рус теленнән кала, бөтен фәннәр «бишле» иде минем. Русча акцентсыз сөйләшергә өйрәнә алмадым... Авылга кайттым да, инәйгә: «Укырга кердем», – дим. «И-и, җитмәдемени әле укып», – диде.

Соңгы курста мине әллә Әлмәткә, әллә Чаллыга эшкә җибәрергә тиешләр иде. Җиһановның Казанда калдырасы килде. Курчак театрына үзе шалтыратты – мине музыкаль җитәкче итеп алдылар.



УҢЫШ Зур уңышны миңа «Мәһди яки изге Болгар дастаны» әсәре алып килде. Стадионга ул чакта 20 мең тамашачы җыелды! Татар музыка сәнгатендә беренче куелыш иде бу. Халык күтәрелгән чак, минем күтәрелеш, мөмкинчелек бирүләр – барысы бергә туры килде... Симфонияләр бик көчле минем. «Татар даласы» да, «Чыңгызхан» да, «Ибне Фадлан» да, «Дәрвиш» тә... Аларның барысын да атаклы дирижер Фуат Мансуров башкарды. Музыкамны яратты. Ул да Казакъстаннан иде бит.

Мин «Сөембикә бәете»н көйләгәннән соң, башкалар да Сөембикә темасы буенча эшли башлады. Ул чакта татар халкына, татар сәнгатенә бик мөһим юнәлеш күрсәттем – шуңа әле дә канәгатьмен. Ә хәзер тарих катламында тагын да аскарак төштем – тамгалар буенча эшлим. Татар халкы ул Сабантуй, түбәтәй һәм өчпочмак кына түгел әле...

Казанда фатир күршебез Шиһабетдин Мәрҗани оныгының кызы Нажия апа Ильясова иде. Фәлсәфи яктан юнәлешне миңа ул бирде. Мәчеткә йөри башладым, Рәшидә абыстай Исхакыйда укыдым. Дини темаларга шулай кереп киттем. Сүз уңаеннан, Колшәриф мәчетендә Рамазан ае буе тәүлек әйләнәсе хәзер дә минем музыка яңгырый.

Диссертацияне илнең иң көчле уку йортында – Санкт-Петербург университетында якладым: фәлсәфә фәннәре кандидаты мин. Кайттым... Үземнең дә, иремнең дә эше юк. Акча юк... Грин карта оту мөмкинлеге туды ул чакта. Һәм мин җиңдем. Ирем Таһирның чит илдә бик эшлисе килде. Әйдә, эшләп карасын, дим. Җиңүчесе мин булгач, үзләре генә чыгып китә алмыйлар: аларны алып барам да, кире кайтып китәм дип уйлыйм. 50 яшь иде миңа бу вакытта. Салих: «Сан-Франциского барабыз, чөнки компьютер белгечләре шунда», – ди. Таһир: «Нью-Йоркта урнашабыз, анда русча сөйләшәләр», – ди... Ә миңа барыбер – кайтасы юл гына якынрак булсын. Алар бер-ике ел эшләр, мин музыка язармын, монда да акча юк, анда да, дим. Җыйган фольклорым бик күп иде – аларны эшкәртәсе бар. Рәхәткә чумдым! Аннан инглиз теле өйрәнү теләге туды. Телләр өйрәнергә ятатам! Татар теленең матурлыгына мөкиббәнмен. Кеше судоку чишә, ә мин бер сүзне табам да, аны русчага тәрҗемә итәм. Минем өчен кроссворд – тел. Бу мавыгу сүзләрнең асылын тоемлауны, сизгерлекне арттыра.

Таһир Америкага баргач кулын сындырды, госпитальдә ятты. Мин дә янына барып йөрим. Җай чыккан саен кем белән булса да сөйләшергә тырышам – тел өйрәнергә телим. Госпитальдә бер хатын: «Йоклый алмыйм», – дип зарланды. Шунда госпитальгә тәкъдим белән чыктым: «Әйдәгез, шундый проект эшлик: мин бишек җырларын җыям, ә сез йоклый алмаган, сызланган авыруларга аларның үз телләрендәге бишек җырларын тыңлатырсыз», – дидем... Ул зур бер хәрәкәткә әйләнде: телевидение төшерде, бу хакта газеталар язды. Безнең Сабантуй кебек фестивальләре бар аларның: миңа шунда махсус зур бина бирделәр, халыклар чират торып бишек көйләрен яздырды. Милләт мөһере, тамгасы дим мин бишек җырын. Бер швед бабае җырлады да, аннары елады. «Инде үлсәм дә ярый. Бу минем ерак әбиемнең бишек көе иде. Аны инде беркайда да җырламыйлар. Ә хәзер беләм – бу көй яшәячәк», – диде...

Сиэтл шәһәрендә нинди генә халык яшәми. Бишек җыры – һәрберсенең күңеленә ишек ача. Бер кытай егетеннән аларның бишек җырын отып алдым. Аны һәммә кытай белә. Көйли башласам – елмаялар, бер урынына миңа ике өлеш ризык салып бирәләр...

Тиз генә әйләнеп кайтырбыз дип киткән идем, Америкада яши башлаганга 20 ел була менә. Үзем белән горурланам: инглиз телен өйрәндем, ризыгым музыка гына түгел хәзер. Татар халкы инде минем ризыгым! Кая гына барсам да, татар иселе белән тамак туйдыра алам. Чиккән сөлгебезне тартып чыгарып, аның турында 10 сәгать сөйли алам. Телне өйрәнү шуңа кирәк тә иде миңа, чөнки татар турында хәзер инглиз телендә сөйли алам.

Сиэтлда татарлар бик күп, әмма аларның күбесе Үзбәкстаннан, Кыргызстаннан күчеп килгән. Мин аларга бик кадерле, чөнки әби-бабалары телен беләм. Дәү әниләре нинди көйләр көйләгән, аларның шуны тыңлыйсылары килә.



МӘХӘББӘТ Ромео-Джульетталардагы кебек әрнүләр булмады миндә, бөтен барлыгым музыка язуга бирелде. Телевидениедә музыкаль тавыш режиссеры булып эшләгән чагым. Ә Таһир инженер булып эшли. Ул инде 30 га җиткән буйдак егет. Минем дә кияүгә чыгар чагым җиткән, тик егет эзләргә

вакытым юк... Берсендә туфлиемнең үкчәсе сынды – аны көйләде; икенче юлы сәгатем йөрми башлады – төзәтте; өченчесендә ачыккан идем – ашатты... Миңа тагын ни кирәк, кияүгә чыгып бала табам да, тагын алга таба музыка язам дип уйладым. Менә шулай гап-гади. Дөрес, Айлы кичләр, Айга караулар бездә дә булды анысы. Әмма мин Галәм белән күбрәк үзем генә калырга яратам: җиргә ятып болытларны, йолдызларны күзәтергә, океанны тыңларга... Мәхәббәт чынында бик хисле кешеләргә, эше, мавыгуы булмаганнарга биреләдер ул. Ә минем һәр күзәнәгемдә – музыка. Һәм музыка бик көнчел: аз гына икенче тарафка киттеңме – ул көнле. Бераз язмый торсаң – син инде аны яза алмыйсың. Музыкага булган мәхәббәткә гел очкын салып торырга кирәк... Әмма мәхәббәт хисенә бик рәхмәтлемен: ул безгә нинди шигъриятне биргән! Музыка яза башласам, шул дөньяга чумам.



ДУСЛАР Иң якын дусларым – ике улым, ирем. Тагын ике кыз туганым: апам белән сеңлем. Күңелемдәген кем беләндер бүлешү, серләшү дигән гадәт юк. Кечкенә чакта интернатта бергә торган дустым бар, ул хәзер Германиядә яши. Тик ул миңа түгел, мин аңа күбрәк сердәшче... Бар нәрсәне дә урамга чыгарып селки алмыйм. Улларымда, иремдә нәрсәдер ошамаса, мин аны гомеремдә дә башкаларга ачып салмаячакмын. Бу – гаилә эше. Дуслар авыр чакта кирәк, диләр. Мин кешегә нинди чакта ярдәм сорап шалтыратыйм? Акча сорапмы? Үлгәндә дә сорамаячакмын! Ул адымга барганчы, идән юам, подъезд җыештырам... Кемнәндер баланы укытырга кертергә сораргамы? Беркайчан да!



БАЛАЛАР Улларым өметләремне акладымы? Ә мин аларга карата ниндидер өметләр кормадым да. Кеше рәнҗетмәсеннәр, хыянәткә кермәсеннәр, тәүфыйклы булсыннар дип теләдем, әлбәттә. Салих белән Надирга гел: «Мин сезгә гомер бирдем, барлык санылгыз да исән-сау, калганына үзегез ирешергә тиешсез», – дия идем. Әтиләре ягы – Кайбычлар бик яхшы нәсел, минем як – шулай ук. Икесе дә Казанда татар гимназиясендә укыды, Америкада югары белем алдылар. Берсе – ракеталар, икенчесе роботлар буенча белгеч. Хыялыйлар! Надир яңа гына өйләнде, киленебез Гөлчәчәк Кама Тамагы районы Иске Казиле авылыннан. Кода-кодагыйларның хуҗалыгы зур: биш сыер, биш бозау, атлар асрыйлар. Надир хәзер тирес түгә, су сиптерә торган роботлар эшләргә хыяллана. Авылдан шәһәргә яңа сауган сөт китерә, шәһәрдән авылга кирәк-яракны ташучы оча торган автобуслар! Салих бакчасына биш хөрмә агачы утыртып куйды менә. Үзе Нью-Йоркта әле: кнопкага басып кына хөрмәләренә су сиптерә. Җир шарының кайсы ноктасында булса да, баса ала ул кнопкасына. Бер баруымда өйдә юк чагы туры килде шулай. Шалтыратам, ә ул миңа: «Әни, кер, робот ишекне ачар», – ди. Чынлап та, робот ачты һәм: «Чәй эчәбезме?» – диде. Нәкъ минем тавыш белән! Салихның бөтен уе: кайда тәмле ашарга? Гөбәдия белән чәй эчәргә дип Нью-Йоркка, шаурма ашарга дип Төркиягә оча ала ул.



АКЧА Җан биргәнгә, җүн биргән, ди безнең татар. Дөрес әйтә! Миңа сарайлар кирәкми, аны төзеп, аннары кыска гына гомердә матди дөньяга мөкиббән китеп, таларлар, яндырырлар дип, шул өйдә куркып утырыргамы?! Миндә күчмә халыклар рухы. Бер урында өч ай утырсам, күңелем алгысына башлый – каядыр чыгып китәргә кирәк. Швеция, Норвегия, Дания, Англия, Ирландия, Португалия, Испания, Польша, Төркия, Мисыр... Мин булган, күргән кайбер илләр болар... Шимбә саен тауларга барам. Инәй: «Бу дөньяга без табак-савыт юарга килмәгән!» – дия иде дә, безне урманга алып чыгып китә иде.



МАВЫГУ Инәемнең бишмәте 35 ямаулы иде... Мин дә ямау салырга яратам. Әмма... ямый алмыйм, чөнки минем өчен бик зур сәнгать кебек тоела ул. Матур да булып торырга тиеш бит син салган ямау. Моңа өйрәнә дә алыр идем, әмма музыка бөтен көчемне үзенә алып бетергән.



КУРКУ Зур куркулар юк күңелемдә... «Ни йөрәк белән чыгып киттең?» – диләр миңа еш кына. Күпләр, читкә китсәм, кайда яшәрмен, нәрсә ашармын дип курка. Әле менә Казанга кайтканда башта Нью-Йоркка килеп төштем, аннан Истанбулга очарга кирәк: терминалга поездда барасың. Элек тел белмәгәч адашудан курка идем. Тел өйрәнеп ул куркуны бастым... Кеше үлемнән курка, мин – юк. Аны көтәм, ул миңа хәтта кызык... Картаю да куркытмый, бу процессны яратам: көзгегә карыйсың, ә анда асфальт юл кебек тигез биттә хәзер ниндидер акыллы җыерчыклар. Чирдән дә курыкмыйм – ул хакта мин уйламыйм. Иң куркынычы – баланың синнән алда вафат булуыдыр. Кечкенә чакта аларга: «Кош кебек һәрвакыт канатларымны җилпеп сезнең өстә саклап торам», – дия идем. Ышаналар иде... Салихка менә 40 яшь тула. «Син әле дә безне саклап очасыңмы?» – ди ул кайчакта. «Очам, тик канатларның каурыйлары гына коелып бетеп бара», – дип көләм.



ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ Гомер буе «туры Тукай» дип йөрттеләр мине. Әмма хәзер акыллана башладым. Элек: «Күзеңне нигә мондый төскә буяп куйдың, килешми бит!» – дия идем, хәзер дәшмим. Болай әйтергә ни хакым бар?! Кайвакыт авызны ябып тору дөресрәк. Аннан яшь тә бара – энергияне сакларга кирәк. Җир йөзендә 8 миллиард кеше яши, алар барысы да төрле-төрле уйлый: син аларны үзгәртә алмыйсың, алар – сине. Тигәнәкләр дә бар табигатьтә, роза чәчәкләре дә. Дөнья шуның белән матур!.. Американ бер дустым: «Син бөтен кешене аклыйсың», – ди. Кемдер ниндидер адым ясаган икән, димәк, аның шулай эшләргә сәбәбе булган дип уйлыйм шул мин.

PRESSA



Мин бик сирәк кешеләргә генә эләгә торган бәхетне татыдым: 62 яшемә кадәр әти-әнием янәшәсендә яшәдем. Аларга кирәк тә, терәк тә булдым кебек. Балалык бурычым да үтәлгәндер сыман. Тик әнине сагындырган йокысыз төннәр уйландыра.

Әнием Шәйхетдинова Рәшидә Сәлахетдин кызы 1930 елның 28 ноябрендә Исәнбай авылында туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң Минзәләдә укытучылыкка укый. Яшь белгечне башта районыбызның Үтәгән авылына, аннары Алга авылы мәктәбенә башлангыч сыйныф укытучысы итеп билгелиләр.

Сугыштан соңгы авыр еллар. Тик яшьлеккә авырлыклар гына киртә була аламы? Әнием дә үз мәхәббәтен таба – Исәнбай МТСында шофер булып эшләүче Шәйхетдинов Нургаян белән гаилә кора. 1958 елдан әни әтинең туган авылы Девятернә җидееллык (1962–1963 елдан – сигезьеллык) мәктәбендә укыта. Бу вакытта инде без – апам Ләлә белән мин туганбыз.

Мәктәптә өлкән сыйныфларга татар теле һәм әдәбияты укытучысы кирәк булгач, җитәкчеләрнең игътибары безнең әнигә төшә. Мин, инде гомерем буе мәктәп тормышы белән яшәгән кеше буларак, әнинең ул чактагы халәтен аңлыйм. Яңа фәннән белем бирүе баштарак җиңел булмагандыр. Ләкин ул кыенлыкларны җиңеп, тиздән мәктәпнең иң абруйлы укытучысына әверелә. Татар теле һәм әдәбияты дәресе кабинетын тиешенчә җиһазлый, балалар белән дәрестән тыш та күп эшли, кечке мәктәптә укыта, җәмәгать эшләре башкара.

Укытучылар эшенә иң дөрес бәяне, минемчә, аның укучылары, әти-әниләр бирә. Күп еллар Девятернә мәктәбендә укытып, районда абруйлы укытучы булып җитешкән, Татарстанның атказанган укытучысы Галия Муратова әни турында: «Мин Девятернә мәктәбеннән тыш беркайда да татар телен һәм әдәбиятын укымадым, мәктәбемдә Рәшидә апаның биргән белеме бөтен тормышым буена җитте, зур уңышларга ирешергә ярдәм итте», – ди.

Әйе, ул чор укучылары бүген инде үзләре дә лаеклы ялда. Тик әниемне, үзләренең укытучыларын, һаман да хөрмәт белән, яратып искә алулары йөрәккә сары май булып ята. 70 ел элек әнинең укучысы булган Гөлсинә апа Гатауллинаның бәйрәм саен чәкчәк, бал күтәреп килүләре, күңел җылысын салып бәйләгән оекбашлар бүләк итүләре әнине бик сөендерә, җанын эретә иде.

Аяклары нык авыртса да, Гөлсинә апа әнине соңгы юлга озатышырга да килде. Санкт-Петербургтан, Калининградтан кайткан укучылары Роза Шәймәрданова, Хәмдия Тимершәеховаларның һәм башка бик күпләрнең үз укытучыларын онытмавы, хәл белешеп торулары күпләрдә соклану уятадыр.

Әнием бик күп укый иде. Үземнең дә әдәбият белән кызыксынуымда әниемнең һәм укытучым Мәүгыйдә апа Айдарованың өлеше зурдыр. Озак еллар үткәч, әниемнең үзе өчен генә шигырьләр язуын белдем.

Күзләр җитеп, ачы җилләр иссә,
Яме китә авыл, калаларның.
Еллар үтеп, яшьләр арткан саен,
Кадерлерәк була балаларың.

Шигырьләрен укыйм да, әниемнең тавышын ишеткән кебек булам. Ул туган авылы Исәнбайны бик сагынды. Бай елга, Шомыртлы чокыры, Яман елга, Салкын чишмәләрне сөйләп, авылдашлар хакында сорашып яшәде. Аларның уңышлары белән горурланды, бакыйлыкка күчкәннәрен догадан калдырмады.

Әнинең тагын бер күркәм гадәте бар иде: кайда гына яшәсә дә, күршеләре белән тату булды. Чисталык, тәртип яратуы, бакчага, чәчәкләргә булган мәхәббәте миңа да күчте.

Әти белән алар 65 ел парлы гомер итеп, икесе дә 91 яшькә кадәр яшәп дөнья куйдылар.

...Уйларымда көн саен иртән үз бүлмәсеннән әнием килеп чыгар кебек. Урыны оҗмахта булсын!

Илдус ШӘЙХЕТДИНОВ.
Әгерҗе районы, Девятернә авылы.

Гомерем буе күңелемдә укытучыларыма карата хөрмәт хисләре йөртәм. Хәзерге көндә дә якын дусларым, фикердәшләрем – укытучылар. 80 гә җитсәм дә, алардан үрнәк алырга тырышам.

Башлангыч классларда Сарман мәктәбендә Кәшифә апа укытты безне. Әниемнән соң иң якын кешем булды ул минем өчен. Мәктәптә шаярышсак, дәресләр әзерләп килмәсәк, ул берне чәпәргә дә күп сорамый иде. Аңа үпкәләү, өйгә кайтып әләкләшү юк, шулай тиеш дип белдек. Беренче класста хәрефләр тану һәм кушу-алудан узмадык. Күбебез колхозчы балалары, ясле-детсадны күрмәгән. Җырларга-биергә дә безне Кәшифә апа өйрәтте.

Алтынчы класстан класс җитәкчебез үзебезнең Сарман кызы Асия апа Галимова булды. Ул вакытта әле кияүгә дә чыкмаган кыз бөтен барлыгын безгә багышлады. Дәресләр беткәч тә, тиз генә өйгә кайтып капкалап киләбез дә, берәр буш класста репетицияләр уздырабыз, чигәргә-бәйләргә өйрәнәбез. Барысын да Асия апа оештыра.

Эшләгән дәверемдә дә гел укытучылар белән аралашырга туры килде. Юллама белән Александровка почтасына эшкә килгәч, мине шул айда ук мәктәпнең татар теле укытучылары спектакльдә уйнарга чакырдылар. Ирле-хатынлы Мәхмүтовлар (Мәхмүтов абый үзе мәктәп директоры), Лира Садретдинова, Нәкыя апа Сәлимова, Фатыйма апа Гәрәева һәм тагын берничә укытучы белән күрше авылларга да спектакль куярга йөрдек әле. Югарыда санап кителгән бу укытучыларның күбесе бакыйлыкка күчте инде, урыннары оҗмахта булсын. Александровка мәктәбенә 8 нче класска Яхшы Каран, Рангазар, Рантамак, хәтта Азнакай районына керә торган Мәндәй, Чалпы авылларыннан килеп укыдылар. Монда шулкадәр белемле, көчле укытучылар укыткан икән. Ике улыма да шушы мәктәптә белем алырга насыйп булды. Аннары икесе дә үз көчләре белән Казанга институтка укырга керделәр. Флера Абзаловна – рус теле укытучысы, Чувашаева Саимә Гарифулловна – математика, Садриев Мисхәт Мисбахович физика укытучысы иде.

Флера Абзаловнаның тагын бер кешелеклелек сыйфатын язып үтим әле. Кышкы бураннарда, яз көне юлга су төшкән чакларда Рантамак, Рангазар, Яхшы Караннан килеп укучыларны ул үз фатирына алып кайтып, ашатып-эчертеп, өендә кундыра иде.

Александровка мәктәбе белән әле дә кызыксынып торам. Кызганыч, дүртәр йөз бала укыган мәктәпне тугыз еллыкка гына калдырганнар. Хәзер биредә нибары 50–60 лап кына бала укый.

Үзем Җәлилдәге «Җәлил чаткылары» әдәби-иҗат төркемендә әгъза булып торам. Монда да күбесе укытучылар. Сөйләшүләренә, үз-үзләрен тотышларына сокланып туймаслык. Укытучы иң кирәкле, затлы һөнәр шул.

Халисә ШӘЙДУЛЛИНА.
Сарман районы, Җәлил бистәсе.

Күзкәй авылында үсмер чакларында ук фермага килеп, гомер буе терлекчелектә эшләгән Ләбүдә белән Мөсфирә Хуҗиәхмәт кызлары яши. *Әтиләре беренче көннәрдән үк сугышка киткән. Әниләре Хәнифә кечкенә биш баласы белән калган.*

Мин аларга әтиләренең фронттан язган хатлары белән танышырга, истәлекләрен барларга дип кердем.

– Әтинең төсен дә хәтерләмибез инде. Беренче айларда әнигә өметле генә хатлар язган. Күпмедер вакыттан соң хат килү тукталды. Аннары өметләрне сүндереп, үлгән хәбәре килде, – дип сөйли Ләбүдә апа. – Мунча хәтле генә өй, эти өй салырга ниятләп йөргәндә сугыш башланган. Сәкедә тезелешеп йоклыйбыз. Әнине бик сирәк күрә идек. Таңнан эшкә чыгып китә, караңгыда гына егылырдай булып арып кайта. Көндезләрен әби килеп күз-колак була, эш куша. Кесәсендә бер зур бәрәңге булыр иде, аны бишебезгә тигезләп бүлә. Җәй көне бераз рәхәткә чыгабыз: башта кычыткан, аннары балтырган, алабута, чөгендер яфрагы ашыйбыз. Без балаларга ярый әле, таянырга терәге булмагач, әнигә бик авыр булды. Шулай бер елны, салымыгыз түләнеп бетмәгән дип, сыерны алып чыгып киттеләр. Әнкәебез бөтен документларны җыеп Минзәләгә китте. Аннан: «Хөкүмәткә юкка рәнҗегәнмен, сыерны алып чыгып китәргә тиеш булмаганнар», – дип кайтты. «Недоимка»ны каплап, әнигә калган акчасын биргәннәр. Шул суммага бер бозау, кәҗә сатып алдык. Әле бит калган түләүләр дә хәттин ашкан: хөкүмәткә 40 килограмм ит, 250 литр сөт, йомырка, 3 центнер бәрәңге тапшырырга кирәк. Сеңлем Мөсфирә белән әнине искә алып, аның чыдамлыгына хәйраннар калабыз. Кайлардан көч алды икән, иренең кайтасы юк, өмет өзелгән, балалар дип тырышкан инде, бахыр. Колхоз эшенә карусыз иде: тавыклар карады. Йомыркаларын каргалар алмасын дип, без дә көннәр буе шунда урала идек. Бераздан аны сарык фермасына күчерделәр. Аннары әни безне колхоз басуына ияртеп йөри башлады, чүп утыйбыз, урак урырга өйрәндек. Без утап җыйган үләнне әниләр «уфалла» арбасы белән тартып кайта. Без арттан этәбез.

– Берзаман районнан сарык сөте тапшырырга язу килде... – дип дәвам итә Ләбүдә апа. – Сугыш беткәч тә җиңеллек сизмәдек. Ачлыгына да түзәргә, ризыгын да юнәтергә өйрәндек, этиле буласы килү үзәкләрне өзде. Үлгән хәбәре килсә дә, өмет сүнмәде. Күктә самолет күргән саен, капка башына менеп, бар көчемә: «Әтине алып кайт!» – дип кычкыра идем.

Безне, буй җиткереп килә торган кызларны, Лаешка урман кисәргә җибәрделәр. Су басарга тиешле болынны агачлардан чистарттык. Урман кисүдән кайту белән Калининград өлкәсенә торф чыгарырга киттек.

Аннары – колхозның терлекчелек фермасы. Мөсфирә дә, Ләбүдә апасына ияреп, сыер саварга килә. Һәм шушы авыр хезмәткә алар 30–40 ел гомерләрен багышлыйлар.

– Ни хәл итәсең, яшьлегебез сугыш чорына туры килде, – ди Ләбүдә апа. – Тик менә 77 ел тыныч тормышта яшәсәк тә, сугыш ятимнәренә, үсмер чакларында ук тормыш тәртәсенә җигелгән буын кешеләренә һаман да игътибар юк. Габделфәт Сафинның «Уфалла арбасы» җырын тыныч күңел белән тыңлый алмыйм. Ул җыр – сугыш чоры балалары язмышы...

Тәнзилә ШӘЙХНУРОВА.
Тукай районы, Күзкәй авылы китапханәсе мөдире.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адр ес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

ХАТА

Гөлнур
САФИУЛЛИНА

Тормышта бер генә кеше дә хаталардан хали түгел. Без ясаган хаталар бер-берсеннән зурлыгы йә кечкенәлеге белән генә аерыладыр. Кечкенәләре шунда ук онытыладыр. Ә зурраклары, язмышыңны башка сукмактан алып кереп киткәннәре... Алары башка шул. Алары сине гомер буе озата бара.

– Биергә чакырды ул мине... Ялындырып тормадым, шунда ук ризалаштым. Күтәрелеп күз салырга, озын буйлы, бөдрә чәчле чибәр егет икәнен күрергә өлгердем, билгеле. Күзләренең зәңгәр икәнен генә ул чакта ук аңлап бетермәдем... Бүтән берәр кыз булса, башы күккә тияр иде. Ә минем исем дә китмәде. Күренеп тора – шәһәр егете. Күрше отрядтагы шундый бер егетнең бәйләнүеннән, сагыз төсле ябышуыннан яңа котылган чак. Каланыкыларга никтер ышанычым юк иде шул минем. Гомумән, шәһәрне беркайчан яратмадым. Институтка укырга кергән елны еладым да, еладым... «Кире кайтыйм әле, сыер саварга да ризамын», – дип, әнигә көнаралаш хат яздым. Мәктәпне «бишле»гә генә тәмамлаган кеше югыйсә мин... «Балакаем, классташларыңның берсе дә авылда калмады бит», – ди әни җавап саен. Шундый матур авылыбыздан, гаиләдән, балачактан аерылуны бик авыр кичердем шул. Җитмәсә, башкалар кебек атна саен кайтып та йөреп булмый – районыбыз Казаннан бик еракта, Башкортстан чигендә үк... Гектар-гектар чөгендер эшкәртәләр иде безнең якта: авыл кешесенең үзәгенә үткән эш. Әти белән әни шуңа күрә: «Теләсә кая укырга кер, авылга кайта торган белгеч кенә булмасын», – диделәр. Казан химия-технология институтына барып кердем. Группада бердәнбер татар идем... Бу мохиткә эләгүне дә авыр кичердем. Тулай торакта яшәүне дә. Гомеремдә беренче тапкыр тараканны шунда күрдем. Бигрәк өй баласы булганмын инде...

Төзелеш отряды белән бер районга эшкә баргач танышa ул Наил белән. Август ахыры, студентларның инде авылда соңгы көне була бу: иртәгә иртән биштәрләрен төйнәп юлга кузгалачаклар. Зур терлекчелек комплексы төзи алар – бетон идәннәр җәяләр. Моңарчы гомердә дә тотынып карамаган эш. Ашау – туяр-туймас, эш – авыр. Әмма яшьлек барыбер үзенекен итә – кич чыгасы, биисе дә килә!

Гөлназ ялгышмый – Наил, чыннан да, шәһәр егете булып чыга. Казаннан күрше авылга – әнисенең туганнарына кунакка кайткан икән. Бию көе тәмамланганчы ул боларның барысын да кызга сөйләргә өлгерә. Алай гына да түгел – хәтта кызның авыл адресын алырга да өлгерә! Гөлназ аны шунда ук әйтә: әйдә, бәйләнеп тормасын – барыбер язмаячак бит. Мондый егетнең Казанда бер түгел, мең кызы бардыр...

Төзелеш отрядында булган студентлар өчен каникул бер айга озыная – сентябрьне Гөлназ авылда уздыра. Әти-әнисенә булыша: бәрәңге, чөгендер алыша. Ә

артымнан хуҗа әби. Кып-кызыл булып оялып, башымны аска иеп кенә чыгып киттем.

Наил мине шул көнне үк өйләренә алып китте. Ә анда әзерләнеп көткәннәр! Галия апа соңрак бер сөйләшкәндә әйтте: «Гөлназны син һичшиксез ошатачаксың!» – дигән булган ул. Әнисенең фикере аңа бик мөһим булгандыр, күрәсең... Галия апа шундый яшь, чибәр иде. Мин аны башта Наилнең апасы дип белдем... Әтисе Хәмзә абый да шундый ачык, сөйкемле кеше. Сеңлесе Назирәне әйтмим дә! Без аның белән беренче көнне үк дуслаштык...

Алар бер ай гына очрашып калырга өлгерәләр. Нибары дүрт-биш тапкыр. Наил заводта токарь, эше сменалы. Гөлназ да укудан бушамый. Өстәвенә, фатир хуҗасы бер сәбәпсез гел каршы төшеп тора. Казанны зур авыл диләр. Дөрес ул: Наил аның бер танышларының улы булып чыга. Шуны белгән көннән алып, моңарчы: «Егетең бик әйбәт күренә – кулыңнан ычкындырма», – дип кенә торган әби кинәт кирегә сөйли башлый.

– Наилне ул ни өчен яратмады – аңламадым. Хәзергәчә аңламыйм... Аларга барып йөрүемне дә ошатмады. Һәр очрашкан саен Наил исә мине башта үзләренә алып китә иде. Анда мине көтәләр! Өйгә кайтып килгән кебек булам... Галия апаның соңрак моңсуланып: «Сезне аерыр өчен фатир хуҗаң да тырышты бугай... Шундый әйбәт, укыган кыз боларга булмасын, диде ахрысы», – дигәне булды... Октябрь башында укырга килдем, ә 10 ноябрьдә – Брежнев үлгән көнне Наилне инде армиягә алдылар. Барысы да бик тиз булды шул. Мин, мөгаен, үземнең хисләремне аңлап та бетерә алмаганмындыр. Үземнекен дә, аныкын да...

Бер үбешү түгел, кулга-кул тотынышырга да өлгерми калалар. Наилнең әниләре озату кичәсе оештыра. Шул кичтә икенче тапкыр икәү бергә бииләр. Егет, ярату тулы күзләре белән карап: «Бәлки, хушлашканда мине бер үбәрсең, Гөлназ?» – ди. Оятыннан җир тишегенә керердәй булган кыз, ишетелер-ишетелмәс кенә: «Мин үбешә белмим...» – ди. Көчле куллары белән Наил аны үзенә табарак тарта – шуннан артыгына бармый. Биюне дәвам итәләр...


– Көтәрсең бит мине? – ди ул.

Гөлназ «әйе» дип ым кага.

«Син безгә гел килеп йөр, яме. Әниләр сине ярата», – ди ул хушлашканда. Наил аерылышуны бик авыр кичерә. «Бу армия мине синнән аеру өчен генә уйлап табылган», – ди ул киткәндә. Кызның да күгән кара болыт каплый. Көне дә ямьсез, салкын, җитмәсә, илдә траур...

Гөлназ аңа, истәлегем булсын дип, затлы авторучка һәм чигүле кулъяулык бүләк итә.

– Наил Мәскәү янында хезмәт итә башлады. Хатлары гел килеп тора. «Сагынам», – дип яза. Әллә өченче, әллә дүртенче хаты иде. «Утырып еладым, син бүләк иткән ручканы «дед»лар сындырган, ә кулъяулыкны аяк астына салып таптаганнар. Йөрәгемне телгәләп аттылармыни...» – дигән. «Учебка» вакытында булган тагын кайбер хәлләрне язган. Әниләренә болар хакында сөйләми иде ул. Ә минем белән бүлешергә теләгән менә. Аңа да кыен булгандыр инде... Тик мин моны ул чакта


Фото: ru.freepik.com

беркөнне әнисе: «Почта килде, кызым. Бу сиңа!» – дип, хат тотып керә. Аптырап кала Гөлназ: берәүдән дә хат көтми бит ул. Аның Наилдән икәнен белгәч, тагын бер кат гаҗәпләнә. Күр, адресны отып калган, онытмаган! Эш юктан эш булсын дип яздымы икән? «Казанга кайчан киләсез? Мин сезне кайдан эзләп табыйм?» – дип сорый егет ул хатында. Җавапсыз калмас өчен генә Гөлназ да хат язарга утыра. Казанда кайда яшәячәген дә яшерми. Шәһәр буйлап аны эзләп йөрүе бик шикле, килмәс – болай гына сорыйдыр.

– Мин ул елны фатирга чыктым. Тулай торакта башка тора алмый идем инде... Фатир хуҗасы – бер әби. Сөйкемле генә күренде ул миңа. «Бер бүлмәдә өч кыз торачаксыз, алар якындагы училищеда укый», – диде ул миңа. 1 октябрь көнне килдем Казанга. Бүлмәдәш кызлар белән таныштык, ошадылар – бик тиз уртак тел дә таптык шикелле... Атна ахыры иде. Бергә чәй эчеп утырганда ишектә кыңгырау шалтырады. Фатир хуҗасы барып ачты.

– Гөлназ, синең янга килгәннәр! – диде ул миңа.

Тавышы кай арада үзгәргән: кырыс, усал. Ә бусагада... Бусагада Наил басып тора!

– Соңга калып кайтма! Миндә торган кызларны моңарчы егетләр эзләп килгәне юк иде әле! – дип калды



аңламадым. Наил өчен нигәдер оят иде миңа: аны кызганыч хәлдә күрергә теләмәвем иде бугай.

Егетенең әниләренә гел барып йөри Гөлназ. Анда аңа күңелле, үз өендәге кебек рәхәт. Галия апасы белән бергә өчпочмаклар пешерәләр. Тәмләп чәй эчәләр. Сөйләшеп утыралар – Наилне сагыналар... Фатир хуҗасыннан сорап, кайсы көнне аларда кунарга да калгалый. Әби монысын бик ошатып бетерми, билгеле... Ә Галия апасы белән Хәмзә абыйсы: «Күченеп кил, бездә тор. Һичьюгы, сессия вакытында бездә яшә. Әнә синә аерым бүлмә – тынычланып имтиханнарыңа әзерлән», – диләр. Галия апа аның өчен аерым халатка кадәр алып куя. Ак җирлеккә шәмәхә чәчәкләр төшкәнне. Икесенә пардан плащ ала. Икәү бергә каядыр барганда, танышлары очрап: «Кызыңмы әллә?» – дисәләр, «әйе» дип җавап бирә... «Мин бит сине шундый яратам, балам! Нәзек итеп токмач кисүләрең генә түгел, ничек итеп йоклауларыңа кадәр ошый миңа. Кереп, карап-карап торам», – ди ул. Ә беркөнне Хәмзә абый: «Гөлназ, әгәр Наилне көтмичә кияүгә чыксаң, барыбер урамда күрермен үзеңне. Ирең белән барганда: «Нигә улымны көтмәдең инде?» – диярмен», – ди. Оялып елмая гына Гөлназ. Нинди кияү? Беркем белән дә аралашмый лабаса ул. Гел бер сукмактан йөреп тора: өйдән – институтка, институттан – өйгә.

– Почта ящигыннан хатларны фатир хуҗасы үзе алып керә иде. Беркөнне Наилнең хатын тоттырды да: «Карале, Татарская ССР дип язган. Бигрәк безграмотный егет бу», – диде. Миңа шул җитә калды... Яшь чакта максимализм көчле була бит. Йөргән кешең турында читләрдән начар сүз ишетү бик нык тәэсир итә. Аның хаталы язуын моңарчы да күрә идем, билгеле. Ә бу хәлдән соң хатларын уку тәмам җәзага әйләнде. Конвертны ачуга, кызыл ручка белән хаталарын төзәтә башлыйм – дәфтәр бите кыпкызыл була. Хәреф хатасы төзәтү – чирем инде ул... Хәзер әнә ватсапта кайчак хата китә: кайберәүләр аңа игътибар да итми, ә мин яңадан төзәтеп язам... Аллаһы Тәгалә кичерсен, кызыл кара белән төзәткән ул хатларын бүлмәдәш кызларга да күрсәткәнем булды. Әйе, аның югары белеме юк иде. Аның каравы, укыган кешедән өч тапкыр күбрәк хезмәт хакы ала иде... Мәрхәмәтле кеше иде ул. Яхшы кеше иде! Әгәр шушы хатлар булмаса, мин аңардан ваз кичмәячәк идем. Хәзер шулай уйлыйм... Ә ул чакта... Ул чакта аннан гайрәтем чикте – язга таба хатларына җавап язмый башладым...

Икенче курсны тәмамлагач, тагын студентларның төзелеш отрядына җыена Гөлназ. Ул киткәнче, Галия апасы аның янына бер хезмәттәшен җибәрә. Үзе килергә көче җитмәгәндер инде... «Нишләп Наилгә хат язмыйсың? Ул бик көтә, борчыла икән бит. Нәрсә булды, нигә үпкәләдең аңа?» – дип кызыксына ул танышы. «Юк, үпкәләмәдем... Әмма үз-үземне дә аңлый алмыйм. Язарга теләмим», – дип җавап бирә Гөлназ. «Биздем», – ди. Үз халәтен аңлатырга башка сүз таба алмый.

Шул көзне Наилнең әтисе белән әнисе Мәскәүгә, аның хезмәт иткән частена барып кайталар. Гөлназны да үзләре белән чакыралар, әмма ул: «Стройотрядтан китә алмыйм», – дигән сылтау табып, барудан баш тарта.

– Минем җырлаганны алар берсендә магнитофонга яздырып алганнар иде. Наил шул кассетаны алып килүләрен сораган. Һәм өч көн буена гел бер җырымны тыңлаган:

Сагынганда ак болытка кара,
Ак болытлар булып мин агам.
Шыбыр-шыбыр яңгырява, димә,
Күз яшьләре булып мин тамам.

Миңа бу хакта Галия апа кайткач очрашканда сөйләде. Бу җырны кайда гына ишетсәм дә елыйм хәзер...

Ә аннан булачак ире белән очраша ул. Гел көтмәгәндә, уйламаганда. Кышкы сессия башланыр алдыннан Магнитогорскига барып кайтырга җыена кыз. «Цех башлыгы белән сөйләштек, сиңа эш бар, кил», – дип чакыра туганнары. Ошаса – бөтенләйгә китәчәк, читтән торып укуга күчеп, үз һөнәре буенча металлургия заводында эшли башлаячак. Шулай хәл иткән була Гөлназ. Зачетларын тапшыруга, билетка дип бара. Әмма буш кул белән, бик күңелсезләнеп кире борылып кайта. Самолетка билетлар сатылып беткән! Кайтса, ул югында аны эзләп стройотрядта бергә булган бер кыз килеп киткән. «Яңа елга сине үзебезгә алып кайтмакчы идем. Иртәгә шул вакытта РКБ янында көтәм», дигән язу калдырган. Аптырап китә Гөлназ: якын дус кыз дип тә булмый, бергә укымыйлар, бергә тормыйлар. Әмма бу тәкъдимнән баш та тарта алмый – авылны артык ярата шул ул. Үзләренә исә кышкы каникулсыз әле кайта алмаячак. Кунакка кайсы авылга түгел, кайсы районга чакырганнарын да белмичә, юлга чыгып китә ул. Әйтерсең нindidер бер көч этеп алып бара.

Ә күкләрдә инде барысы да хәл ителгән була... Яңа елга өйләренә дус кызының абыйсы да кайта. Авылда йөргән кызы бар икән – беренче көнне ул әле аны озата. Аннан инде сеңлесе белән кунак кызы яныннан бер адымга да читкә китми.

– Ниндидер мизгеллек эйфория булган инде миндә... Яшь аермабыз 8 ел. Ул инде үзенә нәрсә кирәген белә. Бик белә! Дөньяның ачысын-төчесен күргән. «Фәнил абый миңа өйләнсә, нинди бәхетле булыр идем», – дип уйлаганым истә... Автовокзалга килеп, ул безне Казанга озатып җибәрде. Аннан миңа хат язды. Хат идеаль почерк белән, бер хатасыз язылган иде. «Сүнеп барган йөрәккә ут капты...» – дигән. Кыз бала мондый сүзләр каршында көчсез инде ул...

Икенче юлы Фәнил Казанга аның янына килергә җыена. Тизрәк булсын дип, самолетка билет ала. Ә Гөлназның адресын өендә онытып калдыра! Сеңлесе авылда чак була. Хәбәрләшеп, тиз генә сорап алырга әле бүгенгедәй кесә телефоннар юк. Гагарин урамы буйлап озак эзләп йөри ул кызны. Ә анда биш катлы йортлар урамы белән тезелеп киткән... Хаты килә. «Сине тапмыйча кайтып киттем», – дигән. Бер хатасыз! Өченче атнада Фәнил тагын юлга чыга. Бу юлы инде кызны күреп, тәкъдим ясап китә. Уйга кала Гөлназ. Беренче имтиханын – «бишле»гә, икенчесен – «дүртле»гә, өченчесен – «өчле»гә бирә. Соңгысын инде бирә дә алмый.

Аның бәхетле икәнен белсәм, миңа бу кадәр авыр булмас иде…

– Миңа аның төзелеш институтын тәмамлавы ошады бугай. Беренче критерий шул булды. Тормышта кешенең югары белеме булу-булмауның мөһим түгел икәнен ул чакта аңламый идем шул әле… Укымышлы, акыллы ирдән акыллы балалар туар дип уйладым. Алгарак китеп булса да әйтим, өч бала таптым. Өчесе дә бер үк белгечлеккә ия булып, үз өлкәләрендә бик яхшы эшлиләр. Кайсының үз фирмасы бар. Кайсысы үзе эшли торган оешмада дәрәҗәле белгеч… Алдагы атнага Фәнил тагын килде һәм мине үзләренә алып кайтып китте. «Хәзер бергәләп кайтабыз да, аннары әти-әниләре белән мине сорарга баралар», – дип уйлыйм. Безнең якта тәртип шулай… Ә Фәнил белән мине табыннар әзерләп каршы алдылар. Мулла чакырып, никах та укып куйдылар. Ул кичтән, ул төннән соң эчемдә нәрсәмдер өзелде… Бик нык еладым. Нәрсәгә елаганымны да аңламадым…

Туйлар узгач, Казанга минем әйберләрне алырга дип бардык. Чүп түгәргә чыгарга дип ишекне ачсам, Галия апа басып тора. Исәнләшергә дә онытттым.

– Кызым, чынмы бу хәбәр? – ди.

– Әйе шул… – дим.

– Ирең дә мондамы? Чыксын, күрим әле, улымнан кай ягы белән яхшырак икән?.. Укыган кеше дигәнсеңдер инде… – диде ул.

Тормышта төрлесе булды. Үкенгән чаклар да күп булды. Без өйләнешкәндә ирем районда прораб иде. Эштән бик соң кайта. Дөресрәге, кайтаралар… Бөтен төзелеш материалы аның кулында бит… Хата ясаганымны аңладым, әлбәттә. Башымны мендәргә тыгып елый идем. Руслар арасында яшибез, бер танышым юк. Балага уздым, үзем уйлыйм: «Берәр җитди сәбәп чыксын иде дә, аерылып китәр идем», – дим. Хыянәт иткәнен көтәм инде ягъни мәсәлән. Кая ул читләргә күз ату?! Ирем мине яратты, хәтта суларга һава калдырмыйча яратты… Әйе, тормышта күңелле чаклар да булды, кайгылы вакытлар да, авыры да, җиңеле дә… Мин гомер буе Наил белән очрашудан куркып яшәдем. «Вәгъдә биргәч, нигә көтмәдең?» – дип соравыннан курыктым. Әгәр аны вәгъдә дип әйтергә яраса инде… Җавабым юк иде. Улым үсеп җиткәч, тагын да зуррак курку өстәлде: ул армиягә китәр дә, аны сөйгән кызы ташлар дип курыктым. Чөнки улым бер генә кызны яратты: әллә нинди интригалар корууларына карамастан, һичкемгә күз салмады. Шөкер, озак кына йөреп, шул кызга өйләнде ул.

Еллар уза. Социаль челтәрләр барлыкка килгәч, балалары Гөлназга да «ВКонтакте»да үз битен ачып бирәләр. Ә беркөнне шунда яңа хәбәр ала ул. Наилнең сеңлесе язган! Алар очрашып йөргәндә әле кеп-кечкенә булган кыз. «Бу синме, Гөлназ апа? Синдер дип уйладым… Фотоң куелмаган, кыз чактагы фамилияң генә күрсәтелгән», – дигән. Язышa башлыйлар. Серне шунда ук ача сеңлесе. «Абыйның үтенече буенча язам. Сине «ВКонтакте»да ул эзләп тапкан. Язып кара әле: Гөлназмы икән, әллә түгелме, ди. Абый сине гомер буена оныта алмады», – ди.

Гөлназның кияүгә чыгу хәбәре ул чакта армиядә хезмәт итүче Наилгә бик тиз барып ирешә, әлбәттә. Хезмәт итәргә ярты ел калгач, ничектер җай табып ялга кайта ул. Бәлки дөрес түгелдер әле дип, кызның фатир хуҗасына бара. Ә әби аңа нигәдер бик ямьсез бер тарих сөйли. Имеш, Гөлназны дус кызының төрмәдән кайткан абыйсы көчләгән һәм ул шуңа кияүгә чыгарга мәҗбүр булган. Наилнең күңелендә нинди өермәләр купканын күз алдына китерү авыр түгел… Сеңлесе язуы буенча, ул үзен кая куярга белмәгән. Әле армиядән кайткач та, үз-үзенә бер хәл ясамаса ярар иде, дип, әти-әниләре бик борчылганнар. Аннары күпмедер вакытлар узгач Наил өйләнгән. Хатыны белән ике кыз үстергәннәр.

– Аның өчен сөендем. Бер мәртәбә чын йөрәктән сөя белгән кеше башканы да шулай яратырга сәләтле булгандыр дип уйладым. Яхшы ир, яхшы әти булгандыр… Мине социаль челтәрдә эзләп тапкач, кызымның сәхифәсенә кереп: «Әниеңнең матурлыгы сиңа күчкән», дип язу калдырган. Сеңлесеннән ул комментын алуын үтендем. «Миңа беркайчан да язмасын, лайклар да куймасын. Ирем көнче кеше… Абыең бик әйбәт иде, әмма язмыш булмаган, рәнҗемәсен», – дидем. Аннан сеңлесе мин гомер буе ишетергә курыккан теге сорауны бирде:

– Нигә башкага кияүгә чыктың син, Гөлназ апа? Абыйның үзеңне никадәр ратканын ничекләр аңламадың? – диде.

– Армиядән кайткан кеше миңа өйләнәме әле, юкмы, дип уйладым, алучы барында чыгып калыйм, дидем…

Әмма бу дошмен калмас өчен генә бирелгән җавап иде.

– Эх, Гөлназ апа! Абыйныкы кебек яратуны мин гомерем буена да күрмәдем! – диде сеңлесе.

«Әнинең синең белән бик сөйләшәсе килә», – дигәч, телефон аша аралашу гөнаһ булмас, дип ризалаштым. Шалтыратты Галия апа. «И-и, балам, сагынам да инде сине… Нигә шулай эшләдең соң?! Кил әле бер, күрешик», – диде. Бармадым. Наил дә анда булыр дип курыктым.

Ә аннан Наил «геморрагический инсульт» кичерә. Аңа әле 50 яшь тә булмый… Бу хакта Гөлназга аның сеңлесе хәбәр итә. Галия апа да, шалтыратып, кайгысы белән уртаклаша. «Кул-аяклары начар хәрәкәтләнсә дә, шөкер, зиһене ачык. Гөлназ белән сөйләштегезме, дип сорап кына тора. Хәбәрләшкәнебезне белсә, бик шатлана. Бер генә күрер идем, дип әйтә», – ди.

– Яңадан алар гаиләсе белән аралашуым Наил өчен зыянлы булды, ахрысы, дип, Галия апа белән сөйләшүдән, сеңлесе белән язышудан туктадым. Аның инсульт кичерүенә сәбәпче булган булсам дигән уй тынгылык бирми. Наил мине шул дәрәҗәдә яраткан дип башыма да китермәдем шул… «ВКонтакте»га ул соңгы тапкыр 2016 елда кергән. Исәндер дип өметләнәм. Югыйсә берәр хәбәр килеп ирешер иде. Бергә булмавыбыз өчен түгел, аны шундый авыр кичерешләргә дучар итүем, рәнҗетүем өчен үкенәм. Язмыш безне нигә очраштырганын, үземне өзелеп яраткан егетне нигә якын итә алмавымны аңламыйм.

КУЛЛАРЫМДА ЯРАЛЫ КОШ ИДЕ...

Лилия ГӘРӘЕВА

Язмышлардан узмыш юк, дибез. Бәлки, болай әйтү үзеңне юату гынадыр? Бәлки, без тормышта узасы сукмакларны үзебез билгелибездер? Үз вакытында, үзсүзләнеп, барган юлыбыздан читкә каерабыз да чытырманлы урман уртасында адашабыз. Төрле яктан авырлыклар баскач, чыгар сукмакларны таба алмый үрсәләнгәндә күңелгә уй килә: «Бу сынау миңа гамәлләрем өчендер...» Татарстанның халык артисты, «Зә-Ләй-Лә» төркеме җырчысы Зөлфия ВӘЛИЕВАның да тормышында сынаулар шактый була. Бертуган энесен югалта, аның кызын үз гаиләсенә алып, әни җылысын бирә. Ятим бала күңеле – канаты имгәнгән кош сыман... Җиңел булмаган Зөлфиягә ул яраларны дәвалау. Яңадан шул көннәргә кайтып, авыр хатирәләрне кузгатабыз.



Балалар турында сорашсалар, гел әйтәм: «Икене таптым, өчне үстердем».

– 1995 елның 26 декабре – тормышыбызны кыл урталай бүлгән көн. Иртән таң белән телефон тавышы һәрвакыт шөбһәле яңгырый. Болай да караңгы иртәнең бар нурын сүндереп, коточкыч хәбәр алдык – командировкага киткән җиреннән бертуган энем Рөстәм вафат булган. Ул көннәрне бүген дә искә аласы килми... Спортсмен иде. Беренче класстан ук спорт гимнастикасы белән шөгыльләнде, аны хәтта балет мәктәбенә дә чакырдылар, табигатьтән төз, матур гәүдәле кешеләр була бит – Рөстәм дә шундый. Чибәр, уңган... Мәктәпне тәмамлау белән аяк киемнәре тегәргә өйрәнеп, шуның белән шөгыльләнде. Рөстәм белән яшь араларыбыз бары яшь тә өч кенә ай безнең. Игезәкләр кебек үстек. Серләребез, куанычларыбыз уртак иде. Белмим, әти белән әни бу хәсрәткә ничек чыдагандыр, миңа язмыш белән килешүе бик-бик авыр булды. Егерме генә яшь иде бит аңа!

Рөстәм китте... Әтисенең төсен хәтеренә алырга да өлгермәгән өч айлык кызы калды...

Сиңа авырдыр, дип тормый тормыш, бер-бер артлы сынауларын җибәрә тора. Берничә елдан киленебезне кулга алдылар. Өч айда әтисен югалткан иде, инде әнисеннән дә аерылды Динара. Моны өлкән кешегә дә кичерүе җиңел түгел. Ә психикасы ныгып та җитмәгән бала ниләр кичерергә тиеш?! Җаны яралы, канатлары имгәнгән бер кошчык иде ул.

Безнең белән яшәргә ул үзе теләде. Авыр тормыш йөге белән килеп керде гаиләбезгә. Холкы формалашкан 11 яшьлек кыз бала...

Җан җылымның барысын да бирергә тырыштым мин аңа. Бу вакытта улыбыз Кәрим дә туган иде. Әни кешенең үз баласын ничек яратканын беләм бит. Динарага да шундый ук мәхәббәтемне бирәм кебек тә... Күңелдә – шик. Җитәрлек яратаммы мин аны? Эченнән генә: «Үз баласы булсам, болай гына булмас иде», – дип уйлап, кимсенеп йөрмиме? Янында уйнап, шаярып йөрсә дә, ятим баланың күңелендә чынлыкта ниләр барын беркем белми. Аны ныграк ярата дип уйламасын өчен, Динара янында мин хәтта үз улымны кочакларга да кыенсына идем. Кәримне кочагыма аласым, шулкадәр сөясем килгән чаклар була, ә мин моны эшли алмыйм, Динара үзен читкә кагылган итеп тояр кебек. Түзә алмыйча, ваннага кереп бикләнәм. Суны шаулатып ачам да үкси-үкси елыйм. «Мин хәзер үз баламны да ярата алмыйм, Динарага да мәхәббәтем җитәрлек түгел. Ике баланы да рухи гарип итәм бит», – дип үрсәләнәм. Якында гына урман. Ялгызым гына шул урманда йөреп, агачларны кочаклап, бераз тынычланган кебек булам. Ләкин ул тынычлану тыштан гына, ә эчемдә ут. Бик авыр халәт иде ул... Үзеңне гаепле итеп сизү халәте...

Ә бит мин үземне Динара каршысында да, әти белән әни, хәтта егерме яшеннән гүрдә яткан энем алдында да коточкыч гаепле сизеп яшәдем. Аның тарихы бик ерактан башлана...

Миңа яңа гына 18 тулган иде. Дус кызыма ияреп диңгезгә барасым килде. Ул әнисе белән Мыс Хака авылында яшәүче әбиләренә бара, мин дә аларга иярмәкче. Әти белән әнинең җибәрәселәре килми. Хәзер бик аңлыйм, ябь-яшь кызларын шундый ерак юлга чыгарып җибәрергә курыккан алар, билгеле. Шулай да, үзсүзләнеп, берәүне дә тыңламыйча, дус кызыма мин дә иярдем. Бик озын, әллә нинди газаплы юл булды ул. Самолетыбыз яшен болытына эләгеп, чын мәхшәр кичердек. Шуннан бирле миндә күккә күтәрелүдән курку яши. Ә бит бу әле юлның яртысы гына, тагын самолетка утырып, күпмедер очасы бар иде. Аннары да автобуслар белән бардык әле. Чын-чынлап җирнең читенә җиттек, диярсең. Анда барып урнашкач, мин бар акчамны урлаттым. Бөтенләй ят шәһәрдә, чит кешеләр арасында бер тиен акчасыз калып кара син?! Дөрес, ияртеп килгән танышларым мине ашаттылар. Ләкин моны шулкадәр күрсәтеп башкара иде алар, янәсе, менә, без сине ашатабыз, рәхмәтле бул! Кайтырыңа акча тап, без бирә алмыйбыз, дип, көн дә тукып торалар. Ә бит акча аларның туганнарында яшәгәндә югалды. Гөнаһына керә алмыйм, өйдәге акча кая киткәндер?

Шундый авыр иде миңа, диңгезләргә төшәрдәй булган идем. Ул вакытта бәхетемә дип уйладым, хәзер күрәчәгебезгә дим, Казаннан әлеге танышларымның дуслары килеп төште. Әнисе белән кызы. Алардан юллык акча алып торып, өч тәүлек бер валчык ризык капмаган килеш Казанга кайттым. Кайттым... Ә өйгә керергә куркам. Ике атнага дип кенә киткән сәфәрем ай ярымга сузылды. Хәзер булса, шалтыратыр идең, ватсабына язар идең, ул вакытта мондый мөмкинлекләр юк. Ишек аша әни белән әбинең шыпырт кына сөйләшкәне ишетелә. Исемә төшсә, шул чагында аларны кызганудан хәзер дә күңелем тула, аларны борчуга салганым өчен оялам. «Бүген дә кайтмас микәнни инде?» Әби шулкадәр өзгәләнеп әйтте бу сүзләрне. Нәкъ шул мизгелдә ишекне әкрен генә ачып, мин килеп кердем.

Күпмедер вакыттан соң, миңа акча биреп торган апаның кызы безгә кунакка килде. Рөстәм дә өйдә иде, кичләтеп кенә үзләренә кадәр озатып та куйды. Аларның дуслыгы шул көннән башланды. Искиткеч чибәр кыз иде ул. Бик матур итеп туйларын уздырдык.

Рөстәмнең үлеме, Динараның ятим калуы, әти белән әнинең бала хәсрәте кичерүләре сәбәбен мин әнә шул вакыйга белән бәйлим. Сүз тыңламыйча үзсүзләнеп чыгып китүем безне нинди авырлыкларга дучар итте. Анда бармаган булсам, Рөстәм, бәлки, Люцияне очратмас та иде. Аның да тормыш сукмаклары бөтенләй бүтән юлга алып чыгар иде. Башка иде бит Люциянең тәрбиясе, тормышка карашлары...

Һәркем үзе сайлаган юлын уза бу тормышта. «Син шушы юлны сайладың, – ди аңа Аллаһы Тәгалә, – ярый алайса, шул юлдан уз. Авырлыкларга зарланма, түз». Ләкин шунысы бар:

Фото: Анна Арахамия

Балага бит ашарына-эчәренә булу түгел, **күңелен аңлаучы булу мөһимрәк.**

үзебез белән бергә без якыннарыбызны да сынауларга дучар итәбез. Менә бит ул язмышлар ничек.

Яралы кош баласыдай кочагыма килеп сыенган Динараның язмышында да күпмедер микъдар үз өлешем барлыгы җанымны гел тырнап яшәде. Яшермим, авыр вакытлар күп булды. Үз балаңны үстерүе дә җайлы түгел бит. Күпме хаталар кылына, күпме кирәксез сүз әйтелә... Ул вакытта миңа 33 яшь иде. Әле үзем дә җитлекмәгән, күп нәрсәне белмим, зирәклегем чамалы. Хәзер булсамы? Мин аны башкача тәрбияләр идем.

Бала 6 яшенә кадәр үзен дөньяның кендеге дип белеп, яратуда коенып үсәргә тиеш. 10 яшеннән ир баланы – әтисе, кыз баланы әнисе бар эшкә өйрәтә башлый. Әни – эшне кушып кына торучы үги анага, ә кыз барысын да эшләүче Золушкага әйләнә. Университетта психология курсында укыганда безне шулай дип өйрәттеләр. Әйе, 40 яшемдә мин кабат укырга кердем. Үз кичерешләремне аңлар өчен кирәк иде миңа бу белем.

Динара белән исә бар да башкача булды. Аңа эш кушсам, ятим баланы эшләтә, дип әйтерләр төсле иде. Хәтта савыт-саба да юдырмадым. «Мин бит бу баланы дөньяга өйрәтергә тиеш. Аңа эшләргә дә туры киләчәк, үз-үзен кайгыртырга да», – дигән уй килгәндә Динарага инде 15 тулган иде. Балада эшлисе килү теләге уята торган чор узган... Өйне җыештыруның графигын элеп куйдым. Бер көнне – мин, икенче көнне ул җыештырасы. Ә аның эшлисе килми, сүз тыңлыйсы килми, киреләнә... Үзара сүзгә килүләр, үпкәләүләр әнә шул көндәлек эшләрне башкаруны таләп итүдән чыкты да.

Мин – идеалистка. Җайсыз сыйфат ул. Кешеләрдән идеаль мөнәсәбәтләр көтәм. Балалар да пыш-пыш серләшеп, дус булып, кочаклашып кына яшәргә тиеш... Ул бит алай була алмый. Хәзер мин моны аңлыйм, ә ул чакта...

Бервакыт бик күңелсез хәл килеп чыкты. Гримеркадан берәүнең акчасы югалды. Хәтерләмим, әллә үзе гаебен танымы ул, гаепле булып Динара калды. Шул вакытта минем ярсуларым, гарьләнүләрем: «Бу баланы шундый итеп мин тәрбияләп үстердем бит. Мин аңа тәрбия бирә алмаганмын». Курку белән ярсу бергә кушыла да, кеше агрессивка әйләнә. Мин Динараны рәнҗеттем, кимсеттем ул көнне. Акчаларны битенә ыргыттым. «Мә, шушы акча кирәк идеме сиңа?! Тутыр кесәңә, синеке булсын», – дип кычкырдым. Ул бер сүз дәшмәде. Әле дә күз алдымда – күзләрендә шулкадәр ачу, нәфрәт иде! Куркынган җәнлек күзләре белән карап торды ул. Хәзер булсаммы? Үлгәндә дә шулай эшләмәс идем. Акчаның нигә кирәк булганын сорашыр идем, баланы кимсетмәс идем... Гомерем буена күңелемдә онытылмас авыр вакыйга булып калды ул. Аның өчен Динара алдында миңа әле дә бик кыен.

Барысы да җыелып килгән булгандыр инде: миндә көчле депрессия башланды. Аңлата да алмаслык халәт. Иртән торасы, көзгегә күз саласы килми. Урыннан торып та булмый, өстән танк узган шикелле хис итәсең үзеңне. Соңыннан белдем, урта яшьләр кризисы булган ул. Көзгедән инде битләре сула төшкән, арыган ханым бага. Телевизордан ять-яшь сылу Зөлфияне күрсәтәләр. Мондый яшь чакның башка беркайчан да кабатланмаячагын уйлыйсың. Кырык яшенә кадәр кеше, әле булдырам, дип яши. Ә кырыктан соң күп нәрсәне инде булдыра алмаячагыңа төшенәсең.

Психологияне өйрәнә башлагач, беренче дәрестән үк елап кайтканым хәтердә. Югыйсә укытучының биреме гап-гади иде – йөз теләктән торган исемлек төзергә кушты. Теләкләр – хатын-кызның яшәү көче, энергия, ут... Бу көчен ул гаиләсенә, балаларына да бирә. Эчендә яшәү уты дөрләгән хатын-кызның теләкләре чиксез. Ә мин унөч теләгемне чак-чак барладым... Мин шулкадәр арыган, саеккан, көчсезләнгән булганмын. Бер яктан әнә шул кризисны кичерүем, икенче яктан гаиләдәге мөнәсәбәтләр, гел киеренкелектә яшәү, үземне битәрләү, барысына да яхшы булырга тырышу... Яхшы булырга тырышуның да тәкәбберлек сыйфаты булуын мин психологка укыганда аңладым. «Менә мин нинди яхшы, әйбәт», – дип белдерү икән ул.

...Динара бездә 18 яшенә кадәр яшәде. Ике бүлмәле фатирда өч бала, үзебез – биш кеше, шәхси пространствога урын калмый иде, билгеле. «Әбиләргә күчәм, аларда иркен», – диде ул. «Син аны акчасы өчен карыйсың», – дип әйтүчеләр булды. Әйе, опекун буларак, дәүләттән акча түләнә иде. Мин аның бер тиененә дә кагылмыйча, җыеп бардым. Динара бездән киткәндә шул акчаларны үзенә бирдем. Салкын саубуллаштык без. Дөресрәге, саубуллашмадык та бугай. Үпкәләп чыгып китте Динара.

Хәзер мөнәсәбәтләребез яхшы безнең. Бик акыллы, чибәр, зирәк кыз булып үсеп җитте ул. Укырга керде, яраткан кешесен тапты, үзенә ошаган эш белән шөгыльләнә. Аралашып торабыз. Ул миңа хәзер тагын да якынрак. Үзе хатын-кыз булып җитлеккәч, ул мине яхшырак аңлады бугай.

Минем аны әнисе белән якынайтасым килә. Икәү янына да барганыбыз булды. Кунакка чакырдым. Килде ул. «Алай булма, тегеләй бул», – дип, табын янында ук кызын яшәргә өйрәтә башлады. Үзен бик тәкәббер тотты. Динарага ошамады, билгеле. Җаны эремәде аның әнисенә карата. Хәзер дә күрешмиләр дип беләм.

Балачакта шундый бер чор була, бала: «Мин чынлап та бу гаиләдә тудым микән?» – дип шикләнә башлый, үзен монда яратмыйлар кебек тоела. Мин дә уздым аны. Хәтта әнигә белдерми генә документларында актарынганым да булды. «Мине яратасыңмы?» – дип, мең кат сорый идем. Динара миннән беркайчан да, мине яратасыңмы, дип сорамады. Ә мин аны бик яраттым, арттырыбрак та яраттым бугай. Әле дә яратам һәм бик горурланам.



Белгеч фикере

БАЛА АКЧА БЕЛӘН ТАНЫШЫП ҮССЕН

Ләйсән ХАЛИКОВА,
финанс белгече

Балаларыбызның киләчәге яхшы булсын өчен аларны финанс темасы белән кече яшьтән үк таныштыра башлау хәерле. Кемдер финанс грамоталылыгына өйрәтүне балага 2,5 яшь тулуга башлый, ә кемдер, укырга кереп, математика дәресе белән таныша башласын, дип көтә. Мин балага 2,5–3 яшеннән әкренләп мәгълүмат сеңдерә башларга тәкъдим итәм. Шунысын да әйтми калып булмый: баланы өйрәтүдән түгел, үзебезне тәрбияләүдән башлау зарур. Баланы көннәр буе өйрәтеп утырып та, үзебез акча белән эш итә белмибез икән, мәгълүматны тиешенчә җиткерә алмаячакбыз.

Балага финанслар темасын уен форматында өйрәтү яхшы. Кибеттә «CashFlow», «Монополия» кебек өстәл уеннары сатыла. Ниндидер махсус уеннар сатып алу мәҗбүри түгел. Без бала вакытта «кибет-кибет» яисә «ресторан» уйный идек. Агач яфраклары акчалар ролен үтәде. Әйбер сатып алгансың икән, аның өчен түләргә кирәген белеп үстек. Һәр уенда финанслар темасын тартып чыгарырга була, моңа әти-әниләрнең фантазиясе генә кирәк.

Билгеле бер яшькә җиткәч, баланың кулына акча бирә башлыйбыз. Үсеп киткәч кенә бирә башласаң, ул чаманы белмәскә мөмкин. Башта чикләп килеп, аннары кисәк бирәсең икән, бәйдән ычкыну җиңел. Әлбәттә инде, бик кечкенә балага акчаны күп итеп бирергә ярамый. Нәрсә алырга уйлыйсың, ул әйбер ничә сум тора, дип, бала белән сөйләшеп, шуннан исәпләп бирә башларга була.

Хәзер балаларга да банк карталары ясату актуаль. Ул әти-әниләрнең картасына бәйләнгән була, баланың бөтен сатып алулары аларга хисап булып килеп бара. Көненә яки аена фәлән сумнан да күбрәк тотарга ярамый дигән чикләү дә куярга мөмкин.

Акча каяндыр күктән төшә дип уйламасын өчен, аңа акчаны эшләү турында да аңлатырга кирәк. Каян килгәнен, чиксез түгеллеген белсен. Син эшлисең, сиңа шуның өчен акча түләнә, дип гадиләштереп аңлатырга була. Әти яки әни кешенең эш урынына алып барып күрсәтү мөмкинлеге булса да бик әйбәт. Бала кечкенә әле, барыбер аңламас, дип уйларга кирәкми. Хәзерге балалар бик акыллы, тиз эләктереп алалар, өстәвенә, кече яшьтә кызыксынучан да булалар, барысын да сеңдереп баралар. Бу урында психологик «установкалар» турында да әйтеп китик. Совет чорында тәрбияләнгән кешеләрдән «акча юк», «бу әйбер бик кыйммәт», «җигелеп эшләсәң генә акчаң була» дигән сүзләрне еш ишетәбез. Бу әти-әниләрдән безгә дә күчкән. Һәм шундый «установкалар» безгә һәм бездән соңгы буынга бик зур зыян китерә. Шуңа күрә «Акча юк, моны алмыйбыз», – дип хәйләләргә, шул рәвешле балада җитешсезлек, мескенлек хисләре тудырырга түгел, бәлки, «Акчабыз булса да, аны экономияләргә кирәк, теләсә нәрсә алмаска, ниндидер максат өчен җыярга», – дип, дөресен аңлатырга тырышырга кирәк.

Акчаның күктән төшмәгәнен, аны эшләп алырга кирәген балага эштә дә күрсәтсәң яхшы. Үзе акча эшләп карасын. Кемдер әнисенә – идән, әтисенә машина юышкан өчен, ә кемдер мәктәптә әйбәт билге алган өчен дә балага «премия» түли. Штраф системасын да кертергә була. Әйтик, идәнне яки машинаны чиста итеп юмаган икән, штраф саласың – акчасын кисәсең. Бу балага стимул бирәчәк, яхшырак эшләргә, тәртипкә өйрәтәчәк. Ата-ана белән бала арасында кулланучы мөнәсәбәте барлыкка килмәсен инде. Эшләгән саен акча биреп торсаң, алга таба ялкауланып, эшләми башларга, акча бирсәң генә эшлим, дияргә мөмкин. Шуңа күрә бу эштә дә чаманы белү зарур.

Кайбер ата-аналарның бик зур хатасы: баланың үзе эшләп тапкан, әби-бабасы биргән, аш мәҗлесләрендә җыелган акчаларын тартып алалар да яшереп куялар. Бала үземнең акчам бар, мин түли алам, дип күреп өйрәнергә тиеш дигән фикердә мин. Бу анда җаваплылык хисе тәрбияли. Әйтик, кибеткә барасыз. Бала аяк тибеп моны ал, тегене ал дип сорый. Аңа: «Аласың килә икән, әйдә синең акчадан тотабыз», – дип әйтергә була. Шулай булганда, бала чынлап та уйлана: ул әйбер аңа кирәкме, үзенең акчасын түгәргә ризамы, юкмы. Бәяләрне чамаларга, акчасы җитеп бетмәсә, җыярга, экономияләргә дә өйрәнә.

Ата-ана баласына бөтен булган акчасын күрсәтеп, аны акчада коендырып яшәтергә тиеш түгел. Беренчедән, алай эшләгәндә бала иркә булып үсә. Икенчедән, кечкенәләрнең уендагы – телендә. Өендә күргәнен дуслары белән дә бүлешә, чит кешеләр дә ишетеп кала ала. Бу куркыныч хәлләргә китерергә мөмкин.

Фәнзилә МОСТАФИНА
әзерләде.



Фото: ru.freepik.com



Сорауларга Республика клиник балалар хастаханәсе офтальмологы Фәрит ГЫЙЛЬМАНОВ җавап бирә.

Улыбызның күзенә еш кына арпа чыга. Дәвалыйбыз, ләкин берәр атнадан ук икенче күзенә чыга. Айлар буена сузылырга мөмкин шулай. Без арпаны дәвалап бетермибезме, әллә дөрес дәваламыйбызмы?

Арпа чыгу медицина терминологиясендә халязион дип атала. Ул күз кабагы ялкынсынуы (блефарит, күз кабаклары демодекозы) аркасында да, иммунитет какшау сәбәпле дә булырга мөмкин. Шулай ук ашкайнату тракты авыруларына: паразитлар булу-булмауга, үт юллары дискинезиясенә, эчәк дисбактериозына игътибар итегез.

Кызыбызга ике ай. Күзе еш яшьләнә, урамда йөргәндә – бигрәк тә. Күз төпләре дә шешенеп тора. Зондирование ясатырга кирәк булыр микән? Дәвалауның альтернатив юллары бармы?

Күз яше юлларының патологик кысылуы дакриостеноз дип атала. Дәвалауны күз яше капчыгын массажлаудан башларга кирәк. Һәрхәлдә, сезнең очрак кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итүне сорый. Зондирование ясауга күрсәтмәләрне табиб кына бирә ала.

Кылый күзлелек тумыштан гына була дип уйлый идем. Беренче сыйныф алдыннан узган медицина тикшеренүе вакытында табиб кызыбызда кылый күзлелек билгеләрен күрде. Бала үскән вакытта да кылый күзлелек килеп чыга аламы?

Кылый күзлелек тумыштан да була, үсү дәверендә дә төрле сәбәпләр аркасында килеп чыга. Начар күрүче балалар саны елдан-ел арта. Чөнки компьютерны, телефонны ешрак кулланган саен, бик кечкенә яшьтә үк ныгып бетмәгән күзләргә авырлык килә. Бу, үз чиратында, тумыштан булмаса да, үсү дәверендә күрү белән бәйле проблемалар китереп чыгара. Дәвалауны вакытында башлагыз, күзлек кияргә кирәк булыр, мөгаен. Күз гигиенасына игътибар итегез, профилактик чаралар кулланыгыз.

Уку елы башында баланың күзләренә аерым игътибар кирәкме? Уку, дәресләр әзерләү, компьютерда эшләү аркасында күзләргә көч килә бит.

Бу сорау алдагысы белән аваздаш. Күзгә көч килмәсен, киләчәктә күз күреме белән проблемалар тумасын өчен профилактик чаралар куллану яхшы булыр. Күзләр арыганын сизә башлауга, баланы тәнәфес ясап алырга өйрәтегез. Тәрәзә аша ераккa карап алсын, күзләрен йомып торсын, күзләрне төрле якларга йөртеп, бүлмәне күзәтсен. Саф һавада йөрергә онытмагыз, бу да күзне бик яхшы ял иттерә.

Нәниләргә күчтәнәч!
Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.



Кадерле әниләр!
«Яшь әни» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Балаларга кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.



Сорауларга Казан шәһәренең 7 нче балалар поликлиникасы хирург-ортопеды Айрат ГАРИПОВ җавап бирә

11 яшьлек кызыбыз соңгы ярты елда кисәк үсеп китте. Еш кына тезләре авыртудан зарлана. Бу авыртулар кисәк үсеп китү белән бәйле була аламы? Бәлки организмга кальций җитмидер?

Тезләр авыртуының сәбәбе еш кына остеохондропатия була, ягъни түбән очлык сөякләренең үсү зоналары үсеше белән бәйле авыртулар. Спортчы балаларның сеңерле бәйләвечләренә һәм минискларына еш зыян килә, болар да баланы борчылырга мәҗбүр итә. Буын тирәсенә көч килгәндә авырту да көчәя. Тез буыннары ювениль артрит аркасында да авыртырга мөмкин. Андый очракта тезләр күбесенчә иртәнге якта авырта. Тиз үсеш чорында да балалар тез авыртуыннан еш зарлана. Һәрхәлдә, моны игътибарсыз калдырмагыз, беренче билгеләре барлыкка килү белән ортопедка, ревматологка мөрәҗәгать итегез.

Хәзер кроксы дигән яңа аяк киеме бик популяр. Җәй көне балалар салмыйча диярлек киеп йөриләр. Бассейнга, тренировкаларга да алмашка алып йөрибез. Аларның аяк табаны өчен зыяны юкмы?

Аяк табаны патологиясе булмаган балаларга кроксы киеп йөрүнең зыяны юк. Әгәр балада яссы табанлылык, чалыш аяклылык билгеләре булса, көндәлек кияр өчен башка аяк киеме киңәш итәр идем. Пляжда, бассейнда кыска вакытлы гына киеп йөрү зыян салмый. Әмма бу аяк киеме спорт белән шөгыльләнү өчен дә туры килми.

Мәктәп өчен икенче аяк киеме итеп кызыбыз үкчәле туфли сайлады. Үкчәсе бик биек булмаса да, 14 яшьтә андый аяк киеме киеп йөрү зыянлы түгелме?

12 яшькә кадәр үкчә биеклеге ике сантиметрдан да артмаска тиеш. 13–18 яшьлек үсмерләр өчен аның биеклеге 2,5 сантиметр булса яхшы. Бөтенләй үкчәсез аяк киеме кию дә дөрес түгел, шуңа күрә балеткалар, кедалардан баш тартыгыз. Биш сантиметрдан биегрәк үкчәле аяк киеме кию бала өчен куркыныч тудыра – буйлы (продольный) яссы табанлылыкка һәм варикозга китерергә мөмкин. Аяк киеме җиңел, уңайлы, амортизацияли торган табанлы, натураль тукымалардан тегелгән булырга тиеш.

Балабыз әле тәпи йөри генә башлады. Яссы табанлылыктан профилактика өчен ортопед өйдә каты аслы аяк киеме киеп йөрергә киңәш бирде. Диагноз куелмаса да, моның кирәге бармы?

Ортопед шундый киңәш биргәч, димәк, баланың вальгуслы деформация билгеләре бар. Бала әле йөрергә генә өйрәнгәндә мин профилактик аяк киеме киңәш итәр идем. Аның супинаторы булуы мөһим, кырлары тубык сөягеннән 2 сантиметрга биегрәк һәм яссы табанлылыкны чикләүче «Каблук Томаса» булсын. Мондый аяк киемен бер-ике атна дәвамында көненә ике-өч сәгать кидертегез, яшь ярымда инде көне буе кидертеп йөрерлек итеп, вакытын арттырыгыз. Шушы киңәшләргә колак салмасагыз, вальгуслы деформация артачак кына, махсус ортопедик аяк киеменә күчәргә туры киләчәк.

СОРАУ—ҖАВАП

Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

УКУЧЫ БАЛАЛАР ТУКЛАНУЫ

Яңа уку елына кердек. Мәктәптә ныклы белем алсын өчен балаларның сау-сәламәт булуы мөһим. Ә бу турыдан-туры туклану рәвеше белән бәйле. Аларның ничек туклануын без, әниләр, тәэмин итәбез. Дөрес ашарга гадәтләндерү дә безнең өстә. «Баш мие эшчәнлегенә йөкләмәләр булганда дөрес туклану аеруча мөһим. Уку елы дәвамында моңа игътибарлы булу зарур», – ди диетолог, нутрициолог Алия САФИНА.



Укучының иртәнге ашы нинди булырга тиеш? Йогуртлар, кукуруз күпертмәләре зыянлы түгелме?

Күпләр белә инде: иртәнге аш аксымнарга һәм майларга бай булырга тиеш. Катлаулы углеводлар да ашарга мөмкин, әмма аларга аксымнар һәм майлар кушу мәҗбүри. Кукуруз күпертмәләре, йогуртлар, боткалар – җиткелексез иртәнге аш. Озак та үтми баланың ашыйсы килә башлый. Ул инде дәрестә укытучыны тыңламаячак, ашау турында уйлаячак. Укучы өчен туклыклы иртәнге аш комплексы: йомырка (сүз уңаеннан, йомырка сарысында холин бар. Ул хәтер процессы өчен бик файдалы), ак май, корица, баланың яраткан җимешләрен салып, суда пешергән тары боткасы, каты сыр йә күркә ите, йә бавыр паштеты белән бер кисәк ипи, бер чәй кашыгы бал салып суда ясалган какао йә шикәрсез морс.

Укучының туклану рационында нинди ризыкларга өстенлек бирергә?

Бала үсә, шуңа күрә көнгә 4–5 тапкыр төрләндереп ашатырга кирәк. Энергия бирә, баш миен эшләтә торган ризыклар сайларга тырышыгыз. Мәсәлән, мәктәптә бирелгән мәгълүматны оныту гадәте организмга цинк җитмәү белән бәйле булырга мөмкин. Ә цинк тавык, куян, майсыз сыер итендә, каты сырларда бар. Хәтерне яхшырту өчен иң яхшы табигый элемент – холин. Ул йомырка, бавыр, тәрәч балыгы, солы ярмасы, борчак, эремчектә бар. Әгәр укучы балагыз таркау, игътибарсыз, ярсучан икән, ризыкны B1 витамины булган продуктлардан әзерләргә тырышыгыз. Көрпәле оннан пешерелгән ипи, тары, солы, арпа, карабодай, бавыр, фасоль, ясмык, әстерхан, эрбет чикләвеге әлеге витаминга бай.

Балаларга сок бирергәме, әллә компотмы?

Сокларда, компотларда клетчаткалар юк. Аларны эчү баллы ризык ашауга тиң. Шуңа күрә җиләк-җимешкә өстенлек бирсәгез яхшырак.

Укучыга мәктәптә туклану мөһимме? Анда ашаудан баш тарткан балалар нинди проблемалар белән очрашырга мөмкин?

Укучының мәктәптә ашавы йә капкалап алуы үтә дә мөһим. Озак ашамый торсалар, күпчелек балаларның каннарында шикәр дәрәҗәсе кисәк кенә кими. Нәтиҗәдә, хәлсезлек барлыкка килә, баш авырта. Мондый хәлдә уку турында уйламый инде бала. Өйгә кайтып көндезге аш ашарга мөмкинлек юк икән, коры ризык капкалап алуга караганда мәктәп ашханәсендә туклану яхшырак.

Замана балалары өйдә пешерелгән ашка караганда фастфудларга өстенлек бирә. Тиз арада ясалган ризык файдалы була аламы?

Фастфудлар берничек тә файдалы була алмый. Җитмәсә, аларга тәм арттыргычлар, буяулар кушылган. Бу ризыкларны ашаганнан соң ашказаны тулачак, әмма организмга кирәкле аксымнар, витаминнар кермәячәк. Өстәвенә, алар зыянлы да әле. Мәсәлән, бала-чага яраткан бәрәңге чипсларында хәтта җитештерүдә кулланыла торган төрле пластмассалар һәм буяулар бар. Ул чипсларны киптергән алмага йә чикләвекләргә алыштырырга тырышыгыз. Балага кечкенәдән үк уен формасында фастфудларның зыянын аңлатыгыз. Үсмер чагында «ашама» дип әйтү нәтиҗә бирмәячәк.

Мәктәптә капкалап алу өчен балаларга нәрсә бирергә мөмкин?

Тәнәфесләрдә капкалап алу файдалы һәм кызыклы булсын. Моның өчен матур ланч-бокс әзерләгез. Мәктәпкә җибәрү өчен иң яхшысы, әлбәттә инде, яшелчә. Анда клетчатка да, витаминнар да күп, баллы ризыклар кебек тешләрдә кариес та барлыкка китерми. Шуны да онытмагыз: артык күп капкалау аппетитны боза. Шуңа укучы сумкасына артык ризык салмагыз. Су турында да онытмагыз. Һәрвакыт шешә белән су бирегез. Ә кышын йөртер өчен кечкенә термос булдырыгыз. Анда шикәрсез морслар сала аласыз.



ТЕЙПЛАУ

Спортчыларның тәннәренә ябыштырылган ленталарны күптәннән күрәбез инде. Косметологиядәге алдынгы алымнарны күзәтеп, кулланып барганнарның битендә дә күренә башлады алар һәм шунда ук популярлашты да. Матурлык салоннарына барып вакыт әрәм итеп йөрмәс өчен, бу процедураны өйдә эшләргә өйрәтә торган күптөрле мастер-класслар үткәрелә. Алар, әлбәттә, түләүле. Без сезгә аны бушлай өйрәтәчәкбез. Тейп, ягъни киҗе-мамык нигезендәге пластырь биткә, нигездә, массаждан соң беркетелә. Ул шул рәвешле мускул тонусын ныгытырга ярдәм итә. «Гадәттә, битне яшьрәк күренсен, тартылып торсын өчен бәйрәм алдыннан төнгә тейплыйлар. Аз вакытка беркетеп куюның мәгънәсе юк. Атнага ике тапкыр төнгә ябыштырып йокласагыз, тупланма нәтиҗәсен сизми калмассыз», – ди массажист, тейплау остасы Алсу ХӘЙДӘРОВА.













■ Тейпны һәрвакыт буйга гына кисәбез. Чит-читләрен түгәрәклибез. Болай булганда ул биттән купмас. Тейпны ябыштырыр алдыннан битне ныклап чистартабыз, майсызландырабыз. Мускулларны йомшарту өчен бераз массаж ясап алсагыз, тагын да яхшырак булыр.

■ Тейпны ябыштыруның үз кагыйдәләре бар. Башта бер очын ябыштырабыз. Ул "якорь" дип атала. «Якорь»не беркеткәч, бераз гына тарттырып, икенче очын ябыштырабыз. Фотода «якорь» нокта белән билгеләнгән, тарттыру юнәлеше ук белән күрсәтелгән.

■ Бит алмасын күтәртү өчен тейпны бераз озынрак итеп кисеп алырга кирәк. Ул аскы казналык башланган урынга ябыштырылып, иреннәргә таба тарттырыла. Игътибар итегез, анда параллель рәвештә ике лента беркетәбез.

■ Ияк тирәсенә ябыштырганда да игътибарлы булыгыз. Ике яктан тейп – аска таба, уртада өскә таба тарттырыла.

■ Тейпларны ябыштырып бетергәч, бит тарттырылып торган кебек булырга тиеш түгел. Гомумән, биттә нидер барлыгы сизелер-сизелмәс кенә булсын. Ленталарны салдырганда кисәк хәрәкәтләр ясамагыз. Аларны җайлап кына куптарыгыз. Крем сөртеп куярга онытмагыз.

QR-код аша кереп, тейплауны видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.





Банкада – шоколадлы чия

«Аш-су» сәхифәсенең бүгенге кунагы – Айзирә БИКТИМЕРОВА. Тумышы белән Сарманнан ул. Ире Ленар, кызы Лия белән хәзер Казанда яши.
Айзирә – яшь һәм талантлы кондитер. Иң беренче тортын иренең туган көненә дип пешерә. Беренче генә тәҗрибәсе булса да, уңышлы килеп чыга ул. Хобби буларак кына башланган бу эшчәнлеге Айзирәне тора-бара җитдирәк эшләргә дә рухландыра. Җәмәгать туклануында инженер-технолог белгечлегенә укыган кызның десертлар белән мавыгып китүенә әллә ни аптырыйсы да юктыр, мөгаен. Ул тәкъдим итә торган десертлар бар да үзенчәлекле. Банкалардагы пирожныйларның унбер төрлесен әзерли Айзирә – бананлысын, чикләвеклесен, чиялесен... Муссы тортлар, бенто-тортлар да пешерә. «Төрле тәмнәрнең үзара ярашуын өйрәнәм, – ди яшь кондитер. – Моның өчен аш бүлмәсендә шактый вакытымны уздырырга туры килде. Аның каравы, күпме тәҗрибә тупладым, үзара идеаль туры килә торган тәмнәрне таптым».
Журнал укучыларыбыз белән бүген бүлешә торган рецепты да уникаль. Гаҗәеп йомшак шоколадлы бисквит һәм каймаклы крем, алар арасында исә әчкелтем татлы сусыл чия – телеңне йотарлык.

Кирәк (ингредиентлар 200 мл зурлыгындагы ике пыяла савыт өчен алына)
бисквит өчен: 2 йомырка / 60 г шикәр / 25 г атланмай (82,5 процентлы) 15 г какао порошогы / 45 г он.

Чия конфитюры өчен: 35–40 г төше алынган чия (туңдырылган чия дә ярый);
15 г шикәр комы / 15 г кукуруз крахмалы.
Крем өчен: 100 г каймак (33 процентлы) / 150 г эремчекле сыр / 25 г шикәр оны (пудра) / 10 г какао порошогы.



Эш барышы

- Башта бисквит пешерәбез. Моның өчен йомырканы савытка сытып, шикәр комы белән туглыйбыз һәм су мунчасында 45 градуска кадәр җылытабыз.
- Су мунчасыннан алып, йомырканы миксер белән күпертә башлыйбыз. Баштагы 2 минутта – акрын тизлектә, аннары инде 8 минут кызу тизлектә куерганчы күпертәбез. Какаоны он белән бутап, күпертелгән йомыркага кушабыз һәм кашык белән генә катнаштырып, йомшак камыр әзерлибез.
- Атланмайны эретеп, аңа камырның бер өлешен бушатабыз. Нәкъ менә камырны майга салу мөһим. Май камырга сеңеп беткәнче туглап, аны калган өлешкә кушабыз.
- Әзер камырны силиконлы җәймә җәелгән табага бушатып (майланган пергамент кәгазе дә ярый), 180 градуска кадәр кызган мичкә куябыз. Ул 20 минут чамасы пешә. Пешкәч, мичтән алып суытабыз.
- Төбе калын савытка чияне салып, утка куябыз. Кайнап чыккач, блендер белән ваклыйбыз. Крахмал белән шикәр комын катнаштырып, издерелгән чиягә әкренләп кенә кушабыз. Төерләнмәсен өчен, гел болгатып торабыз. Куеру белән, уттан алабыз һәм суынганын көтәбез. Өстен пленка белән капларга да онытмыйбыз.
- Хәзер инде крем ясыйк. Какаодан кала, крем өчен барлык ингредиентларны кушып, миксер белән күпертәбез. Крем йомшак һәм көпшәк булырга тиеш. Ахырдан гына бәләкәй иләк аша иләп, какаоны өстибез һәм тагын бер кат туглыйбыз.
- Чия конфитюрын һәм кремны икесен ике кондитер капчыгына тутырабыз. Бисквитны 2 см зурлыктагы шакмакларга бүләбез.
- Десерт кечкенә пыяла савытларга катламлап җыела. Савыт төбенә башта крем салабыз. Аның өстенә бисквит кисәкләре куела, аннары – чия конфитюры һәм янә тагын бер кат бисквит тезелә. Аннары тагын крем, чия конфитюры һәм иң өске катка крем салына. Крем өстенә вак иләк аша какао порошогы сибәбез. Анысы – бизәү өчен.

Чәйләрегез тәмле булсын!


















Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Өйнең яме — гөлләрдә


Камелия

Камелияне бер тапкыр күргән кеше аңа гашыйк булмый калмый. Салкынга чыдам, тынлык чоры булмаган бу гөлне үстерүе җайлыдыр дип уйлаучылар ялгыша. Фатирда камелия өчен яраклы шартлар тудыруы шактый ук четерекле. Ябык балкон, веранда яки кышкы бакча булмаганда камелиянең чәчәк атуын күрү икеле. Аның чәчәк ату чоры кышкы айларга туры килә һәм бу вакытта гөл өчен җылылыкның 10–15 градустан артмавы шарт.
Ул салкынча һаваны ярата, хәтта нульдән түбән температурага да түзә ала. Моннан тыш, яктылык 12–13 сәгатьлек булырга тиеш, әмма туры караган кояш нурларын ул өнәми. Яктылык җитәрлек булмаганда сабаклары озыная, яфракларының төсе китә, вагая. Шунлыктан көзге якта камелия ясалма яктыртуга мохтаҗ. Һаваның дымлылыгына да сизгер ул, кышын җылылык приборларыннан ераграк тотуны, ара-тирә өстенә су бөркеп коендыруны, җәй көне суны даими сибеп торуны таләп итә. Кыш көне исә, чәчәк атуына карамастан, су сибүне сирәгәйтеп, туфрагы кипкәннән соң гына сугаралар. Су йомшак булырга тиеш. Әче туфракларны яратканлыктан (туфрак сайлаганда моны истә тотыгыз), ара-тирә лимон согы яки аш серкәсе кушылган су да сибәргә мөмкин. Язын, гөлнең актив үсеш чоры башлангач, июль ахырына кадәр һәр ике атна саен тукландыру да сорала. Август урталарында туклandыруны туктатып торырга кирәк. Тиз үскәнлектән, камелияне еш күчереп утыртырга туры килә. Карт гөлләрне исә ике-өч елга бер күчерәләр. Азалияләр өчен булган туфрак камелия өчен дә кулай. Матурлыгын югалтмасын дисәгез, чәчәк атып бетергәннән соң гөлегезне формалаштырып кисәргә кирәк булачак. Ботак очларын кисү янботаклар үсешен активлаштыра.

Вриезияне бүлмәнең фильтры дип атыйлар. Ул һаваны зарарлы матдәләрдән, шул исәптән, тәмәке төтененнән дә чистарта. Вриезияне матур яфраклары өчен үстерәләр. Кайчан утыртуга карап, ул февраль-апрель яки май-июль айларында чәчәк ата. Чәчәкләре купшы түгел, ә менә чәчәк яны яфраклары, сортына карап, кызыл, алсу, сары, әфлисун төсендә була. Берьюлы берничә төстәгеләре дә бар. Бу гөл җылы ярата, аның өчен оптималь температура җәен – 22–24, кышын 18–20 градус. Температура +16 градуска кадәр төшсә, ул чирли. Вриезиягә якты урын кирәк, ләкин кояш нуры туры төшкәнне өнәми. Кышын гына көньякка караган тәрәзә төбенә күчерергә була. Аны сугару да үзенчәлекле – суны яфраклардан хасил булган «бүрәнкә»гә салалар. Ләкин ул анда тонып торырлык булмасын. Гөлнең туфрагы гел дымлы торырга тиеш, әмма чамасыз сугару да зыянлы. Кышын исә суны сирәгрәк һәм туфрагына гына сибәләр. Һаваның дымлылыгына таләпчән, дымлылыкны арттыру өчен, чүлмәкне юеш мүккә, керамзитка утыртырга, чәчәкләренә тидерми генә су бөркергә була. Яшь гөлне чәчәк атканчыга кадәр бер-ике елга – бер, ә аннан өч-дүрт елга бер генә күчерәләр. Бу эшне яз көне башкару отышлы. Савытның тирән булмаганын, киңен сайларга кирәк, тамырлары тирән китми. Туфракның бромелияләр өчен булганы яхшы.


Вриезия


Пахира

Пахира – табигатьтә 20 метрга кадәр үсеп, җимеш бирүче агач. Өйдә, билгеле, ул өч метрдан да артыграк үсә алмый. Пахираны уңыш һәм муллык китерә дип тә ышаналар.
Ул яктылык ярата, иртәнге яки кичке якта туры караган кояш нурларына да түзә, ләкин көндезге кояш аның өчен зарарлы. Яктылык җитәрлек булмаса, ул озыная, декоративлыгын югалта. Җил йөргән урыннарда, җылылык торбалары янында начар үсә.
Аның өчен иң кулай температура – 22–26 градус җылылык. Кышын исә температура 16–18 градус җылы булса яхшы. +15 градустан да кимрәк температурада тамырлары чери башларга мөмкин. Дымны яратса да, суны чамалап, туфрагының өсте кипкәннән соң савыт төбендә су җыелып тормаслык кына сибәләр. Сабак төбенә су тидермәскә тырышыгыз. Кышын исә сугаруны сирәгәйтәләр. Һаваның дымлылыгына таләпчән булмаса да, җәй көне яфракларына көн дә су бөркегәнне ярата. Язын һәм җәен актив үсеш чорында тукландыруга мохтаҗ. Ашламаның декоратив-яфраклы үсемлекләр өчен булганын сайларга кирәк. Бер чүлмәккә ике яки өч үсенте утыртып, аларны үзара үреп үстергәндә пахира аеруча матур күренә. Бәләкәй чакта аның сабагы сыгылмалы, үргәч, сүтелеп китмәсен өчен, вакытлыча гына бәйләп тә куярга була. Кибеттән алган гөлне өйдә адаптация узу белән күчерергә кирәк. Савытның киңен һәм саен сайлагыз, аның тамыры кыска гына. Утырткан вакытта үсемлекнең сабагын туфрак белән күмәргә ярамый. Ул уртача әчелектәге, артык уңдырышлы булмаган көпшәк туфракта яхшы үсә. Пальма, драценалар өчен ясалган туфрак аңа да туры килә. Пахираны тармак очларын тамырландырып үрчетәләр. Аның кайрысы инде ныгыган булырга тиеш.


Башка гөлләр үстерү турында да укыгыз.

Фото: ru.freepik.com

тест: сез миһербанлымы?

Әлеге тесттагы сорауларга җавап биреп, үзегезнең холык сыйфатыгызны ачыклый аласыз. Сез нинди кеше икән: кешеләргә карата миһербанлымы, әллә битарафмы?

Кеше белән сөйләшкәндә күңелен күтәрү өчен комплиментлар әйтәсезме?
Әйе, әңгәмәдәшең елмаеп сөйләшсә, күңелле бит – 2; булгалый, ләкин сирәк – 1; юк – 0.
Күңелегезгә ошамаган кеше белән дустанә аралаша аласызмы?
Кирәк булса, алам – 1; юк, моны кирәк дип санамыйм – 0; әлбәттә, татулыкка ни җитә – 2.
Башкаларның күңелен күрәм дип, арадан кемнедер үрти аласызмы?
Шаярту дип кабул итәселәрен белсәм, алам – 1; юк, болай эшләргә ярамый – 2; әйе – 0.
Үзегезгә аталган усал шаяртуга ничек җавап бирәсез?
Кәефкә карап – 0; җавап бирергә тырышам – 1; кәефем төшә – 2.
Сезгә кызык булмаса да, кемнеңдер проблемаларын тыңлый аласызмы?
Якыннарымныкын гына – 1; әлбәттә, бәлки бу аңа мөһимдер – 2; юк, тыңлап тормыйм – 0.
Үзегездән көчсезрәк көндәшегезнең күңеле булсын дип, уенда оттыра аласызмы?
Юк, уен гадел булырга тиеш – 0; ул кеше күңелемә якын булса, әйе – 1; мөгаен, әйе – 2.
Оттырасыгызны сизсәгез, нишлисез?
Уеннан чыгам – 2; зиһенемне тупларга тырышам – 1; ачуым килә, кәефем төшә – 0.
Соңгы акчагызны якыннарыгызга һәм дусларыгызга бүләк алу өчен сарыф итә аласызмы?
Әлбәттә – 2; берәр оригиналь бүләк күрсәм, әйе – 1; юк, бу ахмаклык – 0.
Хаклы икәнегезне белә торып, оппонентыгызны тыңлый аласызмы?
Әлбәттә, аның аргументлары кызык – 2; аннан тизрәк котылу өчен генә тыңлыйм – 1; юк, нигә вакыт әрәм итәргә – 0.
Ярдәм сорасалар, булышырга авырыксынасызмы?
Кем соравына карап – 1; юк, авырыксынмыйм – 2; ярдәм сораганны яратмыйм – 0.
Сезнең хакта, сәләтен тормышта куллана, дип әйтеп буламы?
Әйе – 2; мөгаен, юктыр – 1; юк – 0.

Балларны саныйбыз.
16 һәм аннан да күбрәк балл җыйсагыз – сез илтифатлы, теләсә кем белән уртак тел таба торган кеше. Кешеләргә ярдәм итәргә яратасыз. Мөгаен, дусларыгыз да күптер. Ләкин барысын да йөрәгегезгә артык якын кабул итмәгез, болай ук ярамый.
8 дән алып 15 баллга кадәр – якыннарыгызга, дусларыгызга сез бик мәрхәмәтле. Алар өчен барысын да эшләргә тырышасыз. Бик якын кешеләрегез генә сезнең хакта сокланып сөйли, калганнар өчен сез тәкәббер һәм салкын кеше, күпләр сездән читләшә.
7 балл һәм аннан да кимрәк – сезнең белән аралашу рәхәт түгел. Күңелегездә башкаларга урын юк, кешеләрне сүз белән җәберли аласыз. Шундый ук мөнәсәбәтне үзегезгә карата да тоясыз. Бераз гына түземлерәк һәм игътибарлырак булсагыз, тирә-юньдәгеләрнең сезгә карата фикере үзгәрер иде.

йолдызнамә октябрь

Кучкар. Бу ай яңа мөмкинлекләр вәгъдә итә. Озак уйлап, форсатны кулыгыздан ычкындармагыз. Шактый четерекле мәсьәләләрне хәл итәргә туры килер. Борчылмагыз, бар да сез уйлаганнан җиңелрәк булачак.

Үгезбозау. Тормышыгызда үзгәрешләр көтелә, ияләнгән гадәтләрдән бераз читләшергә туры килер. Игътибарлылык, төгәллек сорый торган эшләрне башка вакытка калдырып торыгыз.

Игезәкләр. Иҗади куәтегезнең көчле чагы. Сәләтегезне тулысынча ачу өчен уңайлы форсат чыгар. Иң кыю эшләргә дә икеләнми алыныгыз, нәтиҗәсе яхшы булачак. Бу айда үзегезне аеруча бәхетле итеп тоярсыз.

Кысла. Романтик вакыйгаларга һәм хисләргә бай чор көтелә. Тормышның моңарчы белмәгән кызыклы якларын ачарсыз. Гаиләдәге мөнәсәбәтләр бик җылы. Бу теләсә кайсы проблемаларны җиңел генә чишәргә көч бирәчәк.

Арыслан. Сезнең өчен алгарыш чоры көтелә, Плутон планетасының торышы белән бәйле ул. Мөһим карарлар кабул итәргә туры киләчәк. Сезгә комачаулаган кешеләр, эшегезгә аяк чалган вак-төякләр үзеннән-үзе юкка чыгачак.

Сөмбелә. Гадәти булмаган, истә калырлык вакыйгалар көтелә. Күп аралашырга туры килер, һәм ул сезнең файдага булачак. Якыннарыгызның киңәшенә колак салыгыз, карарларны ялгыз гына кабул итмәгез.

Бизмән. Алдыгызда яңа мөмкинлекләр һәм һөнәри перспективалар ачылырга тора. Язмышыгызны башка юнәлешкә борып җибәргән вакыйгалар уртасында калуыгыз ихтимал. Эш белән гаилә арасында алтын урталыкны табарга тырышыгыз.

Чаян. Көтелмәгән, хәтта могҗизага тиң үзгәрешләр булыр. Язмыш мөһим карарны үзе күрсәтәчәк, аны күрә белергә генә кирәк. Эчке тавышыгызны тыңласагыз ялгышмассыз, ул сезне уңышка алып киләчәк.

Укчы. Игътибарлырак булырга туры килер. Чишелеше шактый көч сорый торган вакыйгага таруыгыз ихтимал. Карарларны ашыгып кабул итмәгез. Бәлки, үз фикерегезне үзгәртергә дә туры килер. Бу айда авантюралардан сакланыгыз.

Кәҗәмөгез. Өстенлекне дөрес итеп куярга өйрәнергә туры килер. Көчегезне чынлап та мөһим эшләр өчен генә сарыф итегез. Күптәнге хыялыгызны тормышка ашыру өчен мөмкинлек килеп чыгар.

Сукояр. Матди яктан шактый уңышлы ай, уйламаган җирдән керем алырсыз. Күңелле вакыйга яки онытылмас очрашу белән истәлекле булыр бу ай. Ниятләгәннәрегезнең күбесенә җиңел генә ирешерсез.

Балык. Сез – биектә. Бу һөнәри өлкәгә дә, шәхси тормышка да кагыла. Үзегезгә чын-чынлап канәгатьлек китергән эшләр белән шөгыльләнерсез. Зур планнар кору өчен яхшы вакыт түгел. Якыннарыгызны кайгыртырга туры килүе бар.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.







ТӘЭССОРАТЛЫ ӘСӘРЛӘР

Пейзаж жанры дөнья шедеврлары нигезен тәшкил итә дип әйтеп була. Күп рәссамнар әлеге жанрга мөрәҗәгать итеп карый, ләкин барыбер дә картиналарының уңышы белән һәр иҗатчы да горурлана алмый. Ә менә талантлы рәссам Эдуард Хәбибуллинның пейзажларын карап туймаслык. Ул 1972 елда Алабуга шәһәрендә туган. «Әтием Илдус һәм әнием Луиза – иҗатчылар түгел, алар гомер буе төзелеш белән бәйле һөнәрләрдә булды, – ди әңгәмәдәшем. – Гаиләдә без дүрт бала үстек, ике абыем һәм бер сеңлем бар, алар да башка һөнәр ияләре. Ә мин балачактан бирле рәсем ясадым. Шуңа күрә дә әнием мине балалар сынлы сәнгать мәктәбенә бирде. Алабуганың 1 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбендә – алты ел, соңрак Мамадышның 87 нче һөнәр училищесында өч ел белем алдым. Белгечлегем – сәнгати бизәү эшләрен башкаручы».

Эдуард Илдус улы 1990 елда Совет Армиясе сафларына да чакырылган, армиядән соң Алабугада бизәмнәр ясау эшләре белән шөгыльләнгән. Көннәрдән бер көнне картиналар да яза башлармын дигән уй аның башына да килмәгән ул чакта. «Сәнгать мәктәбенә фәкать табигатьне сурәтләргә өйрәнер өчен генә кергән идем, ул темага балачактан ук тартылдым, ә хәзер мин аларны язмыйча түзә дә алмыйм инде, – ди оста. – 26 яшемдә бер рәссам дустым белән Алабуга автомобиль заводында үз һөнәребез буенча эшли башладык. Дустым картиналар да иҗат итә иде. Аңа карап мин дә киндергә майлы буяулар белән атаклы Шишкин, Левитан, Саврасов кебек рәссамнарыбыз әсәрләрен күчереп ясап карадым. 1998 ел иде бу... Бары тик 2008 елдан гына үз картиналарымны иҗат итәргә алындым. Холкым буенча мин тыйнак кеше. «Туган як» дип аталган беренче шәхси күргәзмәмне дә 2012 елда гына Алабуга дәүләт музей-тыюлыгында ачтым».

Эдуард Хәбибуллинның картиналарын үзебездә дә, чит илләрдә дә ошатучылар бик күп. Әйтик, 2015 елда Кытайның Шаньдун каласында узган кытай каллиграфиясе һәм сынлы сәнгать күргәзмәсендә милләттәшебезнең утыз картинасы да сәнгать сөючеләрнең игътибар үзәгендә булган. 2021 елда Алабуганың мәдәният йортында ачылган шәхси күргәзмәсен дә халык бик яратып кабул иткән.


Аның күпсанлы әсәрләре Россия, Кытай, Германия, Австрия, Польша, Чехия, АКШ, Белоруссия, Украина, Төркиянең шәхси тупланмаларында саклана.

Мондый югары дәрәҗәдәге пейзажларны язу өчен никадәр талант, сабырлык, төгәллек, титаник хезмәт таләп ителүе һәркемгә аңлашыла булыр. Эдуард Хәбибуллин, туган як табигатенең мәһабәт матурлыгын һәм куәтен сурәтләүдә үз юлын тапкан ирекле рәссам буларак, җылы, игелекле, тәэсирле әсәрләре белән милли сәнгатебезне баета, күңелләребезне Ватаныбызга карата тирән мәхәббәт белән сугара.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА





ЭДУАРД ХӘБИБУЛЛИН





ӘЙДӘГЕЗ, ХАТЛАР ЯЗЫЙК, ЯҢА ДУСЛАР ТАБЫЙК, БӨТЕН ДӨНЬЯ ТАТАРЛАРЫ БЕЛӘН БЕРЛӘШИК!

Хатлар йорты – открыткалар җибәрү сервисы



16+

ООО «Медиа – партнёр» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2, пом. 14, ГРН 1111690004469. Реклама